МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУК РФ
КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ

Институт филологии и межкультурной коммуникаций

Кафедра татарской литературы и методики преподавания

Т.Ш. ГИЛАЗОВ

ИСТОРИЯ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРНОЙ КРИТИКИ

Конспект лекций

Казань – 2014

Направление подготовки:

- 032700.62 – для студентов-бакалавров (2 курс, 4 семестр, очное) по направлению «Филология» по профилю Прикладная филология (Татарский язык и литература, этнодизайн);
- 032700.62 – для студентов-бакалавров (2 курс, 4 семестр, очное) по направлению «Филология» по профилю Прикладная филология (Татарский язык и литература, информационные технологии);
- 050302.65 для студентов-специалистов (5 курс, 9 семестр, очное) по направлению «Родной язык и литература (Практическая журналистика)», очное.
- 050302.65 для студентов-специалистов (5 курс, 9 семестр, очное) по направлению «Родной язык и литература (Русский язык в национальной школе)»
- 050302.65 для студентов-специалистов (5 курс, 9 семестр, очное) по направлению «Родной язык и литература (иностранный (английский язык))»

Учебный план:

- 032700.62 Филология Профиль: Прикладная филология (Татарский язык и литература, этнодизайн);
- 032700.62 Филология Профиль: Прикладная филология (Татарский язык и литература, информационые технологии).
- 050302.65 Учитель родного языка и литературы (Практическая журналистика).
- 050302.65 Учитель родного языка и литературы (Русский язык в национальной школе).
- 050302.65 Учитель родного языка, литературы и английского языка.

Дисциплина:

Б3.Б.4**.** История татарской литературной критики.

Количество часов: 72 (в том числе: лекции - 16, практические занятия - 18, самостоятельная работа - 38; форма контроля: зачет (4-й семестр).

Б3.8.5. История татарской литературной критики.

Количество часов: 72 (в том числе: лекции - 16, практические занятия - 18, самостоятельная работа - 38; форма контроля: зачет (4-й семестр).

Р.3 История татарской литературной критики.

Количество часов: 60 (в том числе: лекции - 20, практические занятия - 10, самостоятельная работа - 30; форма контроля: зачет (9-й семестр).

Темы

1. Татарская литературная критика как наука: ее предмет и задачи. Теоретическая основа литературой критики.
2. Период поисков и подготовки к формированию татарской литературной критики (древнейший период – конец XIX века).
3. Татарская литературная критика начала XX века: формирование татарской литературной критики как науки (1900-1917 гг.).
4. Реалистическая и романтическая литературная критика (на примере литературно-критической деятельности Ф.Амирхана и Г.Ибрагимова).
5. Татарская литературная критика эпохи тоталитаризма (1920 – I пол. 1950 – х годов).
6. Татарская литературная критика после эпохи тоталитаризма (II пол. 1950 – х годов – I пол. 1980 – х годов).
7. Профессиональная и писательская критика (на примере литературно-критической деятельности Ф. Миннуллина и М.Магдеева).
8. Современная татарская литературная критика (конец XX – начала XXI веков).

Аннотация:

Данный курс предусматривает изучение литературно-критического процесса в его взаимосвязях с общественной жизнью и состоянием культуры. Курс ознакомит этапами и закономерностями развития татарской литературной критики и ее жанровой системой; методами и принципами оценки литературного произведения, а также теорией и научной основой критики как филологической дисциплины; научит применять полученные знания в процессе теоретической и практической деятельности с

художественным текстом. В работе приведен список основных терминов курса и примерное тестовое задание текущего контроля. Электронный курс предназначен для работы на занятии и самостоятельно, поможет он и отстающим.

Ключевые слова: литературная критика, социокультурные условия, возрождение, пресса, журналистика, публицистика, культурный диалог, Восток, исламская культура, Запад, тип, вид, направление, течение, жанр, и т.д.

Дата начала использования: 1 сентября 2014 г.

Автор - составитель: Гилазов Тагир Шамсегалиевич, кандидат филологичеких наук, доцент кафедры татарской литературы и методики преподавания ИФ и МК КФУ , tgilazov@bk.ru

http://tulpar.kfu.ru/course/view.php?id=2018

Оглавление

ТЕМА 1. Әдәби тәнкыйть фән буларак. Аның предметы һәм максат-бурычлары. Әдәби тәнкыйтьнең фәнни нигезе. 5
ТЕМА 2 Әдәби тәнкыйть барлыкка килүгә әзерлек һәм эзләнүләр чоры (борынгы чорлар –XIX гасыр ахыры). 21
ТЕМА 3 XX гасыр башында татар әдәби тәнкыйте: аның фән буларак формалашуы (1900- 1917 еллар). 30
ТЕМА 4 Реалистик һәм романтик әдәби тәнкыйть (Ф.Әмирхан һәм Г.Ибраһимовлар тәнкыйте мисалында). 51
ТЕМА 5 Тоталитаризм дәвере татар әдәби тәнкыйте (1920 еллар - 1950 елларның уртасы). 78
ТЕМА 6 Тоталитаризмнан соңгы татар әдәби тәнкыйте (1950 елларның икенче яртысы – 1980 елларның беренче яртысы). 94
ТЕМА 7 Профессиональ һәм язучылар тәнкыйте (Ф.Миңнуллин һәм М.Мәһдиевләр тәнкыйте мисалында) 102
ТЕМА 8 Хәзерге чор татар әдәби тәнкыйте (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы). 113
Список источников информации 120
Вопросы к зачету 123

ТЕМА 1. Әдәби тәнкыйть фән буларак. Аның предметы һәм максат-бурычлары. Әдәби тәнкыйтьнең фәнни нигезе.

Аннотация. Тема “Татар әдәби тәнкыйте тарихы” фәненең предметын, максат-бурычларын, бу курсның фәнни үзенчәлеген һәм башка тармаклар белән бәйләнешен ача. Анда әдәби тәнкыйтьнең үсеш баскычлары, һәр чорның үзгәреш закончалыклары һәм төп сыйфатлары, тәнкыйтьнең әдәби барыштагы урыны билгеләнә.

Ключевые слова (төп төшенчәләр): социаль, әдәби, мәдәни шартлар, вазифа, предмет, кануннар, әдәби хәрәкәт

Методические рекомендации по изучению темы (Теманы үзләштерү өчен методик рекомендацияләр):

- Курсның предметы, максат-бурычлары хакында гыйльми күзаллау бирелгән лекция материалы урнаштырылган;

- Студентларга мөстәкыйль эш сыйфатында бирелгән темалар буенча презентацияләр үткәрү өчен материаллар тупларга, иҗади һәм контроль эшләр эшләргә, түгәрәк өстәлгә материал сайларга һәм төрле актуаль темаларга чыгышлар ясарга әзерләнергә тәкъдим ителә,

- Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максаты белән һәр темага сораулар һәм биремнәр бирелә.

Источники информации (Информация чыганаклары):

1. Гыйлаҗев Т. Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900-1925). Методик кулланма / Т. Гыйлаҗев – Казан, 1999. – 42 б.
2. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.
3. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 254 б.
4. Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). – Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.
5. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман / Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары / Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 271 б.
6. Мәрданов Р. “Шура” журналы (1908-1917): әдәбият мәсьәләләре / Р. Мәрданов. –Казан: Рухият, 2001. – 152 б.
7. Мәһдиев М.С. Реализмга таба. XXйөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре / М.С. Мәһдиев. – Казан: Университет нәшрияты, 1989. – 154 б.

8. Хәсәнов М.Х., Мөхәммәдиев Р.С. Әдәби тәнкыйть һәм эстетик фикер мәсьәләләре / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3-т. / XX гасыр башы / М.Х. Хәсәнов, Р.С. Мөхәммәдиев. – Казан, 1986. – 490-505 б.

9. Мухамадиев Р.С. Проблемы формирования татарской литературной критики (1900-1917) / Р.С. Мухаммадиев – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – 143 с.

10. Харрасова Р.Ф. Әдәби тәнкыйть теориясе. Махсус фән программасы / Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт университеты, 2007.- 32 б.

Интернет-ресурсы (Интернет-ресурслар):

1. dic.academic.ru/dic.nsf/bse/104011/**Литературная**
2. bse.sci-lib.com/article070749.html
3. http:// kitap.net.ru
4. kitapxane.at.tt
5. tatar.org.ru и др.

Глоссарий (Сүзлекчә):

Әдәби тәнкыйть - әдәби иҗатның әдәби әсәргә чорның гыйльми-нәзари һәм иҗтимагый сәяси, эстетик-әхлакый нормаларыннан чыгып бәя бирә, әдәби хәрәкәттәге күренешләрне аңлата торган төре.

Әдәбият тарихы - әдәбиятны үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган барыш итеп өйрәнә торган фән.

Әдәбит теориясе - әдәби әсәрнең һәм әдәби иҗатның фундаменталь сыйфатларын, закончалыкларын, шулай ук әдәби иҗатның тарихи үзгәрешен өйрәнә торган фән

Публицистика – (латинча “иҗтимагый мәгънәсендә) – хәзерге көннең әһәмиятле һәм актуаль, мөһим булган сәяси, социаль, икътисади, әдәби, хокук һәм башка проблемаларны яктыртучы әдәбият һәм журналистика төре. Публицистиканың максаты милләт, бер сыйныф, социаль катлау

мәнфәгатеннән чыгып, социаль милли һәм әхлакый идеал нигезендә җәмгыятькә, йогынты ясау, милли яшәешне, кешеләр карашын үзгәртү.

Вопросы для изучения (Өйрәнү өчен сораулар):

1. Фән буларак әдәби тәнкыйть, аның предметы һәм максат-бурычлары.
2. Әдәби тәнкыйтьнең башка фәннәр белән бәйләнеше.
3. Әдәби тәнкыйтьнең функцияләре.
4. Әдәби тәнкыйтьнең үсеш баскычлары.
5. Әдәби тәнкыйтьнең өйрәнелү тарихы.

Лекция №1. **Татар әдәби тәнкыйте фән буларак: аның педметы һәм бурычлары. Әдәби тәнкыйтьнең фәнни нигезе.**

Әдәби тәнкыйть - әдәби иҗатның бер төре, әдәби әсәргә һәм анда чагылган тормыш күренешләренә бәя бирү, әдәби әсәрләрнең чынбарлык белән бәйләнешен өйрәнә, аңлата. Теге яки бу әдәби әсәрнең идея-эстетик кыйммәтен ачыклау, аны китап укучыга тәкъдим итү дә булып тора. Шуңа да әлеге бәядә әсәрнең эчтәлек һәм формага бәйле сәнгати эшләнешен, яңалыгын объектив рәвештә билгеләү мөһим шартлардан санала. Шул рәвешле китап турында киң катлам укучыларда фикер-караш, мөнәсәбәт тудырыла һәм ул еш кына аның шул чор әдәбиятындагы урынын билгеләүгә йогынты ясый. Гомумән, тәнкыйть, бер яктан, аерым әсәрләрне яисә шул чор әдәби процессын өйрәнеп бәяләве белән әдәби-иҗади процессны оештыруга, үсеш-үзгәрешкә ярдәм итә; икенче яктан, китап укучы белән әдәип арасында арадашчылык вазифасын башкара, соңгысының сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен төшенергә, аңларга булыша; өченче яктан, эстетик төшенчәләрнең нигезен ачу-аңлату аша әдәби зәвыкны үстерергә ярдәм итә.

Матур әдәбият тәнкыйтьсез яши һәм үсә алмый. Төгәл фәннәрдән, әйтик, математика, физика, химиядән аермалы буларак, сәнгать, шул исәптән әдәби әсәрләр дә хис-кичерешләр, укучының күңел дөньясы аша кабул ителә. Хәтта кешенең характеры, холкы, халәте һәм эстетик зәвыгы дә китапны аңлауга һәм бәяләүгә мәгълүм дәрәҗәдә йогынты ясый. Әдәбият галиме һәм

методист Г.Сәгъди 1912 елда дөнья күргән “Әдәбият ысуллары” дигән хезмәтендә болай дип яза: “... шигырьләрнең гүзәллеген яки косурларын (кимчелекләрен – Г.Т.) бәхак (дөрес – Г.Т.) аңлап җитү кешенең [китапны уку] вакытына да вә кәефенә дә карый. Чөнки кеше һәрвакытта да [бертөрле] булып тормый. Шул сәбәптән бу көн безгә бик яхшы тәэсир иткән вә гүзәл тоелган бер шигырь иртәгесен тәэсир итми вә яхшы күренми башлый. Күңелебез ул шигырь алдында бик илтифатсыз бер хәлдә кала”. Күренә ки, әдәби әсәрне аңлау һәм бәяләүдә субъективлыкка урын кала. Яңа әсәрдә күзәтелгән уңай тенденцияләрне, яралгы хәлендәге яңалыкларны калкытып кую, сүз сәнгатенең үсеш-үзгәреш закончалыкларын билгеләү белән бергә, анда күзәтелгән кимчелекләрне, тискәре якларны куире кагу, аларны аңлатып бирү өчен дә тәнкыйть кирәк.

Тәнкыйтьнең нәрсә булуы турында, аның асылында иҗадилыкмы, фәннилекме өстенлек итүгә бәйле бәхәсләр дәвам итә.Әлеге сыйфатларны каршылыкта түгел, бәлки диалогик бәйләнештә карау уңышлы. А.А.Жук язганча, тәнкыйть “ әдәби процесс мәгълүматлары белән генә эш итүче фән түгел. Чын асылында ул үзе әлеге әдәби иҗатның аерылгысыз бер өлеше, әдәби эшчәнлек төре. Тәнкыйтьче – һәрвакыт әдип, әдәби тормышта тере катнашучы, бәлки аны өйрәнүче генә түгел (соңгысы әдәбият белеменә карый).

“Матур әдәбиятның таянычы, рухи юлдашы, изге намусы, хөкемдары” (Галиуллин Т.Н. 1984) буларак, тәнкыйть әдәби процесста гаять җитди урын алып тора. XX гасыр башында тәнкыйть мәкаләләре белән чыгыш ясый башлаган М.Укмасый болай дип яза: Әдәбият эчендә тәнкыйть булмаса, Аурупа галәмендә бу кадәр әдәбиятлар вөҗүдкә (барлык) килмәгән булыр иде. Без бу мәхсулатны (казанышны) күрмәс идек. Аурупада: нинди генә голүм вә фөнунгә (гыйлем һәм фән) яки сәнгатькә даир бер тәэлиф (китап) мәйданга килде исә әрбабы (каләм ияләре) тарафыннан мизанга салынып, бакчасына карап акчасы, кыйммәтенә карап хөрмәте биреләдер” Бу караш, иә беренче нәүбәттә, тәнкыйть башкарган бурыч-вазифаларның җитдилеге

белән бәйле. Чөнки ул әдәби әсәр яисә әдәби процесс турында гына түгел, бәлки мәдәнияткә, аның аша чагылыш тапкан дөньяны күзаллауга йогынты ясый.

Әдәбият тарихыннан аермалы буларак, әдәби тәнкыйть гадәттә әдәби хәрәкәттә булган үзгәрешләрне аңлатып бирә. Танылган драматург Т.Миңнуллин әдәби тәнкыйтьнең асылын болай аңлата: “Әдәби тәнкыйтьнең чын асылы – анализдыр. Әйтик, язучыны теге яки бу әсәрне язарга нинди сәбәпләр этәргән, масатына ирешә алганмы язучы, ирешә алмаса ни комачаулаган, бүгенге җәмгыять күзлегеннән караганда әһәмиятлеме язылган әсәр, язучы фикерен ни дәрәҗәдә осталык белән әйтә алган. Гомумәдәби процесста үз урыны бармы әсәрнең һ.б. һ.б. Мондый тәнкыйть-анализ теләсә кемне уйландыра. Син язучылык хезмәтенең ничаклы җаваплы икәнен янә бер тоясың, ягъни үз эшеңә читтән карап бәя бирәсең” (Таяныч, 2005).

Әдәби тәнкыйть күптөрле: эстетик, социаль, иҗтимагый бурыч-функцияләр башкара. Аның берсе *оештыру* белән бәйле, ягъни ул әдәби күренешләрне бәяләү белән генә чикләнмичә, әдәипләрне билгеле бер проблематика, актуаль мәсьәлә тирәсендә туплауга ярдәм итә. Бу төр эшчәнлекнең тагын бер формасы булып турле конкурслар, дискуссияләр аша теге яки бу чор әдәби процессын, аерым әдипләр иҗатын бәяәүне оештыра. Соңгысына нисбәтле төрле әдәби һәм дәүләт премияләренә лаек язучыларны барлау, алар иҗатын тикшерү, китң катлау укучыларга җиткерү дә тәнкыйтьнең җитди бурычларыннан берсе булып тора.

Аның тагын бер функциясе – *киләчәкне күзаллау*, прогноз бирү. Киң планда караганда тәнкыйть әдәби хәрәкәт артыннан бара: басылып чыккан әсәрләрне бәяли, нәтиҗәләр ясый, гомумиләштерүләр белән шөгыльләнә. Шул ук вакытта ул сүз сәнгатендә әлегә шытым гына булып сиземләнгән табышларны тотып ала, аларны киләчәктә билгеле бер тенденцияләргә әверелачәген билгели. Әдәби тәнкыйть “әдәби юнәлешнең эчке резервларын эзлекле аңлау-аңлату чарасы һәм аның әле ачылмаган иҗади мөмкинлекләркен билгеләү юлы һәм формасы” вазифасын үти (Жук, 1994).

Тәнкыйтьнең мөһим бер функциясе – *әдипкә,* аның дөньяны кабул итүенә йогынты ясау. Тәнкыйть мәкаләсе өйрәнелә торган әсәрнең авторын күздә тотып языла. Тәнкыйтьче әсәрне анализлау барышында автор белән бәхәс-әңгәмә дә алыып бара, аерым очракларда аның эзләнүен дәвам итә, тулыландыра, яңа якларын ача. Еш кына аерым штрихларда, кинаяле сүз артында яткан караш-фикерләрен үстереп, логик табышларга, иҗатчының үзе өчен дә серле булган иҗади фикерләү дөньясына килә. Шуның белән ул язучы әсәренең тирән катламнарын ачуга үзеннән өлеш кертә һәм әдипнең үзен дә бай мәгълүмат, үзенчәлекле караш-концепцияләр белән баета. Шулай ук язучы күз уңыннан төшеп калган яисә китап укучыларда каршылык уяткан, сәнгати планда тиешенчә дәлилләнеп, ачылып бетмәгән фикер, караш, төшенчә һ.б. бәяләп, әдипнең зәвыгын формалаштыруда, тел-стилен калыплаштыруда катнаша. “Һәрбер олы язучы, иҗатка керешкәнче, башкалар язган әсәрләр белән яхшылап танышып чыга, бөтен милли казанышларны, башка халыкларның сәнгать байлыкларын кызыксынып, күңел биреп, кирәксенеп өйрәнә, шуларның иң мөһим хасиятләрен, кабатлана торган билгеләрен, аңына, күңеленә сеңдерә. – дип яза Фәрит Хатипов. – Шулай итеп, анда матур әдәбиятның табигате, асыл хосусияте турында караш туа.. Кәгазьгә төшмәгән теория аның аңында хасил була. Әгәр шулай булмаса, шагыйрь үзенең шигырьләрен рифма, ритм, строфа белән язмас, әдип әсәрнең жанрын билгели алмас, каһарманнар язмышын мәгълүм бер сюжетка салып, бәйләнеш-мөнәсәбәтләр аркылы күрсәтмәс иде” (Хатипов Ф. 2003).

Әдәби тәнкыйтьнең чираттагы мөһим функциясе – китап *укучыга*, аның әдәби зәвыгына йогынты ясау. Бу турыда сүз алып барганда. Тәнкыйтьнең матур әдәбият белән якынлыгы, ягъни соңгысы үтәгән бурыч-вазифалар белән кушылып, үрелеп баруын да билгеләргә кирәк. Тәнкыйтьче үзе тикшерә торган әсәрне укучыга тәкъдим итеп кенә калмый, бәлки анда әдәби сурәтләнеш тапкан вакыйга-күренешләргә, тема-проблемага, алым-чараларга үз карашын, мөнәсәбәтен белдерә. Шуның белән ул укучының зәвыгын үстерә, “нәрсә яхшы, нәрсә начар”, “сәнгати матурлык”, “иҗат дөньясы”,

“сурәтле дөнья” һ.б. күпсанлы төшенчәләрне аңларга булыша.Бүгенге укучыларда шактый кызыксыну уяткан, киң планда массачыл әдәбият үрнәкләре буларак бәяләнгән детектив, хатын-кыз һәм солдат романнары кебек жанрлар вакыйгалылыкка, тәэсирлелеккә, төрле инстинктларга кагылучы күренешләргә, интригага, көтелмәгән сюҗет борылышларына байлыгы белән характерлана. Шуныңбелән бергә, аларда җитди сәнгать әсәренә хас булган үзенчәлекләр – кеше күңеленең тирән төпкелләренә төшү, яшәешне милли, әхлакый, фәлсәфи мәсьәләләр яктылыгында гәүдәләндерү, чор рухын чагылдырган образ-характерлар тудыру һ.б. шундый сыйфатлар урын алмый диярлек. Ә бит гомумкешелек кыйммәтләренә нигезләнгән чын гумманистны тәрбияләү башкача мөмкин түгел. Әдәби зәвык тәрбияләү әлеге олы максатка хезмәт итә. Әдәби зәвык төшенчәсе милли һәм әхлакый тәрбиядән шулай ук аерылгысыз. Миилилек күпгасырлык татар әдәбиятын иңләп уза. Тәнкыйтьченең бурычы әлеге сыйфатның тарлык, чикләнү булмавын, киресенчә, үз укучы һәм башкалар өчен дә мөһим, кызыклы төшенчә буларак ачу-аңлатудан гыйбарәт.

Тәнкыйтьнең функцияләре арасында аның *чынбарлыкка тәэсир итүе* дә бар. Бу аның дөньяга карашы, актив тормыш позициясе белән тыгыз бәйле. Тикшеренү объекты булган сүз сәнгате әсәрендә урын алган мәсьәләләргә нисбәтле тәнкыйтҗче караш-фикерләре белән уртаклаша, бәя бирә, иң мөһиме, әдип иҗатында я объектив, я субъектив рәвештә чагылыш тапкан, еш кына әсәрнең төрле катламнарында ачылган яшәеш-чынбарлыкның нигез проблемаларын үзәккә алып, бәхәс кора, анализ ясый, үзгәрешләр мөмкинлеген, юлларын билгели. Әсәрдә сурәтләнгән чынбарлык тәнкыйди язма авторының уй-фикерләре белән тулылана. Язучы фикеренең яңа якларын ачып, үзе дә иҗат процессында катнаша һәм шуның белән чынбарлыкка йогынты ясый.

Тәнкйтҗ теориясендә фәнни-теоретик тикшеренүләрнең объекты булып торган тәнкыйди язма тексты мөһим урын алып тора. Аның үзгә табигате матур әдәбият тексты белән фәнни текст арасында торуына бәйле.

Ул әдәби текст кебек күпмәгънәлелекккә йөз тотмаса да, фәнни язма кебек төгәллек-конкретлык белән дә аерылып тормый. Дөрес, әдәбият белемендә тәнкыйть текстының әдәбилеккә авышуы яисә якынаюы турында фикерләр өстенлек итә (Хализев Е.В.1980. Крылов 2007). Бердән, күптөрле фикер-карашлар уяткан әсәр турындагы язма үзе дә бертөрле генә бәялнә алмый, икенчедән,тәнкыйть язмасында һәрвакыт диярлек әсәрдән цитаталар урын ала. Шуның белән тексттагы әдәбилек төсмере бермә-бер арта. Һәм текстара бәйләнеш, автор сөйләме, персонаж сөйләме кебек төшенчәләр белән байый. Тәнкыйть язмалары да бертөрле генә түгел. Аерым текстлар әдәби әсәр кебек укылса (бигрәк тә”эссе”, “очерк” жанрлары), икенчеләренең абстракт фикерләүгә нигезләнеп язылуын күрәбез (әйтик, проблемалы мәкаләләрнең байтагы).

Әдәби тәнкыйть үзе дә тармаклана. Әдәби тәнкыйтьнең предметы, вазифа-бурычлары, жанрлар системасы, әсәрне бәяләү принциплары, алым-методлары кебек проблемалар белән *тәнкыйть теориясе шөгыльләнә.* Тәнкыйди фикернең борынгы чорлардан алып хәзерге көннәргә кадәр үсеш-үзгәреш баскычларын *әдәби тәнкыйть тарихы* тикшерә. Авторларның яңа басылып чыккан әсәрләренә *тәнкыйди барышта* бәя бирелә.

Тәнкыйть текстының үзенчәлекләрен билгеләгәндә, аның әдәбият белән бәйлелегеннән тыш, кайсы аудиториягә төбәлгән булуы, нинди максат белән язылуы да мөһим роль уйный. Соңгысы жанрлар классификациясендә аеруча ачык чагылыш таба. Язманың нинди аудиториягә атап язылуына килгәндә, гадәттә өч төркемне аерып чыгару күзәтелә: яшьләр өчен, махсус әзерлекле (элитар) укучыга (бу төркемгә язучылар да керә) һәм киң катлам укучыны күздә тотып. Билгеле, әлеге бүленеш бик тә шартлы., чөнки алар барысы да киң планда китап укучы булып торалар.Шулай да аерым язмаларда мондый бүленеш үзен шактый ачык сиздереп тора. Мисал өчен, Ф..Хатиповның “Иҗат серләре” мәкаләсе киң катлам укучыларга атап язылган. Автор укучысын сүз сәнгате дип аталган серле дөнья белән таныштыруны максат итеп куя. Ә инде Марсель Бакировның “Йөрәгемне

минем былбыл чакты...” язмасыэлитар укучыны күздә тотып язылган. Хезмәттә шагыйрь Зөлфәт иҗаты, теоретик төшенчәләргә нигезләнеп, сурәтле ассоциатив фикерләү үзенчәлекләрен билгеләү яссылыгында тикшерелә. Мәкалә авторы талантлы шагыйрьне “контрастлар шагыйре” дип атый һәм аңарда төрле халәткә күчү тойгысының бик нык үскән булуын дәлилли. Әлеге фәлсәфи-диалектик һәм поэтик алымнарның Зөлфәткә табигать дөньясы, кеше рухы турындагы хакыйкатьне әйтергә мөмкинлек бирүен ача (Бакиров. 2000).

Ул - әдәбият белеме фәненең бер тармагы һәм әдәбият тарихы, әдәбият теориясе, әдәби чыганакчылык һәм текстология белән тыгыз бәйләнештә яши. Аннан тыш әдәби әсәргә нисбәтле язылган текстта иҗат мәсьәләсе, аңа эстетик яктан бәя бирү теге яки бу дәрәҗәдә урын алса да, язма авторы яшәешнең күптөрле сорауларын читләтеп уза алмый, ягъни чор-заман проблемалары фәлсәфи, әхлакый, сәяси, тарихи мәсьәләләр белән үрелеп, ялганып китә. Тәнкыйть яшәешнең рухи-иҗтимагый өлкәләре булган матур әдәбият, фәлсәфә, эстетика, социология, психология, тарих һ.б. белән тыгыз бәйләнештә тора. Шул рәвешле әдәби тәнкыйть бу тармакларда да ачышлар ясарга мөмкинлек бирә.

Әлеге бәйләнештә гаять үзенчәлекле төс алган өлкә булып журналистика тора, чөнки ул тәнкыйтьнең гадәти яшәү, үсү-үзгәрү урыны да булып санала. XX йөз башында күпләп татарча газета-журналлар чыга башлау һәм аларда тәнкыйтькә киң урын бирелү нәтиҗәсендә тәнкыйть иҗатның бер төре буларак статус ала. Бу исә һәр текстка диярлек публицистиканың үтеп керүенә юл ача. Аерым очракларда исә тәнкыйтьнең публицистик тибы турында да сүз алып бару мөмкинлеге туа. Мондый язмалар әдәби тормышның теге яки бу чорына юнәлтелеп. Әдәби иҗатка йогынты ясаган шартлар, иҗтимагый күренешләр, чынбарлык вакыйга-хәлләре белән әсәр арасындагы бәйләнешләр үзәккә алына. Публицистик як өстенлек иткән язмала, гадәттә, киң катламукучыга атала. Һәм аларда аны әңгәмәгә тарту, бәхәскә китерү алымнары да урын ала. Мондый текстларны

бәяләгәндә социаль-иҗтимагый мохтине ачыклау белән бергә, язма структурасының үзенчәлекләрен, публицистиклыкның башка элементлары йогынтысын, чагыштырма урынын билгеләү дә сорала.

Тәнкыйть әдәбият тарихы һәм сәнгатьнең башка төрләре белән дә тыгыз бәйләнештә яши. Әдәбият тарихын өйрәнүче, билгеле инде, үткән мирас белән кызыксына, аны бәяли, закончалыкларын ача, системага салып тикшерә. Шуның белән бергә ул бүгенге әдәби процесска да тукталырга мөмкин һәм аны сүз сәнгатенең үсеш-үзгәрешендәге бер этап буларак бәяли ала. Шуның кебек үк тәнкыйтьченең төп максаты хәзерге әдәби процесс күренешләрен бәяләү-аңлату булса да, ул үткәндәге әдәби фактларга, әсәрләргә, чорларга, юнәлеш-агымнарга бүгенге көн биеклегеннән , яңа концепцияләргә таянып, анализ ясый, тикшерә ала. Аңлашылганча, әдәби тәнкыйть һич тә тар рамкаларда калмыйча, әдәбият тарихы, әдәбият теориясе, публицистика белән үзара йогынтылы мөнәсәбәттә була. Бу урында шуны искәртеп узарга кирәк, әдәбият турындагы фәннең башлангычында тәнкыйть тора. Әдәби тәнкыйть әдәбият тарихы һәм татар нәзари фикере формалашуга җирлек әзерли; әдәбия белеменең бу тармаклары, әдәби тәнкыйтҗ эчедә барлыкка килеп,сан һәм сыйфат үзгәреше кичерәләр. Мисал өчен, татар әдәби тәнкыйтенең формалашу чоры булган XX йөз башы тәнкыйтенә караган хезмәтләр дә бер төрле генә түгел, дөресрәге алар синкретик характерда булып, эчтәлекләрендә һәм тәнкыйтькә, һәм әдәбият тарихына, һәм әдәбият теориясенә караган мәсьәләләр тыгыз үрелеп бара. Шуңа да бу чор әдәбият белеменең нигезен тәшкил иткән Җ.Вәлиди, Г.Баттал, Г.Сәгъди, Г.Исхакый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан һ.б. хезмәтләре әлеге өч тармакның һәркайсы үсешендә мөһим этап буларак бәяләнә. Алга таба аларның һәрберсе үзенең предметын, өйрәнү объектын таба һәм үзен хас тикшеренү методларын, принципларын билгели.

Шулай итеп, үз предметы, хосусый үзенчәлекләре булган әдәби тәнкыйть әдәбият белеменең мөһим бер тармагы булып тора.

Татар әдәби тәнкыйтенең өйрәнелү тарихы

Татар әдәбияты тарихы, фәлсәфи-иҗтимагый хәят, нәзари-теоретик фикер үсеше галимнәр тарафыннан шактый тулы тикшерелгән, әмма тәнкыйть тарихы хакында моны әйтеп булмый. Ә аларны тулы, объектив яктырту иҗтимагый аңның бер өлеше бер булган әдәби тәнкыйтькә мөнәсәбәт белдерүдән башка мөмкин түгел. Шуңа күрә әдәбиятчы галимнәр һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикерне өйрәнүчеләр төп фәнни тикшеренү объекты уңаеннан тәнкыйди фикер яшәешенә, аның үсеш-үзгәрешенә игътибар итеп, үз мөнәсәбәтләрен белдереп баралар. Дөрес, әдәби тәнкыйди хәят бөтенләй өйрәнелмәгән дисәк, дөрес булмас иде. XX гасыр татар язучыларының әдәби эшчәнлеген, беренчедән, әдипнең үз тәнкыйди эшчәнлегеннән, икенчедән, каләмдәшләренең аның әсәрләре хакында әйтелгән бәя-хөкемнәреннән башка тулы, бөтен итеп гыйльми күзаллап булмас та иде. Галимнәр аерым язучылар рухи мирасын өйрәнәме, аерым төрнең формалашуын карыймы, я булмаса теоретик мәсьәләләрне тикшерәме, алар һәр очракта да әдәби тәнкыйди материалга мөрәҗәгать итәләр. Шушыңа параллель рәвештә XX гасырда әдәби тәнкыйть үткән юлның аерым баскычларын (аеруча татарәдәби тәнкыйтенең фән буларак формалашу чоры, татар совет әдәби тәнкыйтенең 1917-1935 еллары), үсеш тенденцияләрен барлау юнәлешендә җитди нәтиҗәләргә ирешелгән.

Шулай да тәнкыйть тарихы белән махсус шөгыльләнүче галимнәр аз. Тәнкыйтьне тарихи процесс буларак, эзлекле рәвештә өйрәнү, яктыртып бару мәсьәләсе 1910 нчы елларда ук көн тәртибенә куела. Ул энциклопедист галим Ризаэддин Фәхреддин мөхәррирлегендә нәшер ителеп, әдәби тәнкыйть, гомумән, тәнкыйть мәсьәләләренә зур игътибар биргән “Шура” журналы битләрендә күтәрелә. Озак та көттерми, еллык тәнкыйть тарихын яктыртып барырга тиеш булган басманың беренче китабы 1911 елда Казанда “Олуг кешеләр һәм аның эшләре” дигән исем астында дөнья күрә. Әмма “Шура” журналында тәнкыйтькә зур урын бирелү сәбәпле булса кирәк, бу китап бер генә мәртәбә дөнья күрә, яңадан чыгуы турында мәгълүмат юк.

Билгеле булганча, 1910 елларда мәктәп-мәдрәсәләрдә, мөгаллимнәр әзерләүче югары курсларда татар телен һәм әдәбиятын укыту проблемасы көн тәртибенә куела. Шушы уңайдан күп санлы дәреслекләр, хрестоматияләр языла. Г.Тукай "Мәктәптә милли әдәбият дәресләре" (1911), "Яңа әдәбият" (1914) һ.б. Г.Сәгъди "Әдәбият ысуллары" (1912), Г.Баттал "Нәзарияте әдәбияты" (1913), Г.Ибраһимов "Әдәбият кануннары" (1918) китапларында әдәби тәнкыйтькә махсус бүлек багышлыйлар һәм аларда тәнкыйть тарихының һәм поэтикасының аерым мәсьәләләре яктыртыла. Шулай ук татар дөньясында бу иҗат төренең барлыкка килү үзенчәлегенә, аның торышына да күпмедер күләмдә игътибар ителә.

Күренә ки, 1917 елдагы Октябрь борылышына кадәр татар әдәби тәнкыйте тарихын гыйльми өйрәнүнең беренче адымнары ясалса да, аны тарихи планда барлап, үсеш баскычларын, һәр чор-баскычның закончалыкларын ачыклаган, тәнкыйтьчеләрнең иҗат мирасын тикшергән монографик хезмәтләр язылмый. Совет власте елларында яңа иҗтимагый-сәяси шартларда әдәбият белеме фәненең марксистик-ленинчыл методологиясе эшләнә. Татар әдәби тәнкыйтьнең тарихы да шушы юнәлеш-позициядән торып тикшерелә башлый. Тәнкыйди фикер үткән юлны аңлау һәм үзләштерү мәсьәләләре белән махсус шөгыльләнмәсәләр дә Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Г.Рәхим, Җ.Вәлиди, Г.Сәгъди, Г.Газиз хезмәтләрендә татар әдәбияты тарихы һәм үзләре яшәгән чор әдипләре иҗаты турында гыйльми-тәнкыйди карашлары урын ала.

1927 елда Г.Сәгъди "Безнең юл" журналында "Бездә әдәби тәнкыйть" дигән монографик мәкаләсен бастыра. Шул ук елда ул аерым китап булып та чыга. Күләме зур булмаган хезмәт татар әдәби тәнкыйте үткән юлны тарихи планда яктырту омтылышының беренче тәҗрибәсе булып тора. Аның әһәмияте әдәби тәнкыйтьне формалаштыруга һәм үстерүгә зур өлеш керткән күренекле әдәбият галиме тарафыннан язылу белән дә билгеләнә. Г.Сәгъди беренчеләрдән булып, әдәби тәнкыйди фикернең тамырларын билгели. Ул тәнкыйть тарихын хаклы рәвештә мәгърифәтче галимнәр, иҗтимагый фикер

ияләре эшчәнлеге белән бәйләп карый: Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Кәрамнарның бу өлкәдә хезмәтләре автор тарафыннан югары бәяләнә. Сәнгать төрләренә бәйле рәвештә әдәби тәнкыйтьне, театр тәнкыйтен, ә тәнкыйтьчеләрнең әдәби әсәрне бәяләү принципларына, алымнарына нисбәтле реалистик тәнкыйтьне, чор идеологиясе йогынтысында идеалистик тәнкыйтьне (бүгенге көн күзлегеннән караганда Г.Сәгъдинең бу юнәлеш астында романтик тәнкыйтьне күздә тотуы ачыклана) аерып чыгара. Кызганычка каршы, әдәби тәнкыйть тарихын яктыртуда авторга вульгар социологизм шаукымы шактый комачаулаган.

Шулай да, безнең карашыбызча, XX гасыр татар әдәби тәнкыйтен өйрәнүдә сыйфат үзгәреше 1960-1980 елларга туры килә, чөнки бу дәвердә әдәбият белеменең бөтен тармакларында да сыйфади үзгәрешләр ясала. М.Гайнулинның “Татарская литература и публицистика начала XX века” (Казань, 1966) дигән монографиясендә XX гасыр башы татар әдәби тәнкыйтенә махсус бүлек багышланган. Ул анда күренекле әдипләрдән Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал һәм Г.Ибраһимовларның тәнкыйди эшчәнлеген тулы яктырта.

Татар тәнкыйтен бербөтен итеп карап, махсус өйрәнүгә багышланмасалар да, язучыларның әдәби иҗатларын фәнни тикшеренүгә багышланган монографияләрдә, гыйльми хезмәтләрдә аларның әдәби тәнкыйди эшчәнлекләре дә мәгълүм күләмдә игътибарга алына. Гали Халитнең “Габдулла Тукай и татарское литературное движение начала XX века” (Казань, 1956), “Тукай үткән юл” (Казан, 1962), Иван Пехтелевнең “Г.Тукай и русская литература” (Казань, 1966), Абдулла Сайгановның “Проблема типического в татарской реалистической литературе” (Казань, 1972), “Эстетика Ф.Әмирхана и эстетические идеи в реалистической литературе конца XIX – начала XX века (У истоков эстетики татарского реализма)” (Баку, 1972); Мансур Хәсәновның “Галимҗан Ибраһимов: Тормыш һәм иҗат юлы” (Казан, 1964), Шәйхелислам Садретдиновның “Сәгыйть Рәмиев иҗаты” (Казан, 1973) һ.б.ларда әдипләрнең матур

әдәбиятка карашлары, замандашларының әдәби әсәрләре хакындагы бәя-хөкемнәре, аны бәяләү алымнары һәм принциплары турында мәгълүмат урнаштырылган.

1972 елда КПСС Үзәк Комитетының югары уку йортларында әдәби тәнкыйтьне фән буларак укыту мәсьәләләренә дә кагылган карары кабул ителә. Гәрчә бу карар идеологик максатлардан гамәлгә куелса да, татар әдәби тәнкыйть тарихын өйрәнүгә күпмедер күләмдә уңай йогынты ясый. 1970-1980 елларда бу чорның әдәби тәнкыйтен өйрәнү белән М.Мәһдиев, Р.Мөхәммәдиев, З.Мәҗитовлар махсус шөгыльләнәләр.Шушы чорда татар әдәби тәнкыйте үсешенең төрле үсеш баскычларын тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациляәре тәкъдим ителә: М.Магдеев. Татарская советская литературная критика (1917-1932), 1963.; Бариева ЭР. Методология советской литературной критики (1917-1932), 1982; Гыйлаҗев Т.Ш.1920-1930 еллар татарәдәби тәнкыйте үсешендә төп тенденцияләр (метод һәм герой мәсҗәләләре), 1991. 1970 елларның икенче яртысында Р.С.Мөхәммәдиев татар әдәби тәнкыйтенең XX гасыр башында формалашу хәрәкәтен фәнни яктыртуга алына. Яшь галим тәнкыйтьнең предметы, үзбилгеләнү хокукы, иҗтимагый һәм әдәби вазифасы, тәнкыйть шартлары һәм башка теоретик мәсьәләләргә игътибарын юнәлтә. Кандидатлык диссертациясе нигезендә рус телендә “Проблемы формирования татарской литературной критики (1905-1917)” дигән монографик хезмәте 1982 елда дөнья күрә.

М.Мәһдиевнең XX гасыр башы әдәби-эстетик, әдәби тәнкыйди фикер көрәшен, матур әдәбиятның реализмга хәрәкәтен, язучыларның иҗтимагый һәм эшчәлекләре арасындагы мөнәсәбәтне, әдәбият тарихы чыганагы буларак вакытлы матбугатны өйрәнүгә багышланган “Реализмга таба” (Казан, 1989), “Социальные корни таланта” (Казан, 1990), “Әдәбият һәм чынбарлык (XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар)” (Казан, 1987) хезмәтләре басылып чыга.

1980 елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер тел, әдәбият һәм сәнгать) институты татар әдәбияты тарихының алты томлыгын язуга керешә. Татар әдәбиятының үсеш чорына нисбәтле Һәр томлыкта әдәбият белеме һәм тәнкыйтькә махсус бүлек багышлана. Мәсәлән, өченче томда М.Хәсәновның, Р.Мөхәммәдиев белән берггдектә язылган "Әдәби тәнкыйть һәм эстетик фикер мәсьәләләре" дигән монографик мәкаләсе урын алаган. Шулай ук бу тармакларда нәтиҗәле эшләгән галимнәрнең һәм тәнкыйтьчеләрнең гыйльми һәм тәнкыйди эшчәлекләре монографик мәкаләләрдә яктыртыла.

Үзгәртеп корулардан соң татар әдәби тәнкыйтен формалаштыру һәм үстерүгә зур өлеш керткән яңа исемнәр, яңа материаллар кайтты. Шулай ук моңа кадәр билгеле булган хезмәтләргә, мәкаләләргә яңача бәя бирү кирәклеге көн тәртибенә куелды. Шушы юнәлештә фәнни эзләнүләр алып барган галимнәр тагын да югарырак баскычка күтәрелеп докторлык диссертацияләре язуга алындылар. Ф.Галимуллинның "1920-1930 еллар татар әдәбиятында эстетика һәм социологиянең үзара мөнәсәбәте" (1999); Ә.Галиеваның "Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе" (2002) кебек хезмәтләрендә 1920-1930 еллар тәнкыйтенең методологик проблемалары яктыртыла. Бу юлда Т.Гыйләҗев уңышлы гына эшләп килә. Аның "Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900-1925)" (1999), "Әдәби мирас: тарих һәм заман" (2006) , "Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте" (2008) хезмәтләре XX гасыр башы әдәби тәнкыйтенең үсеш тенденцияләрен, тәнкыйть төрләрен, аерым әдипләрнең тәнкыйди эшчәнлеген өйрәнүгә багышлаган. Д.Заһидуллинаның татар нәзари фикеренең барлыкка килү һәм үсеш баскычларын барлаган "Әдәбият кануннары һәм заман" (2000) 1910 еллар тәнкыйди һәм нәзари фикер тарихына гомуми караш ташлана.

Ә.Закирҗановның "Яңарыш юлыннан" (2008), докторлык эзләнүләр нәтиҗәсе буларак басылып чыккан "Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.)(2011)

монографик хезмәтләрендә әдәби тәнкыйть тарихына шактый зур урын бирелә. Соңгы китапның “Современное состояние литературной кратики и перспективы развития” дигән бүлегендә (С.204-285) әдәби тәнкыйтьне өйрәнгән галимнәрнең хезмәтләренә күзәтү ясала., аларның тәнкыйть тарихын өйрәнүгә керткән өлешләре билгеләнә. Аннан соң тәнкыйтьнең үсеш баскычлары, һәр чорның үзенчәлекләре, үзгәреш тенденцияләре күрсәтелә. . Әдәби тәнкыйтьнең жанрлары, аларны төркемләү принциплары һәм төрле классификацияләре күздән кичерелә. Хәзерге әдәби тәнкыйтьтәге әдәби-гыйльми һәм фәлсәфи-эстетик концепцияләр анализлана. Ә.Закирҗановның монографиясе бүгенге көндә әдәби тәнкыйть фәне ирешкән казанышларны системалаштыру һәм аларны гыйльми-теоретик яссылыкта бәяләү ноктасыннан игътибарга лаек.

Вопросы и задания для самопроверки и контроля (Үзконтроль өчен сораулар һәм биремнәр):

1. Әдәби тәнкыйть һәм әдәбият тарихы: аерымлыклар һәм уртак яклар.
2. Әдәби тәнкыйть: әдәби иҗатмы әллә фәнме?
3. Әдәби тәнкыйтьнең функцияләре.
4. Әдәби тәнкыйтьнең өйрәнелү тарихының төп этапларын билгеләгез.

ТЕМА 2 Әдәби тәнкыйть барлыкка килүгә әзерлек һәм эзләнүләр чоры (борынгы чорлар –XIX гасыр ахыры).

Аннотация.

Тәнкыйди фикернең Урта гасырларны иңләп, борынгы чорларга кадәр барып тоташуы, татар әдәбиятының синкретик характерда булып, тәнкыйди бәя-хөкемнәрнең әсәр тукымасында урын алуы хакында мәгълүмат бирелә. Аеруча Урта гасыр ядкәрләрендә язучылар турында биобиблиографик белешмәләр урнаштыру киң тарала. XIX гасырда Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов

һәм аеруча К.Насыри хезмәтләрендә әдәби тәнкыйть беренче адымнарын ясый. Әдәби тәнкыйтьнең функцияләре , теоретик пастулатлары ачыклана башлый.

Ключевые слова (төп төшенчәләр): синкретизм, хашияләр, дини-дидактик тәнкыйть, Гареб, Шәрекъ, календарь, идея-эстетик катлам, рецензия.

Методические рекомендации по изучению темы (Теманы үзләштерү өчен методик рекомендацияләр):

- Әдәби-тәнкыйди фикернең борынгы чордан алып XX гасыр башына кадәр үсеш һәм эзләнүләр юлы турында гыйльми күзаллау булдырыла;

- Студентларга мөстәкыйль эш сыйфатында бирелгән темалар буенча презентацияләр үткәрү өчен материаллар тупларга, иҗади һәм контроль эшләр эшләргә, түгәрәк өстәлгә материал сайларга һәм төрле актуаль темаларга чыгышлар ясарга әзерләнергә тәкъдим ителә,

- Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максаты белән һәр темага сораулар һәм биремнәр бирелә.

Источники информации (Информация чыганаклары):

1. Гыйлаҗев Т. Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900-1925). Методик кулланма. – Казан, 1999. – 42 б.

2. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.

3. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 254 б.

4. Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). – Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.

5. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман / Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары / Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 271 б.

6. Ибрагим.Т.К., Султанов Ф.М., Юзеев А.Н. Татарская религиозно-философская мысль в общемусульманском контексте. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 239 с.

11. Мухамадиев Р.С. Проблемы формирования татарской литературной критики (1900-1917) / Р.С. Мухаммадиев – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – 143 с.

12. Очерки истории татарской общественной мысли. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. – 191 с.

13. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 1 том / Урта гасырлар дәвере. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1984.- 566 б.

14. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 2 том / XIX йөз татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1985.- 573 б.

15. Харрасова Р.Ф. Әдәби тәнкыйть теориясе. Махсус фән программасы / Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт университеты, 2007.- 32 б.

16. Юзеев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII-XIX вв. / А.Н. Юзеев.-Казань: Татар. кн. изд-во, 2001.- 192 с.

Интернет-ресурсы (Интернет-ресурслар):

1. dic.academic.ru/dic.nsf/bse/104011/**Литературная**
2. bse.sci-lib.com/article070749.html
3. http:// kitap.net.ru
4. kitapxane.at.tt
5. tatar.org.ru и др.

Глоссарий (Сүзлекчә):

Синкретизм – иҗтимагый һәм фәлсәфи фикернең сәнгатьчә әдәби формалар белән тоташкан, кушылган булуы.

Хашияләр – замандашларының шигъри әсәрләренең китап битләре кырыена язылган бәя-хөкемнәр.

Мәкалә - аерым китап яки билгеле бер вакыт аралыгында басылып чыккан әсәрләр төркеме турында сөйләп, гыйльми-нәзари карашлар якланган, теоретик фикерләр үткәрелгән тәнкыйди язма.

Некролог (грекча "үлгән" һәм "сөйләм" сүзләреннән) – күренекле кешенең үлеменә мөнәсәбәтле аның тормышы һәм эшчәнлеге турында язылган мәкалә, хәбәр.

Рецензия (латинча: тикшерү, карау мәгънәсендә) - әдәби тәнкыйть жанры. Рецензия китапка библиографик күзәтү ясый, әсәрнең эчтәлеге, стиле, алып килгән яңалыгы белән укучыны кыскача таныштыра, аның язучы иҗатында тоткан урынын, традицияләр белән бәйләнешен билгели, сюжет һәм композициясе турында фикер әйтә, әдипнең язучылык сәләтенә бәя бирә.

"Китаб әл-иршад-лил-гыйбад" – "Кешеләрне тугъры юлга өндәү"

"Мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" – "Казан вә Болгал хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр"

"Мөкаддимә китап вафият-әл-әслаф вә тәхият – әл-әхләф" – "Бабайларның үлеме һәм аларның киләчәк буыннарга васыяте"

"**Фәвакиһел җөласә фил әдәбият"** – "Әдәбият турында мәҗлесләрнең җимешләре"

Вопросы для изучения (Өйрәнү өчен сораулар):

1. Борынгы һәм Урта гасырлар дәверендә тәнкыйди фикернең яшәү формалары.
2. XIX гасырда тәнкыйди фикер үсешендә сыйфади үзгәрешләр.
3. Каюм Насыйри – әдәбият белеме һәм тәнкыйтькә нигез салучы.
4. XIX гасырның икенче яртысында язылган әдәби әсәрләрдә идея-эстетик катлам (Г.Ильяси, Ф.Халиди, Р.Фәхретдин, Г.Исхакый һ.б.).

Лекция №2. **Әдәби тәнкыйть барлыкка килүгә әзерлек һәм эзләнүләр чоры (борынгы чорлар – XIX гасыр ахыры)**

Әдәби тәнкыйть барлыкка килүгә әзерлек һәм эзләнүләр чоры хронологик яктан борынгы чорлардан алып XIXгасыр ахырына кадәрге вакытны иңли. Татар әдәби тәнкыйте, билгеле булганча, татар әдәбияты

тарихы белән тыгыз бәйләнештә, аның белән үрелеп үсә. XX гасыр башына кадәр татар әдәбияты, тулаем алганда, синкретик характерлы әдәбият булып кала. “Синкретик әдәбият аерым алынган нәфис әдәбият, фән һ.б. дан зуррак, киңрәк төшенчә генә түгел, ул – үзгә табигатьле күренеш, иҗтимагый аңның, фикерләүнең үзгә тибы. Тизләтелгән иҗтимагый үсеш шартларында синкретик әдәбияттан, ягъни барлык язма мәдәнияттән нәфис әдәбиятка, ягъни сәнгать төре буларак аңланучы әдәбиятка күчү башкарыла”, - дип яза Гочев Г.С. (“Ускоренное развитие литературы (на материале болгарской литературы первой половины XIX в. – М., 1964. – С. 15. Д.Ф.Заһидуллина. Дөнья сурәте үзгәрү. – Казан: Мәгариф, 2006. – 29 б.). Шушы карашны гыйльми – нәзари фикергә нисбәтле дә әйтергә мөмкин: XIX – XX гасыр чикләрендә әдәбият белеменең әдәбият тарихы, әдәби тәнкыйть кебек тармаклары мөстәкыйль үсеш юлына чыгалар. Мәсьәләгә болай якын килгәндә, тәнкыйди фикернең чикләре, урта гасырларны иңләп, борынгы чорга барып тоташа. Әдәби тәнкыйть элементларын халык авыз иҗатында, Урта гасырның кульязма истәлекләрендә очратырга мөмкин. Соңрак басма әсәрләрдә, фәнгә һәм тарихка караган хезмәтләрдә тәнкыйди фикерләр, эстетик карашлар, библиографик белешмәләр, бәяләмәләр, аңлатмалар формасында тәнкыйди фикерләр урын ала, китерелә; шулай ук язучы, галим, иҗтимагый фикер ияләренең тормыш юлы һәм эшчәнлекләре турында мәгълүматлар бирелә.

Бу чордагы шигъри әсәрләрдә каләмдәшләре әсәрләрен бәяләү, тамгалау традициясе яшәгән. Шулай ук шәрех (аңлатма), хашияләр, “бәйләүләр” (китап бите кырыендагы искәрмәләр) язу гадәте дә киң тарала. Алтын Урда чорының күренекле шагыйре Сәиф Сараиның атаклы фарсы шагыйре Сәгъдинең “Гөлстан”ыннан ирекле тәрҗемә ителгән “Гөлстан бит-төрки” поэмасында әдәбиятның, китапның язылу максатын яшәү, көнитеш мәсьәләләреннән кешеләргә үгет-нәсихәт бирүдә, аларда уңай, матур сыйфатлар тәрбияләүдә билгели. Автор рифмага корылган мәгънәсез шигырь авторларын, башка шагыйрь әсәрләрен үзләштергән плагиатларны

тәнкыйтьли. Үзләре яшәгән тормышка мөнәсәбәтләрен, дөньяга карашларын ачык белдерә башлаган М.Колый (XVIII гасыр урталары), Габдерәхим Утыз-Имәни (1754-1834), Г.Кандалыйлар (1797-1860) матур әдәбият турында уйланганнар, үз бәя-хөкемнәрен теркәп калдырганнар. Кызганычка каршы, аларның фикер юнәлеше аз өйрәнелгән.

Габденнасыйр Курсави (1776-1818) беренчеләрдән булып, кеше акылын зурлый, аның мөмкинлекләренең киңлеген раслый. Адәмнең кылган гамәлләре, эшләре үзенең белеме һәм акылы белән билгеләнүен әйтеп чыга. Ул тәнкыйди фикерләрен гарәп телендә язылган “Китаб әл-иршад-лил-гыйбад” (Казан, 1903) (“Кешеләрне тугры юлга өндәү”) дигән китабында теркәп калдыра. Бу хезмәткә Г.Сәгъди югары бәя бирә: “Әл-иршад лил-гыйбад” – үзе тәнкыйди бер әсәр ул. Курсави моның белән, гәрчә гарәп телендә булса да, татарда беренче мәртәбә тәнкыйть юлын ача. Аның тәнкыйте дә каты, ачы. Әлбәттә, әдәби тәнкыйть түгел, дини, фәлсәфи бер тәнкыйть” (Татар әдәбияты тарихы, 1926, 22 б.).

Мәгълүм булганча, XIX гасырда иҗтимагый фикернең бер төре буларак дини-фәлсәфи фикер формалаша. Г.Курсави, Г.Утыз-Имәниләрдән башланган бу юнәлеш Ш.Мәрҗәни, Х.Фәезханов һ.б.лар көче белән үстерелә. Дини фәлсәфи эчтәлектәге хезмәтләрдә тәнкыйть яралгылары да урын ала. Тарихчы, философ һәм галим-мәгърифәтче Ш.Мәрҗани (1818-1889) үзенең “Мөкаддимә китап вафият-әл-әслаф вә тәхият-әл-әхләф” (“Бабайларның үлеме һәм аларның киләчәк буыннарга васыяте”) дигән җиде томнан торган библиографик хезмәтендә атаклы галим, философ, әдипләрдән Әбугалисина, Эвклид, Платон, Пифагор, Фалес, Сократ, Нәваи, гомумән, гарәп шигъриятенең тарихы турында тәнкыйди фикерләр, үз карашларын язып калдырган. Шулай ук аның үз остазы Г.Курсави, Г.Утыз-Миәни кебек әдипләр тормышына игътибар итүе турында мәгълүматлар бар. Аның “Мөстафадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар” (“Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр”) китабында да тәнкыйтькә караган мәгълүматлар урын ала. Китапның авторы татар халкының рухи-мәдәни,

әдәби тормышында әһәмиятле роль уйнаган могътәбәр кешеләр хакында белешмәләр урнаштыра. Борынгы һәм Урта гасыр болгар-татар әдәби истәлекләре Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф”, Мәхмүд Болгариның “Нәһҗел-фәрадис”, “Кисекбаш” һ.б. әсәрләр идея-эчтәлеге һәм аларның авторлары турында үз бәя-хөкемнәре белән уртаклаша. Хәтта үзенә кадәр дөнья күргән китапларга шәрехләүләрдәге төгәлсезлекләрне дә барлый. Мәсәлән, Г.Утыз-Имәни тарафыннан Суфи Аллаһиярның “Сөбател гаҗизин” китабына язылган аңлатмада аның хаталарын күрсәтә.

Татар иҗтимагый фикере тарихында тәнкыйть сукмакларын салучыларның берсе Ш.Мәрҗани булуын Г.Сәгъди әйтеп уза: “Бездә тәнкыйтьнең беренче адымы XIX йөзнең башларында Курсави белән башланды. Беренче укларын атучы ул булды. Аның тәнкыйте татарның фикер туңлыгына, каралыгына, наданлыгына һәм тәкълидчелегенә каратылган дини-фәлсәфи усал, каты бер тәнкыйть иде... Шул ук рухтагы тәнкыйтьне XIX йөзнең соңгы яртысында Шиһаб Мәрҗани дәвам иттереп алып китте. Бу тарихчы-галимнең тәнкыйте тагын да ачы, тагын да каты, тагын да зәһәрле булды. Аның тәнкыйте дини, гыйльми, тарихи иде” (Сәгъди Г. “Бездә әдәби тәнкыйть”, “Безнең юл”, 1927, № 10, 39 б.).

Х.Фәезхановның энесе Габделгалләм Фәезханов “Мөхәррик әл-әфкяр” (“Фикер уяну”) китабында, беренчеләрдән булып, татар язучыларыннан Заһир Бигиев, Муса Акъегетзадә иҗатына бәя бирә, рус телен өйрәнергә чакыра, кадимчеләрнең хаксызлыгын раслый.

XIX гасырның икенче яртысында атаклы татар галиме, мәгърифәтче, фикер иясе булып танылган К.Насыйри – татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырган шәхес. Ул әдәбият белеме өлкәсендә зур хезмәт куя. Аның исеме белән татар әдәбиятында яңа дәвер башлана. Шәрыкътән Гаребкә таба борылу шуның характерлы бер сыйфаты булып тора. Урта гасыр татар әдәбияты, шәрыкътән килгән традицияләрне Көнбатышның әдәби практикасы белән кушу омтылышы юлындагы беренче адымнар К.Насыйриның әдәби эшчәнлегендә ясала. Календарьларында

чыгып барган фәнни һәм публицистик мәкаләләре белән ул татар әдәби тәнкыйтенә һәм әдәбият белеменә нигез сала. Аның әсәрләрендә Г.Утыз-Имәни, Кандалый кебек шагыйрьләрнең иҗат мирасын бәяләүнең беренче үрнәкләре очрый. Яңа китапларга рецензияләр язганда, ул аларны һәм эчтәлек, һәм форма җәһәтеннән яхшырту юнәлешендә киңәшләр бирә. Әйтергә кирәк, К.Насыйри әдәби-гыйльми эшчәнлегендә әдәби тәнкыйтьнең жанрлары, аларның сыйфатлары ачыклана башлый. Мәсәлән, рецензия, тәгъзия, мәкалә һ.б.

К.Насыйриның 1881 елда Казанда басылып чыккан китабы "Кабуснамә" дип атала. Китапның бер бүлеге "Шигырь вә шагыйрьләр әхвале бәянында" дип атала. Анда шигырь, шигырьнең эчтәлеге, укучыларга төбәлгәнлеге турында әйтелгән фикерләре кыйммәткә ия. Автор карашынча, шигырьнең төп күрсәткече ритм һәм рифма гына түгел. Илһам, хис һәм таланттан башка шигырь язып, иҗат итеп булмый.

К.Насыйри кешенең матурлыкны күрә белү һәм бәяләү сәләтен югары бәяли. "Чәчәкләр матурлыгын күреп сокланмаган, музыка, җыр белән кызыксынмаган кеше нинди кеше була инде ул", - ди яза галим "Фәвакиһел җөласә фил әдәбият" ("Әдәбият турында мәҗлесләрнең җимеше") (Казан, 1884) дигән китабында. Аның кырыгынчы, соңгы бүлеге халык авыз иҗаты, тел, әдәбият тарихы һәм әдәбият мәсьәләләренә багышланган. К.Насыйри башта халык авыз иҗаты жанрларына, шигырьләрнең, гомумән матур әдәбиятның әһәмиятенә туктала, әдәби күренешләргә шактый киң аңлатмалар бирә. Анда, алда әйтелгәнчә, XIX гасыр әдәбиятына күпер салучы Габдерәхим Утыз-Имәни һәм мәгърифәтче шагыйрь Габделҗәббар Кандалый иҗатлары гыйльми күзаллана. Соңгысының күренекле поэмаларыннан "Сәхипҗамал", "Бәдыйга", "Фәрхи"не үз китабына урнаштыра. Әдип әсәрләрен тел һәм төзелеш ягыннан фәнни шәрехләү омтылышын ясый.

XIX гасырның икенче яртысында иҗат ителгән әдипләрнең әсәрләрендә матур әдәбият, әдәби әсәрләрдә гәүдәләнгән тормыш материалы, аның иҗтимагый-милли әһәмияте, башка авторларның әсәрләре турындагы

фикерләр урын ала. Күп кенә әсәрләр башка язучыларның әсәрләренә җавап, аның идея-эчтәлегенә авторның үз позициясен белдерү рәвешендә язылалар. Исеменнән күренгәнчә, Ф.Халидинең “Рәдде бичара кыз” драмасы Г.Илъясиның “Бичара кыз”ына җавап, аның белән сөйләшү, әдәби диалог формасында язылган Р.Фәхретдиновның “Әсма яки гамәл вә җәза”, “Сәлимә вә гыйффәт” әсәрләрендә әдәби тәнкыйть элементлары зур урын ала. Г.Исхакыйның XX гасыр башында язылган хикәя, повесть, романнарында, мәсәлән, “Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер”, “Кәләпүшче кыз”, “Бай углы” кебек әсәрләрендә гомумән матур әдәбиятның әһәмияте, аның иҗтимагый вазифасы, анда гәүдәләнгән әдәби күренешләр турында бәя-фикерләр урнаштырылган. Мәсәлән, Г. Исхакый 1903 елда дөнья күргән “Бай углы” романына язылган кереш сүзендә матур әдәбиятның ролен кешенең әхлагын, холыгын төзәтүдә, яшь кешегә дөрес юл күрсәтүдә билгели: “Егетләр бу романнардагы кешеләрдән гыйбрәт алып, бердән, холыкларыны төзәтәләр; икенчедән, андый юк эшләр эшләргә вакытлары калмый; өченчедән, вакытлары булса да, бу хикәяләр, романнар саясендә бунларның вөҗданы үзләренә баш булып, үзләрене начар эшләрдән саклыйдыр” (129-130 б.).

Димәк, борынгы чорлардан алып XIX гасыр ахырына кадәр тәнкыйди фикер катлаулы үсеш юлы кичерә. Бу вакыт аралыгында ул башка фикерләү төрләреннән аерылып чыгып, мөстәкыйль үсеш сукмагына әзерләнә, үз предметын, максат-бурычларын ачыклау, хосусый жанрларын, әдәби әсәрләрне бәяләү кагыйдәләрен һәм метод-алымнарын эшләү юлына чыга.

Вопросы и задания для самопроверки и контроля (Үзконтроль өчен сораулар һәм биремнәр):

1. Борынгы һәм Урта гасырлар дәверендә тәнкыйди фикер нинди формада яши.
2. Г.Сәгъди “Бездә әдәби тәнкыйть” (1927) Г.Курсави һәм Ш.Мәрҗаниләргә нинди бәя бирә.
3. Ш.Мәрҗанинең нинди хезмәтендә әдәби тәнкыйтькә беренче билгеләмә бирелә.

4. Г.Ильяси һәм Ф.Халиди әдәби әсәрләрендә әдәби әсәргә бирелән катламнарны табыгыз.
5. К.Насыйри гыйльми эшчәнлегендә әдәби тәнкыйтьнең нинди теоретик мәсьәләләре күтәрелә.

ТЕМА 3 XX гасыр башында татар әдәби тәнкыйте: анық фән буларак формалашуы (1900- 1917 еллар).

Аннотация.

XX гасыр башының иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-мәдәни характеристикасы турында мәгълүмат бирелә һәм татар әдәби тәнкыйтенең фән буларак үсеш сукмагына чыгу ассызыклана. Яңарыш чорында татар әдәби тәнкыйтенең үсеш закончалыклары, эстетик фикер көрәше гыйльми күзаллана. Әдәби тәнкыйтьне формалаштыруга зур өлеш керткән тәнкыйтьчеләр эшчәнлеге яктыртыла.

Ключевые слова (төп төшенчәләр): социаль, әдәби-мәдәни шартлар, вакытлы матбугат, тәнкыйть предметы, функция, культурологик ориентация, бәйләнешләр, жанр, тәнкыйть типлары, төрләре.

Методические рекомендации по изучению темы (Теманы үзләштерү өчен методик рекомендацияләр):

- Лекция материалында татар әдәби тәнкыйтенең фән буларак калыплашу тарихы урнаштырылган;

- Студентларга мөстәкыйль эш сыйфатында бирелгән темалар буенча презентацияләр үткәрү өчен материаллар тупларга, иҗади һәм контроль эшләр эшләргә, түгәрәк өстәлгә материал сайларга һәм төрле актуаль темаларга чыгышлар ясарга әзерләнергә тәкъдим ителә,

- Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максаты белән һәр темага сораулар һәм биремнәр бирелә.

Источники информации (Информация чыганаклары):

1. Гыйлаҗев Т. Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900-1925). Методик кулланма. – Казан, 1999. – 42 б.

2. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.

3. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 254 б.

4. Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). – Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.

5. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман / Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары / Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 271 б.

6. Мәрданов Р. “Шура” журналы (1908-1917): әдәбият мәсьәләләре / Р. Мәрданов. –Казан: Рухият, 2001. – 152 б.

7. Мәһдиев М.С. Реализмга таба. XXйөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре / М.С. Мәһдиев. – Казан: Университет нәшрияты, 1989. – 154 б.

8. Хәсәнов М.Х., Мөхәммәдиев Р.С. Әдәби тәнкыйть һәм эстетик фикер мәсьәләләре / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3-т. / XX гасыр башы / М.Х. Хәсәнов, Р.С. Мөхәммәдиев. – Казан, 1986. – 490-505 б.

9. Мухамадиев Р.С. Проблемы формирования татарской литературной критики (1900-1917) / Р.С. Мухаммадиев – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – 143 с.

10. Харрасова Р.Ф. Әдәби тәнкыйть теориясе. Махсус фән программасы / Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт университеты, 2007.- 32 б.

Интернет-ресурсы (Интернет-ресурслар):

1. dic.academic.ru/dic.nsf/bse/104011/**Литературная**
2. bse.sci-lib.com/article070749.html
3. http:// kitap.net.ru

4. kitapxane.at.tt

5. tatar.org.ru и др.

Глоссарий (Сүзлекчә):

Әдәби тәнкыйть - әдәби иҗатның әдәби әсәргә чорның гыйльми-нәзари һәм иҗтимагый сәяси, эстетик-әхлакый нормаларыннан чыгып бәя бирә, әдәби хәрәкәттәге күренешләрне аңлата торган төре.

Интикад (гарәпчә: акчаның ялганнарын дөресләрдән аеру мәгънәсендәге нәкадә сүзеннән ясалган) – китап, журналны игътибар белән укып чыгып, шәхси мөнәсәбәтләргә юл куймыйча, аны тикшерү һәм җентекләп өйрәнү, уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтү. XX гасыр башында әдәби иҗатның бер төре – тәнкыйть терминына синоним төшенчә буларак кулланыла.

Профессиональ тәнкыйть – әдәби тәнкыйть өлкәсендә максатчан шөгыльләнүче эшчәнлеген белдереп, әдәби әсәрне төзелеш-структурасына, эчке закончалыкларына таянып анализлаган һәм шул нигездә тормышның сүз сәнгатенә бәйле рухи ихтыяҗларын, мәдәни сыйфат-билгеләрен ачкан академик характердагы тәнкыйть.

Публицистик тәнкыйть – әдәби әсәрне җәмгыятькә, андагы процессларга бәйле тикшереп, яшәешкә социологик характеристика мөһим урын алып торган һәм ул язма структурасының башка элементлары белән тыгыз үрелеп, укучыга юнәлтелгән тәнкыйть.

Сәлби (кире) - әдәби әсәрнең җитешмәгән, кимчелекле якларын күрсәткән тәнкыйть сәлби тәнкыйть дип атала.

Укучылар тәнкыйте – китап укучыларның үз заманы әдәби процессына, аерым әсәрләргә бәйле карашлары белән уртаклашуга нигезләнеп, нигездә әсәрнең итҗтиагый-милли кыйммәтен ачкан, ихласлылык, укылган әсәр нигезендә туган хисси уйлануларга, шәхси кичерешләргә бай булган тәнкыйть.

Филологик тәнкыйть – әдәби әсәрне тел-стиль үзенчәлекләре ягыннан тикшереп бәяләүне күздә тотып, өйрәнү объектының идея-

проблематика ягын, киң планда бөтенлекле анализны читтә калдырып, алгы планга грамматика һәм сурәт чаралары, тел билгеләре кебек мәсьәләләне чыгарган тәнкыйть.

Фәлсәфи тәнкыйть – матур әдәбиятны үткән һәм киләчәк, язмыш һәм хакыйкать, фаҗига һәм өмет һ.б. фәлсәфи категорияләргә бәйле тикшереп, анда яшәешнең, чынбарлыкның олы мәгънәсен эзләп табуга юнәлтелгән тәнкыйть

Язучылар тәнкыйте – төп иҗади эшчәнлекләре әдәби әсәрләр язу белән бәйле булып, субъективлык, шәхси башлангыч, көтелмәгән ассоциацияләр, бәйләнешләр, нәтиҗәләр киң урын алган, үзгә зәвыкка нигезләнгән, төр һәм жанр ягыннан чуар булган тәнкыйть.

Вопросы для изучения (Өйрәнү өчен сораулар):

1. XX гасыр башында яңа иҗтимагый һәм әдәби-мәдәни ситуация.
2. Әдәби тәнкыйтьнең фән буларак формалашуы: әдәби тәнкыйтьнең предметы ачыклану әдәби әсәрне бәяләү принциплары, кагыйдәләре һәм алымнары эшләнү.
3. 1910 еллар татар әдәби-гыйльми фикерендә эзләнүләр, дөнья әдәбият белемендә формалашкан мәктәпләргә, нәзари юнәлешләргә мөнәсәбәт.
4. Әдәби тәнкыйть төрләре һәм типлары.

Лекция№3. **XX гасыр башында татар әдәби тәнкыйте: аның фән буларак формалашуы (1900-1917 еллар).**

20 йөз башында әдәби тәнкыйть үзенең үсеш тарихында яңа чорга килеп керә. Беренче рус инкыйлабының шифалы җилләре аның яңа күтәрелешенә шартлар әзерли. Вакытлы матбугат туып, әдипләр каләменнән төшкән яңа әсәрләрне укучы игътибарына тәкъдим итү өчен мәйдан барлыкка килә. Казанда нәшер ителгән “Йолдыз”, “Азат”, “Азат халык”, “Таң йолдызы”, “Аң”, Җаекта чыккан “Фикер”, “Әлгасрелҗәдит”, Оренбургтагы “Вакыт”, “Шура” һ.б. газета-журналлар бу юлда игелекле эшләр башкара. Басмаханәләр челтәре киңәя, күпләп китаплар, рисаләләр, журналлар басыла

башлый. Вакытлы матбугат сәхифәләрендә яңа әсәрләр турында бәяләр, фикер алышулар өчен мөмкинлекләр ачыла. Иҗтимагый фәлсәфи фикернең тиз үсеше дә әдәби тәнкыйтьнең формалашуына уңай йогынты ясый. Менә бу шартлар барысы да тәнкыйтьнең кирәклеген көн тәртибенә куя һәм, ниһаять, Беренче рус инкыйлабыннан соң әдәби тәнкыйть, әдәбият белеменең башка тармакларыннан аерылып чыгып, мөстәкыйль үсә башлый.

Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Г.Камал, Р.Фәхреддин, Г.Баттал, С.Рәмиев, Н.Гасрый, Н.Җамал, Җ.Вәлиди, М.Мәрҗани, Б.Шәрәф, Г.Кәрам һ.б.ларның мәкаләләрендә һәм рецензияләрендә, берьяктан әдәби тәнкыйтьнең предметы, максат-бурычлары, үзбилгеләнү хокукы, фәнни кагыйдәләре, әдәби әсәрне бәяләү принциплары, критерийлары, алымнары, методлары кебек мәсьәләләрне ачыкласалар, икенче яктан, тәнкыйть этикасы, шартлары турында сүз алып баралар.

1910 нчы елларда нәшер ителгән “Шура”, “Аң”, “Мәктәп” һ.б. журналларда матур әдәбият, әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә зур урын бирелү сәбәпле, тәнкыйди фикер камилләшә, тәнкыйтьчеләрнең профессиональ осталыгы үсә.

XX гасыр башында тәнкыйтьнең профессиональ, язучылар, укучылар тәнкыйте кебек төрләре яши. Профессиональ тәнкыйть сыйфатлары Җ.Вәлиди, Г.Кәрам, Н.Хәлфин эшчәнлекләрендә күзәтелә. Язучылар тәнкыйтенең хәлиткеч роль уйнавы татар әдәби тәнкыйтенең үзенчәлеге булып тора. Журнал тәнкыйтенең барлыкка килүе аның сыйфат үзгәреше турында сөйли.

Татар әдәби тәнкыйте XX гасыр башында язучы белән укучы арасында арадашчы ролен үти башлый. Бу дәвер әдәби хезмәтләренә бәхәс рухы, автор, укучылар, оппонент белән фикер көрәшенә корылган сөйләшү рухы хас. Мәсәлән, Ф.Әмирханның “Татар шагыйрьләре”, 1908; Җ.Вәлидинең “Гаяз әфәнде”, 1913, “Татар шагыйрьләре”, 1913; Г.Ибраһимовның “Мөгаллимә”нең Уфада уйналу мөнәсәбәте белән”, 1913 һ.б.

Тәнкыйди карашның беренче яралгылары, адымнары күрсәткәнчә, әдәби тәнкыйть озак вакытлар әсәргә гомуми бәя бирү, авторны мактау яисә хурлау, китапка рекомендация бирү мәгънәсен саклап килә. Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый һәм башкалар әдәби әсәргә аның идея эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше аша якын килә башлыйлар. Әдип иҗатына язучының чорга, заман таләпләренә мөнәсәбәтеннән чыгып тәнкыйть ясала, ягъни әдәби әсәр чынбарлыкның көнүзәгендәге мәсьәләләре тирәсендә уйланулар мәйданына әверелә. Әдәби тәнкыйть мөһим иҗтимагый-милли, фәлсәфи мәсьәләләр буенча кискен бәхәскә керә.

Татар реалистик әдәби тәнкыйтенә нигез салучылардан Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Исхакый, Г.Камал, Вәлиди һ.б.ларның эшчәнлегендә әдәби тәнкыйтьнең төп принциплары, нәфис әдәбиятның тормышка һәм чынбарлыкка мөнәсәбәте, әдәбиятның халыкчанлыгы һәм миллилеге, психологизм һ.б. эстетик категорияләр мәсьәләсе күтәрелә. Һәм дөнья әдәбиятындагы югары идея-эстетик фикерләргә нигезләнеп, милли әдәби хәрәкәт җирлегендә хәл ителә башлый.

Әдәби-мәдәни мәйданга килгән һәрбер яңа фән кебек әдәби тәнкыйть тә, иң беренче нәүбәттә, үз предметын, өйрәнү һәм бәяләү объектын ачыклау, үз билгеләнү хокукы, иҗтимагый вазифасы һәм функцияләре, әдәби барыштагы урыны кебек мәсьәләләрне хәл итәргә алына. XX гасыр башы – гыйльми-фәнни фикер, татар әдәбият нәзариясе дә үз сукмагын салган чор, ягъни әдәби төшенчәләр һәм атамалар турында җитди уйланулар һәм мәгълүм нәтиҗәләргә ирешкән дәвер дә. Әлбәттә, бу гомуми хәрәкәттән тәнкыйди фикер дә читтә калмаган. Милли, әдәби-мәдәни күтәрелештә әһәмиятле роль уйнаган Шәрык һәм Гареб мәдәниятләренең уңай йогынтысы, хәтта бу ике культурологик ориентирның үзара бәхәсе әдәби тәнкыйтьнең мөһим теоретик мәсьәләләрен хәл иткәндә дә сиземләнә. Соңгы елларда татар әдәбият белемендә милли гыйльми-тәнкыйди фикернең, тарихи-әдәби чорларның үсеш закончалыкларын тирәнрәк чагылдырган әдәби-мәдәни бәйләнешләрне тикшерүгә багышланган хезмәтләр язылды.

Мәкаләдә татар әдәби тәнкыйтенең барлыкка килү һәм үсү процессы әдәби багланышлар яссылыгында өйрәнелә һәм шуның белән аның яңалыгы һәм актуальлеге билгеләнә.

XX гасыр башында әдәби иҗатның бу төренә атама булып ике термин: тәнкыйть һәм интикадның фәнни кулланылышта йөрүе күзәтелә. Р.Фәхретдин, Н.Җамал, Н.Гасрый, М.Укмасый һ.б.лар үз практикаларында интикад атамасына мөрәҗәгать итәләр. Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Тукай, Г.Баттал, Г.Сәгъди һ.бларның аерым мәкалә-язмаларында интикад кулланылса да, тәнкыйть терминына өстенлек бирелә. Г.Сәгъди "Әдәбият ысуллары" (1912) китабында милли телебездә интикадка караганда "тәнкыйть" терминының актив файдалануын факт буларак күрсәтеп чыга: "Гәрчә гарәп кагыйдәсенчә дөресе интикад булса да, арабызда күптәннән бирле кулланылып, билгеле вә танылганлыгы өчен тәнкыйть сүзе кулланылырга тиеш".

Тәнкыйди фикернең тамырлары, аның яшәү формалары, үсеш закончалыклары, тәнкыйтьнең төрләре һәм шартлары хакында Шәрык, Ислам мәдәнияте, дин-шәригать кануннарына таянып уйланган Р.Фәхретдиннең "Интикад вә тәган (сүгү, хурлау)" монографик мәкаләсе 1916 елда "Шура" журналында басыла. Автор мәкаләсен тәнкыйть сүзенең килеп чыгышы, мәгънәсе, фәнни һәм гамәли әйләнешкә керүе, аның тамырдаш, мәгънәдәш сүзләре турында уйлануларыннан башлый. Автор "нәкадә" сүзенең гарәпләрдә борынгыдан ук файдаланганлыгын искәртә. "Интикад" термины килеп чыгышы белән "нәкадә" сүзенә барып тоташса да, "тәнкыйть" сүзе турында хәбәр юклыгын әйтә. "Нәкадә" сүзе түбәндәге мәгънәне белдерә: "Лөгать китапларында "нәкадә" сүзе акчаның ялганнарыны дөрестләрдән аерып ташлау дип тәгъриф ителә". Тәнкыйть сүзенең гамәли кулланылышка керүен заман агымына, йогынтысына бәйләп карый. "Һәрхәлдә бүген арабызда мәшһүр булган "тәнкыйть" сүзе "интикад" урынында истигъмал ителә. "Интикад" та яхшы сүзләр һәм дөрест

фикерләрне башкалардан аерып күрсәтү мәгънәсендә йөртеләдер”. Галим үзенең тәнкыйть эшчәнлегендә “интикад” терминына өстенлек бирә.

Гыйльми-нәзари фикердә әлеге терминнарны куллануда төрлелек, аларның мәгънәсе, килеп чыгышлары мәсьәләсенә Г.Ибраһимов “Әдәбият кануннары” (1919) дигән хезмәтендә игътибарга алына: “Тәнкыйть сүзе “нәкыд” матдәсеннән алынган. Лөгать мәгънәсе акчаның чынын ялганыннан аеру димәктер”.

Әдәби тәнкыйтьнең предметы проблемасы белән тыгыз бәйләнгән әдәби тәнкыйть атамасының мәгънәсен аңлау һәм үзләштерү дә ике мәдәният тәэсирендә бара. Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Баттал, М.Укмасиларда үзе латин, борынгы грек цивилизациясе тәэсирендә калыплашкан рус әдәбият белеменең тәэсире зур булса, ә Р.Фәхретдин, Г.Сәгъди һ.б.лар төрки-татар дөньясы озак гасырлар тыгыз бәйләнештә яшәгән, әдәп-әхлак, белем алмашкан Шәрык мәдәниятенә таяналар. Татар галимнәре тарафыннан, мөмкин булганда, милли әдәбият белеменең, шул исәптән әдәби тәнкыйтьнең аерым терминнарын татарча эшләү теләге белдерелсә дә, ике мәдәниятнең ирешкән фәнни казанышларыннан башка бу мәсьәләне хәл итү мөмкин түгеллеге танылa. Мәгърифәтче галим Ш.Мәрҗанинең “Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар” (“Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр”) китабында бу иҗат төренең асылын аңлауда беренче адым ясала. Галим Хисаметдин Мөслиминең “Тәварихе Болгария” китабында бәяләүгә алыну уңаеннан тәнкыйть терминына мондый мәгънә сала: “Бу фәкыйрь, китапның кайбер әһәмиятле урыннарындагы ялгышларны ачып салу, ялганнарны күрсәтү һәм калган урыннарының да илтифатка лаек түгеллеге турында кисәтү теләге белән, китапка алданып, хата һәм бозык фикердә булган бик күп кешеләрне шул карашларыннан, ялгыш ышануларыннан азат итү теләге белән, вакыт сыйдырганча аңлатып бирү эшенә кереште”.

Татар халык шагыйре һәм тәнкыйтьче Г.Тукай Җаектан Казанга каткач, “Тәнкыйть кирәкле шәйдер” (1907) дигән мәкаләсен яза. Әдәби тәнкыйтьнең

кирәклеген татар дөньясында рәсми рәвештә күтәреп чыккан бу мәкаләдә әдәби тәнкыйтьнең предметы, үзенчәлеге нәшер ителгән әсәрнең уңай һәм кимчелекле якларын "матур итеп һәм объективлык белән тәнкыйть итүдә" билгеләнә. Н.Ливановның "Учебный курс теории словесности" китабын иҗади файдаланган" "Нәзарияте әдәбия" ("Әдәбият теориясе") дәреслегендә Г.Баттал рус телендәге терминга мөрәҗәгать итеп, тәнкыйтькә түбәндәге билгеләмә бирә: "Тәнкыйть – критика – бер әдәби әсәргә яки сәнгать (рәсем, музыка – Г.Т.) әсәрләренә бәһа кую, ягъни шуның уңай яки кимчелекләрен күрсәтүне эченә алган мөхакамә "тәнкыйть" дип атала". Г.Ибраһимов та әдәби тәнкыйтьне әдәбият белеменең мөстәкыйль бер тармагы төсен дә карый һәм тәнкыйть атамасы, бу иҗат төренең асылы хакындагы хөкемнәре Г.Баттал фикер сукмагыннан бара: "Әдәбият телендә тәнкыйть дип, әсәрләрне билгеле бер критерий белән үлчәп тикшереп, шуның буенча кыйммәт куюга әйтәләр". Галим тәнкыйтьнең ике мәгънәдә яшәвен күрсәтә. "Хәяттә һәрбер эш, һәрбер хәдис үзенең әһеле тарафыннан тәнкыйть ителә"("Нәзарияте әдәбия") дип тәнкыйтьнең киң аңланылышын билгели. Ә тар мәгънәдә әдәби тәнкыйтькә бүген салынган үзенчәлекне, ягъни әдәби хәрәкәткә, яңа әдәби әсәргә бәя бирүне өстәп, тәнкыйть атамасының шәрехләнүенә яңалык алып килә: "Ләкин гади телдә тәнкыйть дигән сүздән мәйданга чыккан китаплар хакында мөхакәмәне атыйлар".

Әдәби тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләрен ачыклауда шәркый мәдәниятнең идея-эстетик казанышлары, фәлсәфи фикере мәгълүм роль уйный. Р.Фәхретдинов әдәби-мәдәни хәятта тәнкыйди фикернең җитди урынын нигезләп, "Шура" журналындагы әдәби тәнкыйть бүлегенең максат-бурычларын ачыклап, "Тәкъриз (мактау рецензиясе) вә интикад" мәкаләсе белән чыгыш ясый. Р.Фәхретдинов тарафыннан тәнкыйтькә түбәндәге билгеләмә бирелә: "Бер китап вә рисаләне дикъкать илә укып та, язучысыннан бөтенләй катгый караш белән хосусый сурәттә булган дуслык илә дошманлыкны күңелдән тәмам чыгарып, китапны тикшереп, озын вә тирән дикъкатьләү соңында күрелгән яхшы җирләрен яхшы вә яман

җирләрен ялган димәк – интикадтыр”. Билгеләмә алдагыларыннан тәнкыйтьнең шартлары: игътибарлылык, объективлык, принципиальлек белән баетыла.

Әдәби тәнкыйтьнең үзенчәлеге, предметы, аның әдәби-мәдәни хәрәкәттә вазифасы мәсьәләре 1907-1910 елларда татар вакытлы матбугатында нигездә хәл ителә. Бу вакытны әдәби тәнкыйть фәненең калыплашу дәверендәге беренче баскыч дип аерып чыгарырга мөмкин булыр иде. 1910 елларда да бу әдәби иҗат төренең алдында торган бурычларны конкретлаштыру, тәнкыйтьче – укучы – язучы арасындагы мөнәсәбәт, тәнкыйтьнең профессиональлек дәрәҗәсен үстерү мәсьәләләрен уртага салып сөйләшү ихтыяҗы үз актуальлеген югалтмый. Әлеге сыйфади үзгәреш, әлбәттә, дөньяви уку йортларында белем алган Г.Газиз, Г.Рәхим, Г.Кәрам, Н.Хәлфин, Х.Кәримов һәм Җ.Вәлиди кебек теоретик әзерлекле, киң карашлы татар зыялыларының әдәби тәнкыйть мәсьәләләре белән турыдан-туры шөгыльләнә башлавы белән дә бәйле була.

Тәнкыйтьчеләр һәм әдипләр дөнья һәм төрки-татар әдәбиятында шартлы-романтик кулланылышның гаять бай, үзенчәлекле традицияләре булган гөл, бакча, су, яктылык символларына мөрәҗәгать итеп, әдәби тәнкыйтьнең матур әдәбият үсешендә тоткан урыны, тәнкыйтьченең абруе турында үз бәя-хөкемнәре белән уртаклашалар. Мәсәлән, М.Укмаси тәнкыйтьнең вазифасын “алтынның асылын тәхлил иткән кыйммәтен бозып ятучы ялган минераллардан аеру” белән чагыштыра.

Бу еллар гыйльми-нәзари фикере әдәби тәнкыйтьне милли әдәбиятны югары баскычларга күтәрү, Аурупа әдәбиятлары ирешкән биеклекләргә ирештерү чарасы рәвешендә тәкъдим итә: “Әдәбият эчендә тәнкыйть булмаса, Аурупа галәмендә бу кадәр әдәбиятлар барлыкка килмәгән булыр иде. Без казанышларны күрмәс идек. Аурупада нинди генә гыйлем вә фән яки сәнгатькә караган китаплар мәйданга килде исә каләм ияләре тарафыннан мизанга салынып, бакчасына карап акчасы, кыйммәтенә карап хөрмәте биреләдер”[9]. Тәнкыйть үсешенең бу баскычында тәнкыйтьчеләр милли

әдәбиятны рус, Аурупа әдәбиятлары белән чагыштырып, аның идея эчтәлеген яңарту һәм сәнгатьчә эшләнешен камилләштерү хакында уйланалар.

Аерым алганда, Нәҗип Гасрый 1913 елда "Ил" газетасының 14 ноябрь санында басылган "Әдәбиятыбыз тәнкыйтьчегә мохтаҗ" дигән мәкаләсендә тәнкыйтьсез әдәбиятны караучысы булмаган, хуҗасыз гөл бакчасына охшата. "Караучысы булмаган гөл бакчасында бик күп чәчәкләр сусыз, яктылыксыз сулып, корып, кычытканнар тоткан кебек, тәнкыйтьсез әдәбиятта бик күп талантлар әрәм булып, аларның урынын сәләтсез, ни сәнгатькә, ни халыкка файдасы булмаган кешеләр тоталар". Инде бу хөкемдә әдәби тәнкыйтьнең кирәклеге сүз сәнгатенең үсеш ихтыяҗы, укучы зәвыгын тәрбияләү, халык, милләткә файдалылык ноктасыннан ассызыклана. Ул тәнкыйтьне "әдәбиятның үсешендә иң әһәмиятле бер гамәл" дип, тәнкыйть хакында әйтелгәннәрне камилләштерә.

Алга таба әдәби тәнкыйди фикер тәнкыйтькә куелган таләпләр (аны икенче төрле шартлар дип тә атыйлар) тәнкыйть ысуллары, алымнары, таләпләрдән чыгып әдәби тәнкыйтьнең төрләре турында, сөйләшүгә күчә.

Төгәл фәннәрдән аермалы буларак, сәнгать, шул исәптән әдәби әсәрләр дә хис, кичерешләр аша кабул ителә. Хәтта укучының табигате, кәеф-халәте дә китапны аңлауга һәм бәяләүгә мәгълүм дәрәҗәдә йогынты ясый. "Моның белән бәрабәр шигырьләрнең гүзәллеген яки кимчелекләрен ялгыш аңлау кешенең вакытына вә кәефенә дә карый. Чөнки кеше һәрвакытта да бертөрле булып тормый. Шул сәбәптән бу көн безгә бик яхшы тәэсир иткән вә гүзәл тоелган бер шигырь, иртәгесен тәэсир итми вә яхшы күренми башлый. Күңелебез ул шигырь алдында бик илтифатсыз бер хәлдә кала. Хәлбуки шигырь һаман шул бер шигырь була"("Әдәбият ысуллары"), - дип яза әдәбият галиме Г.Сәгъди. Күренә ки, әдәби әсәрне аңлау һәм бәяләүдә субъективлыкка урын кала. Шуңа күрә әдәби тәнкыйтьнең кирәклеге күтәрелгән мәкаләләрдә әдәби тәнкыйтьнең шартлары турында да сүз алып барыла.

Г.Тукай “китаплар, брошюралар, газеталар, журналлар таулар кадәр өелеп барган бер заманда” тәнкыйтькә ихтыяҗ зурлыгын төпле дәлилләр белән исбатлаган “Тәнкыйть – кирәкле шәйдер” (1907) мәкаләсендә әдәби тәнкыйтьнең шартларыннан объективлык, намуслылык, принципиальлек, җаваплылыкны атый. “Тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка” дигән эш алымын кире кагып, тәнкыйтьченең тәҗрибәле, югары әхлаклы, талантлы иҗат кеше булуына зур әһәмият бирә: “Ләкин тәнкыйть итүченең дә кем очрады шул булуы тагы ярамыйдыр. Тәнкыйтьче булыр өчен, әлбәттә, үзләре дә әдәбият галәмендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле вә әхлаклы адәм булуы таләп ителә. Югыйсә үз файдасын күзәтеп тәнкыйть итүчеләр күптер”.

Алда әйтелгәнчә, 1910 нчы елларда язылган тәнкыйть мәкаләләре куелган мәсьәләләрнең киңлеге, югары дәрәҗәдә хәл ителеше белән характерлана. 1911 елда Җ.Насыйп “Осуле интикад” (“Интикад ысуллары”) дигән язма белән “Йолдыз” газетасының 1911 ел 15 август санында чыгыш ясый. Анда әдәби тәнкыйтьнең Ватанга һәм татар милләтенә хезмәт итәргә тиешлеге хакындагы фикер мәкаләнең башыннан алып ахырына кадәр кызыл җеп булып сузыла. Тәнкыйть ителәчәк китапны башыннан алып ахырына кадәр дикъкать белән уку;төрле яктан тикшереп хөкем чыгару әдәби тәнкыйтьнең төп шарты, ысулы итеп күрсәтелә. Җ.Насыйп игътибар ителергә тиешле икенче дәрәҗәдәге шартларны тәкъдим итә һәм алда ассызыкланган таләпләр түбәндәгеләр белән тулыландырыла: 1) әдәби әсәрләрнең Ватан һәм милләт темаларын гәүдәләндерүен, мәнфәгатьләрен чагылдыруны ачыклау; 2) язучының теманы гәүдәләндерүдә, әсәрне оештыруда, аның композициясен төзүдә уңышын тикшерү; 3) язучының стиленә , әсәр теленә җитди анализ ясау”.

М.Укмасиның “Интикад” исемле мәкаләсе шушы рухта язылган. Күтәрелгән мәсьәләләре, фикер агышы, бәя-хөкемнәренең охшашлыгы бер-берсе белән берләштергән ике язмада да тәнкыйть шартлары мәсьәләсе куела. М.Укмаси әдәби тәнкыйть шартларын яңа сызык белән баета. Ул аларны татар әдәбиятын матуррак, нәфисрәк, камилрәк итү яссылыгында карый.

Шушы язмада ук тәнкыйтьчеләр тәрбияләү, аларны үстерү мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Автор камил тәнкыйтьчеләрне “бриллиантлар”га тиңләп, аларның бүгенге көндә аз булуларын әйтеп чыга.

Билгеле булганча, 1910 елларда мәктәп-мәдрәсәләрдә татар әдәбияты фән буларак укытыла башлый. Шушы уңайдан укучылар, шәкертләр өчен татар әдәбиятыннан дәреслекләр, хрестоматияләр языла. Әдәбият теориясе, татар әдәбияты тарихын яктырту белән бергә әдәби тәнкыйтькә дә махсус бүлек багышлана. “Татарның мәктәп – мәдрәсәләренә дә инде татар әдәбиятын аерым бер кирәкле нәрсә, аерым фән итеп кергезү хәрәкәте кузгалган иде, - дип яза Г.Сәгъди. – Татар әдәбиятын мәктәпләрдә укыту, тикшерү эшләре башлану белән бергә һәм бәлки шуның нәтиҗәсе булып, бу әдәбиятны, аның әдип-шагыйрьләрен тәнкыйтьтән үткәрү хәрәкәте көчәя башлады. Әдәби тәнкыйтькә ихтыяҗ, аны кирәксенү, аны иҗтимагый-әдәби хәяттә иң кирәкле бер нәрсә дип тану гомумиләшә барды”(“Әдәбият ысуллары”). Г.Сәгъди “Әдәбият ысуллары” китабында әдәби тәнкыйтьнең шартларын бер системага салырга омтылып, сигез шартын билгели: объективлык; аек акыл һәм сәламәт фикергә ия булу; әдәби, иҗтимагый фәннәрдән, милләт һәм мәдәният тарихыннан хәбәрдарлык; хис әсире булмау; әсәрең темасы һәм эчтәлеге белән тирән танышлык; тәнкыйтьнең максатын аңлап, суык канлы, батыр йөрәкле һәм гүзәл әхлак иясе булу; тәкълид богавы белән богауланмау; дәрес китабы булганда, тәнкыйтьченең укыту һәм тәрбия ысуллар белән хәбәрдарлыгы.

Р.Фәхретдиннең 1916 елдагы “Интикад вә тәган” мәкаләсенең башлам өлешендә шәригатьтә һәм мөселманнарда тәнкыйтькә караш һәм мөнәсәбәт турында киң мәгълүмат бирелә. Шунлыктан ул тәнкыйтьнең шартларын язганда да, шәригать кануннарының гомумкешелек характерыннан, әхлакый кагыйдәләреннән чыгып эш йөртә. Р.Фәхретдин тәнкыйтьнең шартларын тәнкыйтьнең бер төре булган “тәган”гә (сүгү, хурлау, мыскыллау) илткән сәбәпләр белән үреп бирә. Галим тәнкыйтьнең игътибар үзәгендә булырга тиешле сигез шарт хакында яза: 1) гүзәл касд, ягъни яхшы ният-максат булу.

Галим карашынча, изге ниятле интикадлар шәригать каршында саваплы эш, ә кешенең гаепләрен, хаталарын гына табып, аны халык күзеннән төшерү максаты белән тикшерүләр шәригатьтә хәрам санала; 2) Тәнкыйть ителә торган әсәрнең дәрәҗәсен белү, аның проблематикасы белән танышлык; 3) тәнкыйть ителәчәк мәкаләне, әсәрне яки хезмәтне кыскача аңлатып бирү; 4) тәнкыйтьченең мәгълүматлылыгы һәм хәбәрдарлыгы әсәр һәм мәкалә авторыныкыннан ким булмау; 5) фикер хөрлегенә каршы булмау; 6) тәнкыйтьченең нигезе акыл белән шәригать, хис һәм ышаныч, дөрес хәбәр булу; 7) тәнкыйть ителәсе маддәләрнең исбатлы булуы; 8) тәнкыйтьченең исеме яшерелмәү, ягъни мәкалә авторының ачыклыгы ("Интикад вә тәган"). Күренә ки, Р.Фәхреддин кешелек җәмгыятенең нигезе булган һәм борынгы заманнардан, гасырлардан гасырларга күчеп, ислам мәдәниятеннән, Коръәннән килә торган гомумкешелек кыймммәтләренә, әхлакый кануннарга басым ясый.

Әдәби тәнкыйтьнең шартларын билгеләүдә икенче юнәлеш Г.Ибраһимов, Г.Баттал хезмәтләрендә күзәтелә. Тәнкыйтьнең предметы, аның шартлары һ.б. гыйльми-нәзари төшенчәләрен шәрехләүдә галимнәрнең яңа сукмак булдыруларының сәбәпләре, аларның, беренчедән, үзгә күзаллаулары, икенчедән, Аурупа-рус әдәбият белеме йогынтысында булулары белән аңлатыла. Алар Ауропа-Рус әдәбият белеме терминологиясенә мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, ике галим дә тәнкыйтьне үзе үк фикерне мантыйкый дәлилләр белән ачуны һәм исбатлауны таләп иткән мөхакәмәнең бер төре итеп яктырталар. Алга таба тәнкыйть, аның предметы һәм шартлары шушы караш ноктасыннан чыгып аңлатыла һәм билгеләнә. Алар кагыйдә, кануннар дигән төшенчәләр белән эш итсәләр дә, биредә әдәби тәнкыйтьнең шартлары, аңа куелган таләпләр күздә тотыла.

Г.Баттал "Нәзарияте әдәбия" (1913) китабында рус әдәбияты белемендәге терминга мөрәҗәгать итеп, әдәби әсәрне тәнкыйть иткәндә таянылырга тиешле таләпләрне, кагыйдәләрне "критириум" дип атый. "Критериум – әдәби әсәр вә сәнгать әсәрләре, аларның буйсынырга тиеш

булганы кагыйдә вә кануннарга таянып тәнкыйть ителәләр. Билгеле бер әсәрне тәнкыйть иткәндә тәнкыйтьченең кулланма итеп токкан кагыйдә вә кануннарның җыелмасы “критериум” дип атала”. Галим әдәби тәнкыйтьнең фәннилегенә өстенлек биреп, аны “Гыйльми яки фәлсәфи китаплар” бүлеге эчендә карый, шуңа күрә мантыйкый һәм аналитик фикерләүгә куелган таләпләр белән әдәби әсәрне тәнкыйтьләү үлчәмнәре үзара үрелеп китә. Бүгенге тәнкыйть теориясенә караган хезмәтләрдә, тәнкыйть текстының үзгә табигате турында сүз алып барылып, аның матур әдәби тексты белән фәнни текст арасында торуы билгеләнә. Ул әдәби текст кебек күпмәгънәлелеккә йөз тотмаса да, фәнни язмадагы кебек фәнни төгәллек белән аерылып тормый .

Г. Баттал әдәби тәнкыйтьнең түбәндәге үлчәмнәрен аерып чыгара: тәнкыйть объектының тиешле кагыйдә һәм кануннарга туры килүе; замана фәннәре вә сәнгатенең теорияләре буенча әсәргә куелган таләпләргә җавап бирү; китаптагы төп фикер вә икенче дәрәҗәдәге фикерләрнең үзара гармониясе; әсәр темасының ачык вә тулы чагылышы; фикер эзлеклелеге һәм әсәр элементларының максатка ярашлы итеп урнаштырылышы; китап стиленең тиешле нәзария һәм кагыйдәләргә туры килүе .

Г.Ибраһимов та үзенең әдәби тәнкыйть фәне турындагы нәзари эзләнүләрен 1916 елда Казанда “Сабах” матбагасында дөнья күргән “Әдәбият кануннары” (“Әдәбият дәресләре”) (1919) дигән хезмәтендә бер бүлекчәгә туплап урнаштыра. Әдәби тәнкыйтьне фәнни нигезгә эшләргә омтылган Г.Ибраһимов әдәби тәнкыйтьнең шартлары, аңа куелган таләпләр сүзләре урынына кагыйдәләр, кануннар дигән төшенчәләргә мөрәҗәгать итә . Ул инде әдәби әсәргә бәя бирүнең үлчәүләре турында сүз алып барып, “мизан” төшенчәсен фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә: “Бер әсәрне яки бер язучының барлык әсәрләрен тикшереп, аларга кыйммәт куйганда, тәнкыйтьченең шулардагы җитешкән яки җитешмәгән якларны билгеләүдә үзенә юл күрсәткән шул канун вә нәзарияләре “тәнкыйтьнең мизаны” – яки критериум дип атыйлар”.

Г.Ибраһимов тарафыннан “тикшерелгән әсәрнең эч йөзен, асылын” ачып бирү, әсәр теле, өслүбе, план вә мөндәриҗәсе төп уйны ачып җитә алып – алмавы, хәяткә мөнәсәбәте мәгълүм мизаннар ярдәмендә бәяләнергә тиешле яклар буларак аерып чыгарыла. Бәя, шәрехләүнең объективлыгын, беръяклы гына булмавын күздә тотып, тәнкыйтьне “ике йөзле хәнҗәргә тиңли”. “Тәнкыйть ике йөзле үткен хәнҗәр булырга тиеш. Бу хәнҗәрнең бер ягы әсәрнең эчендәге җәүһәрләрне казып чыгарса, икенче ягы аның чүбекләрен табып күрсәтү”(“Әдәбият кануннары”).

XX йөз башы әдәби – тәнкыйди фикерендә әдәби тәнкыйтьнең төрләрен аерып чыгару, аларның үзенчәлекләрен билгеләү юнәлешендә фикер алышу башлана һәм татар әдәби тәнкыйтенә генә хас төрләр дә аерып чыгарыла. Әдәби тәнкыйтьнең әдәби әсәргә рекомендация бирү, әдәби әсәрнең “уңай” һәм “кире,” “җитешкән вә җитешмәгән” якларына бәя бирү вазифасы милли җирлектә аның ике: **“иҗаби” (уңай)** һәм **“сәлби” (кире)** төрләрен күрсәтүгә юл ача. “Әсәрнең яхшы ягын күрсәткән тәнкыйтьләр иҗаби тәнкыйть дип, җитешмәгәнен күрсәткәннәре сәлби тәнкыйть дип атала” (“Әдәбият кануннары”). (. Дөрес, биредә кире тәнкыйтьнең әдипкә ярдәм итү, әсәрнең кимчелекле якларын бетерүдә юл күрсәтү сыйфаты калкытып куела: “Сәлби тәнкыйтьләр әсәрнең җитешмәгән якларын күрсәтү белән язучының үзен дә, башкаларны да шул хатадан, шул кимчелектән сакланырга юк эзләргә, шулай итеп төзәлүгә сәбәп булалар”.

1910 елларда теоретик тирәнлек һәм карашлар киңлеге хас тәнкыйть мәкаләләре белән чыгыш ясый башлаган Г.Гобәйдуллин. Г. Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр”енә язылган “Яшь әдәбиятыбызда” – “Яшь йөрәкләр” дигән проблемалы мәкаләсендә бу төр иҗатта субъективлыкка, шәхсилектә урын калдырылу аның табигатеннән килә дигән карашны яклый һәм ул **“шәхси тәнкыйть”** дигән атама тәкъдим итә. Р.Фәхретдин әдәби әсәрнең тәнкыйть ителү шартларына, рухына, тәнкыйтьченең бәя – карашларына таянып ике төрле: **дөрес (хакыйкый**) (“Интикад вә тәган”)] тәнкыйтьне һәм **тәган (тагын**) аерып куя. Ул Аурупадагы тәнкыйть белеменә нигезләнеп дөрес

тәнкыйтьнең асылы турында уйлана. Моның өчен “салкын кан, тирән мәгълүмат вә алар өстенә дә намуслы вә нәзакәтле һәм дә тәрбияле һәм культуралы булу” кирәклеген ассызыклый. Авторның бәя – хокемнәреннән күренгәнчә, хакыйкый тәнкыйть әдәби әсәрне бәяләүнең гыйльми, терәк кануннарына таянып түгел, ә әхлакый яссылыктан чыгып нигезләнә. Күренә ки, әдәп мәйданында, шәригать каршында дөрес, гамәли һәм файдалы эш саналып тәганга каршы мәгънәгә йөргәнен дөрест интикад дип карый. Язманың соңгы өлешендә, Р.Фәхретдин “дөрес” тәнкыйть турындагы уйлануларыннан тәганга (тагын сүгү, хурлау, мыскыллау) күчә.

Тәган (сүгү, хурлау, мыскыллау мәгънәсендә) – әдәби тәнкыйтьнең интикадка каршы куелган бер төре. Әдәби тәнкыйтьнең мөһим шартларыннан берсе – объективлык, шәхси мөнәсәбәтләрдән, материалдан өстен булу үтәлмәгәндә, иҗтимагый хәят, әдәбият үсеше өчен зарарлы күренеш булган тәгангә юл ачыла. Бу термин Р.Фәхреддин тарафыннан фәнни әйләнешкә кертелеп, ул тәган бәласенең ислам дөньясында гына түгел, бәлки бөтен Аурупада киң таралганлыгын әйтеп үтә.

Галим асылын субъективлык, шәхси дошманлык билгеләгән тәган кылуның наданлык һәм аңламау; хак сүзнең тәнкыйтьче тискәре мөнәсәбәттә торган кеше тарафыннан әйтелүе; бер фикернең кеше күңеленә электән үк салынган булуы; үз-үзеңне генә сөю, үзеңә изге итеп карау; хөсетлелек кебек сәбәпләрен күрсәтә.

“Балалык” дәверен үткән тәнкыйди фикернең Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Исхакыйлар заманында әдәби әсәргә аның идея-эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан бәя бирә башлый. Тәнкыйди фикер бу елларда үзенең тәүге адымнарын ясый башлаган татар әдәбияты нәзариясенең вазифасын, ягъни яңа татар әдәбиятын бәяләүне, аның үсеш юнәлешен билгеләүне үз өстенә ала. “Ул чын мәгънәсендә әдәбият теориясе калыплашсын өчен кирәк булган үтә әһәмиятле шартны үти: нәзари фикерне милли әдәби барыш, аерым әдәби әсәр белән бәйләп куя. Бары тик әдәби тәнкыйть кенә башкара ала торган вазифаны җиренә җиткерә”(“Әдәбият кануннары һәм заман”).

Әдип иҗатына язучының чорга, заман таләпләренә мөнәсәбәтеннән чыгып тәнкыйть ясала, әдәби әсәрнең чор, милли хәят, чынбарлык белән бәйләнеше, анда тормыш дөреслеге чагылу төп кагыйдә буларак тәкъдим ителә башлый. Татар реалистик әдәби тәнкыйтенә нигез салучылардан Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Исхакый, Г.Камал һ.бларның эшчәнлегендә әдәби тәнкыйтьнең төп принциплары, алымнары, чаралары нәфис әдәбиятның халыкчанлыгы һәм миллилеге һ.б. мәсьәләләр күтәрелә. Матур әдәбиятның реаль чынбарлыкны тулы һәм дөрес чагылдыру хасияте бары тик җанлы һәм тормышчан образларда, табигый типлар аша гына чагыла алуы бу чор тәнкыйди фикере үзәгенә куела. Тәнкыйтьчеләр әсәрләрдә сурәтләнгән милли картиналар, күренешләрдән чыгып, әдәби образның гомумилеге һәм индивидуальлеге турында, социаль типлар сүз алып баралар.

Тәнкыйтьчеләр әдәби әсәргә бәя биргәндә, Аурупа-рус әдәбият белемендә калыплашкан культура-тарих мәктәбе кагыйдәләренә: тирәлек - раса (милләт, кавем) – моментка таяналар. Һәм шушы җирлектә **реалистик** әдәби тәнкыйть барлыкка. Дөрес, әле бу заманда “реалистик тәнкыйть” термины фәнни әйләнештә күзәтелми. Беркадәр соңрак, төгәлрәге 1920 елларда Г.Сәгъди Ф.Әмирхан тәнкыйди эшчәнлегендә реалистик тәнкыйть сыйфатлары чагылуын билгели, аны реалист тәнкыйтьче дип атый: “Ф.Әмирхан үзенең беренче әдәби-фикри эшчәнлеге адымында бер сәнгатьче – сүз сәнгатьчесе булудан бигрәк, татар буржуазиясенең “карчыга күзле” реалист бер тәнкыйтьчесе булды” (“Бездә әдәби тәнкыйть”).

1910 еллар татар эстетик фикеренең икенче бер зур казанышы булып сәнгатьчә фикерләүнең реалистик төре белән янәшә романтик төре, ә соңгысы җирлегендә **романтик** тәнкыйтьнең формалашуы тора. Эстетик (романтик) тәнкыйть татар әдипләренең, галимнәренең гыйльми-нәзари эзләнүләре, төрле теоретик концепцияләрнең, Рус-Ауропа әдәбият белемендәге психологик мәктәпнең тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә. Аның аерым үзенчәлекләре Г.Исхакый, Җ.Вәлиди, Н.Думавиның иҗат практикасында урын алса, Г.Ибраһимовның бу еллардагы мәкалә һәм

хезмәтләрендә (“Татар шагыйрьләре”, 1913, “Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз” (1915)) романтик тәнкыйтьнең концепциясе теоретик яктан эшләнә.

Билгеле булганча, әдәби материалны тикшерү һәм бәяләү өчен чаралар, кагыйдәләр, методлар һәм алымнар кирәк. Әдәби тәнкыйтьнең жанрлар системасы формалашу да ике мәдәният тәэсирендә бара. Гарәп, фарсы классик әдәбияты йогынтысында булган урта гасырларда ук гыйльми-тәнкыйди фикер үз жанрларын калыплаштыру омтылышы ясый. Бу вакытта шигъри әсәрләрдә каләмдәшләре әсәрләрен бәяләү, тамгалау традициясе яшәгән. Шулай ук **шәрех** (аңлатма), **хашияләр** (китап читендәге язма) язу гадәте дә киң тарала. Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән **тәгъзия** дә үзенең тамырлары белән үзебезнең борынгы бабаларыбызның мәдәни – тарихи культурасына барып тоташа. XIX гасырның соңгы чирегендә Рус-Ауропа мәдниятенә йөз белән борылган татар әдәби-гыйльми фикерендә **мәкалә**, **рецензия** әдәби тәнкыйть жанрлары буларак формалашу процессы кичерә. Аерым алганда, мәгърифәтче галим К. Насыйриның өстәл календарьларында, әдәби-гыйльми эшчәнлегендә Бакчасарайда И. Гаспралы нәшер иткән “Тәрҗеман” газетасы битләрендә рецензия, мәкалә, хәбәрнең тәүге үрнәкләре урын ала.

Әдәби тәнкыйтьнең жанр ягыннан үсү, баю баскычы XX гасыр башларына туры килә. Гыйльми-тәнкыйди фикердә жанрлар мәсьәләсе теоретик проблема буларак көн тәртибенә куела. Ф. Әмирхан, Г.Тукай, Г,Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Н.Хәлфин һ.б. ларның тәнкыйди эшчәнлегендә рецензия жанры, аның төрле формалары: монорецензия, күзәтү рецензиясе, кыска рецензия, аннотация, мәкалә – рецензия һ.б.лар әдәби тәнкыйди мәйданда тулы хокук яулый. Г. Ибраһимов “Әдәбият кануннары”. Өченче басма (1919) дигән китабында рецензия, рәддия һәм мәкаләне әдәби тәнкыйтьнең жанрлары буларак карый. Ул рецензиягә түбәндәге билгеләмәне бирә: “Мәйданга чыккан бер әсәр, тыңланган концерт, күрелгән спектакль хакында вакытлы матбугатта, дәлилләр белән исбатка керешелмичә, кыска рәвештә тәэсир вә мөляхәзәне бәяннән гыйбарәт булган мәкаләләр

“рецензия” дип атала”. Ә рәддияне, аның карашынча, “сәлби тәнкыйтьләргә мөхәррирнең үзе яки башка берәү тарафыннан бирелгән җаваплар” барлыкка китерә. Алга таба бу жанрның рус әдәбият белемендә **антикритика** дип аталуы искәртелә. 1910 еллар татар әдәби тәнкыйтендә аналитик фикер тирәнәю сәбәпле, рецензия жанрыны караганда, мәкалә активлаша төшә. Ләкин шул ук вакытта рецензия, мәкаләнең жанр сыйфатларын үзенә алып, аңа тартымлык күрсәтә. Бу тәнкыйди фикернең үз өстенә тагын да катлаулырак вазыйфалар алуы белән аңлатыла.

XX йөз башының аерым тәнкыйтьчеләре эшчәнлегендә Шәрык дөньясыннан үтеп кергән терминнардан **тәкъриз** (рецензия), **мөрасәлә** (хат), **мөхабәрә** (хәбәр) фәнни әйләнештә йөри. Әмма бу жанрлар атамалары заман сынавын үтә алмыйча төшеп калалар. Тәнкыйди жанрларның төрлелеге Ф.Әмирхан, Г. Тукай, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди иҗатларында күзәтелә.. 1910 елларда әдәби тәнкыйтьтә, Шәрык классикасының һәм Ауропа-рус әдәби – мәдәни мохитләренең уңай тәэсирен тоеп, милли җирлектә формалашкан тулы, бербөтен жанрлар системасы хасил була: рецензия, мәкалә, аларның төрле формалары, монорецензия, күзәтү рецензиясе, рецензия-мәкалә, программ мәкалә, проблемалы мәкалә – фельетон, әдәби портрет, еллык күзәтү, хат, әдәби – тәнкыйди диалог, тәгъзия, хәбәр һ.б.

Татар әдәби тәнкыйте XX гасыр башында тәмамланган бер эстетик система рәвешен алып, гарәп, фарсы. Рус Ауропа мәдәниятләренең тәэсирендә клыплаша., төрле әдәби-нәзари концепцияләр хакында бәсәсләшеп, үз үсеш сукмагын булдыра. Ул әдәби барышны оештыра һәм шәрехли. Матур әдәбиятның үсеш тенденцияләрен, закончалыкларын барлый һәм аның үсеш юнәлешен билгели. Ул гына түгел, нәкъ менә әдәби тәнкыйть әдәбият тарихы һәм татар нәзари фикере калыплашуга җирлек әзерли; әдәбият белеменең бу тармаклары әдәби тәнкыйть эчендә барлыкка килеп, сан һәм сыйфади үсеш кичерәләр.

XX гасыр башында татар әдәби тәнкыйте әдәби барышны оештыра һәм шәрехли. Матур әдәбиятның үсеш тенденцияләрен, закончалыкларын барлый

һәм аның үсеш юнәлешен билгели. Ул гына түгел, нәкъ менә әдәби тәнкыйть әдәбият тарихы һәм татар нәзари фикере калыплашуга җирлек әзерли; әдәбият белеменең бу тармаклары әдәби тәнкыйть эчендә барлыкка килеп, сан һәм сыйфади үсеш кичерәләр.

Әдәбият (Использованнная литература)

1. Сәгъди Г. Әдәбият ысуллары. – Оренбург: Вакыт, 1912. – 55 б.
2. Фәхретдин Р. Интикад вә тәган: интикадмы? тәнкыйтьме? Интикадның файдасы. “Шура”. – 1916. - № 16. – 391-393 б.
3. Ибраһимов Г. Әдәбият кануннары. Теория словесности. Өченче басма. – Казан: Дәүләт типографиясе, “Сабах”. 1919. - 126 б.
4. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – 415б.
5. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: татар. кит. нәшр., 2008.- 254 б.
6. Заһидуллина Д. Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариятенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 271 б.
7. Баттал Г. Нәзарияте әдәбия. – Казан: Өмет, 1913. – 104 б.
8. Фәхретдинов Р. Тәкъриз вә интикад // Шура. – 1908. - № 1. - 24. – 26 б
9. Укмаси М. Интикад // Йолдыз. – 1911. – 7 июль.
10. Гасрый Н. Әдәбиятыбыз мөнәкъкыйдкә мохтаҗ // Ил. – 1913. – 14 ноябрь.
11. Тукай Г Сайланма әсәрләр. Ике томда. 2 том / Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 132 б.
12. Насыйп Җ. Осуле интикад (“Интикад ысуллары”) // Йолдыз. – 1911. – 15 август
13. Сәгъди Г. Бездә әдәби тәнкыйть (Үктәбернең ун еллыгына) – Казан: Безнең юл, 1927. – 22 б.
14. Фәхретдин Р.Интикад вә тәган (интикадның шартлары) // Шура. – 1916. №17. – 410-412 б.

15. Закирзянов А.Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон.XX – нач. XXI) ._ Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.
16. Фәхретдин Р Интикад вә тәган (дөрест вә хакыйкый “интикад” – интикад ителмеш кешенең вазифасы) // Шура. 1916 - №18. – 433-435 б.

Вопросы и задания для самопроверки и контроля (Үзконтроль өчен сораулар һәм биремнәр):

1. Әдәби тәнкыйтьнең фән буларак сыйфатларын билгеләгез.
2. Әдәби тәнкыйтьне формалаштыруга зур өлеш керткән тәнкыйтьчеләрне санагыз.
3. Ни өчен татар әдәби тәнкыйтендә язучылар тәнкыйте өстенлек итә?
4. Тәнкыйди язмаларда субъективлык күзәтелүнең сәбәпләрен билгеләгез.
5. Габдулла Тукай тәнкыйтьне нинди яңа жанрлар белән баета.
6. “Шура” журналының татар журнал тәнкыйтен барлыкка китерүдәге роле.
7. Татар әдәби тәнкыйте формалашуга нинди мәдәниятләр йогынты ясый?
8. “Татар нәзари фикерендәге эзләнүләрнең татар әдәби тәнкыйтенә йогынтысы” дигән темага түгәрәк өстәл оештырыгыз.

ТЕМА 4 Реалистик һәм романтик әдәби тәнкыйть (Ф.Әмирхан һәм Г.Ибраһимовлар тәнкыйте мисалында).

Аннотация.

XX гасыр башында әдәби тәнкыйть әдәби әсәрне тикшерү һәм бәяләүнең үлчәмнәрен, кагыйдә-кануннарын, фәнни нигезләрен ачкан концепцияләрне эзләү юлына чыга. Татар әдәби тәнкыйтенең теоретик нигезен формалаштыруда ике культурологик юнәлеш – Гареб һәм Шәрекъ мәдәниятләренең йогынтысы зур була. Эчке иҗтимагый һәм мәдәни факторлар реалистик һәм романтик тәнкыйтьләрнең формалашуына китерә. Г.Исхакый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди һ.б. тәнкыйтендә әлеге юнәлешләрнең фәнни концепциясенә нигез салына.

Ключевые слова (төп төшенчәләр): реалистик, романтик, тормыш дөреслеге, заман, чор картинасы, кеше рухы,эстетик кануннар.

Методические рекомендации по изучению темы (Теманы үзләштерү өчен методик рекомендацияләр):

-Лекция материалында тәнкыйтьчеләр эшчәнлеге мисалында XX гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә күзәтелгән реалистик һәм романтик тәнкыйтьләр һәм аларның төп сыфатлары хакында күзаллау булдырыла;

- Студентларга мөстәкыйль эш сыйфатында бирелгән темалар буенча презентацияләр үткәрү өчен материаллар тупларга, иҗади һәм контроль эшләр эшләргә, түгәрәк өстәлгә материал сайларга һәм төрле актуаль темаларга чыгышлар ясарга әзерләнергә тәкъдим ителә,

- Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максаты белән һәр темага сораулар һәм биремнәр бирелә.

Источники информации (Информация чыганаклары):

1. Гыйлаҗев Т. Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900-1925). Методик кулланма – Казан, 1999. – 42 б.

2. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.

3. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 254 б.

4. Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). – Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.

5. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман / Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары / Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 271 б.

6. Мәрданов Р. “Шура” журналы (1908-1917): әдәбият мәсьәләләре / Р. Мәрданов. –Казан: Рухият, 2001. – 152 б.

7. Мәһдиев М.С. Реализмга таба. XXйөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре / М.С. Мәһдиев. – Казан: Университет нәшрияты, 1989. – 154 б.

8. Хәсәнов М.Х., Мөхәммәдиев Р.С. Әдәби тәнкыйть һәм эстетик фикер мәсьәләләре / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3-т. / XX гасыр башы / М.Х. Хәсәнов, Р.С. Мөхәммәдиев. – Казан, 1986. – 490-505 б.

9. Мухамадиев Р.С. Проблемы формирования татарской литературной критики (1900-1917) / Р.С. Мухаммадиев – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – 143 с.

10. Харрасова Р.Ф. Әдәби тәнкыйть теориясе. Махсус фән программасы / Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт университеты, 2007.- 32 б.

Интернет-ресурсы (Интернет-ресурслар):

1. dic.academic.ru/dic.nsf/bse/104011/**Литературная**
2. bse.sci-lib.com/article070749.html
3. http:// kitap.net.ru
4. kitapxane.at.tt
5. tatar.org.ru и др.

Глоссарий (Сүзлекчә):

Әдәби йогынты – бер әдәби күренешнең (факт, әсәр яисә аның компоненты, әдип иҗаты, әдәби процесс, идея-эстетик карашлар, милли әдәбият яисә фольклор,аерым чор әдәбияты һ.б.) икенче бер әдәби күренешкә тәэсир итүе, яңалык тууга этәргеч ясавы, сәбәпче булуы, катнашуы.

Реалистик тәнкыйть - әдәби әсәргә бәя биргәндә, Аурупа-рус әдәбият белемендә калыплашкан культура-тарих мәктәбе кагыйдәләренә: тирәлек - раса (милләт, кавем) – моментка таянылган әдәби тәнкыйть төре.

Романтик тәнкыйть – язучы әсәрендә кеше рухы, күңел дөньясы ни рәвешле чагылыш табу билгеләнгән, яшәешнең психологик җирлеге ачылган, әхлакый-рухи кыйммәтләр барланган, романтик сурәтлелек һәм образлылык хас булган тәнкыйть.

Укучылар тәнкыйте – китап укучыларның үз заманы әдәби процессына, аерым әсәрләргә бәйле карашлары белән уртаклашуга нигезләнеп, нигездә әсәрнең итҗтиагый-милли кыйммәтен ачкан, ихласлылык, укылган әсәр нигезендә туган хисси уйлануларга, шәхси кичерешләргә бай булган тәнкыйть.

Эстетик тәнкыйть – концепциясен сәнгатьнең мәңгелек һәм үзгәрешсез законнары тәшкил итеп, әдәби әсәрнең матурлык, яхшылык, дөреслек кебек эстетик кыйммәтләре ассызыкланган тәнкыйть

Вопросы для изучения (Өйрәнү өчен сораулар):

1. XX гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә барлыкка килгән тәнкыйтьнең юнәлешләре һәм агымнары, аларның барлыкка килү сәбәпләре.
2. Г.Исхакый һәм Ф. Әмирхан эшчәнлекләрендә реалистик тәнкыйть чагылышы. Аның иҗтимагый-милли җирлеге.
3. Г.Ибраһиов эшчәнлегендә романтик тәнкыйть формалашу. Аның сәбәпләре.
4. Г.Ибраһимовның күренекле “Татар шагыйрьләре” хезмәте.

Лекция №4. **Реалистик һәм романтик әдәби тәнкыйть (Ф.Әмирхан һәм Г.Ибраһимовлар тәнкыйте мисалында).**

Тәнкыйть теориясенә караган төшенчәләрдән – әдәби тәнкыйть юнәлешләре катлаулы проблемалардан санала. Аларны ачыклау гаять мөһим, чөнки яңа әдәби әсәрнең әһәмиятен, аларның чор сәнгатенә керткән өлешен һәм киң планда әдәбият-сәнгатьнең җәмгыятьтәге урынын дөрес аңлау, бәяләү, авторның нинди үзенчәлеке алымнар кулланып, нинди детальләргә мөрәҗәгать итүен ачыклау мөһим. Матур әдәбияттагы әдәби юнәлешләргә, әдәби агымнарга нисбәтле үзенчәлекләр әдәби тәнкыйтьтә дә чагылыш таба. Тәнкыйтьче әдәби әсәргә бәя бирүбарышында анда өстенлек иткән сәнгати фикерләүне, аңа хас сыйфат-билгеләрне ачыклый, үзе яклаган позиөиядән чыгып, аларны аңлата һәм бәяли.

Татар әдәби тәнкыйте XX гасыр башында, күптөрле тышкы һәм эчке факторларга нисбәтле, яңа чор әдәби проөессын, шул исәптән аерым әсәрләрне аңлау-бәяләүнең үлчәмнәрен. Фәнни нигезләрен ачкан эстетик концепцияләрне эзләү юлына чыга. XX гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә әдәби тәнкыйтҗнең реалистик һәм романтик төрләре күзәтелә. Г.Исхакый, Ф Әмирхан тәнкыйтьләрендә реалистик, ә Г.Ибраһимовта романтик тәнкыйть нигезләнә.

Ф.Әмирханның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге

Ф.Әмирхан – татар әдәби тәнкыйтенә нигез салучыларның берсе. Ул киң карашлы, нечкә зәвекълы, эрудицияле тәнкыйтьчеләрдән санала. Бүгенге көндә кызганычка каршы, аның әдәби тәнкыйди эшчәнлеге тулысынча өйрәнелмәгән. Социаль- икътисади фәннәрне яхшы белгән Ф.Әмирхан тәнкыйть эшчәнлегендә тарихилык принцибыннан чыгып эш итә. Тарихилык ул – әдәби күренешне башка күренешләр белән тыгыз бәйләнештә, диалектик бәйләнештә карау. Г.Сәгъди үзенең 1927 елда язылган “Бездә әдәби тәнкыйть” хезмәтендә аңа зур бәя бирә. Үткен каләмен, таләпчән, принципиаль тәнкыйтен күздә тотып, “карчыга күзле” тәнкыйтьче дип атый.

Тәнкыйтьче бу төр эшчәнлегендә яңа реалистик татар әдәбиятына нигез салган Г.Исхакый, Г.Тукай, Г.Камал, Г.Коләхмәтов, М.Гафури һ.б.лар белән эш итә. Аларның әдәби әсәрләре басылып чыгу уңаеннан дөнья күргән мәкаләләрендә, рецензияләрендә әдәбиятның иҗтимагый роле, чынбарлыкка мөнәсәбәте, сүз сәнгатенең милли характеры, реализм, халыкчанлык һәм әдәби осталык, театр тәнкыйте мәсьәләләре күтәрелә. Әдәбият һәм сәнгатьнең бурычын ул мәгърифәт тарату һәм әхлак төзәтүдә билгеләү белән бергә, иҗтимагый-милли мәсьәләләрне күтәрүдә, сәяси һәм икътисади стройның асылын сәнгатьчә ачып бирүдә билгели.

Ул заман таләпләренә җавап бирмәгән әдәби әсәрләрне кискен тәнкыйтьли. Ф.Әмирханның мондый рухта язылган рецензияләре бер төркемне тәшкил итә. Г.Тукайның тәүге шигырьләренә, Ярулла Вәли, М.Гафури, М.Фәүзи әсәрләренә язылган бәяләр шундыйлардан. Г.Тукай рус

шагыйре Кольцовның “Что ты спишь, мужичок” шигырен “Мужик йокысы” исемендә тәрҗемә итә. Шагыйрьнең беренче тәҗрибәләреннән булган бу әсәр Г.Тукайның иҗатында мәгърифәтчелек идеяләре өстенлек иткән вакытта тәрҗемә ителә. Шигырьдә авыл мужигы үзенең ярлы, ялкаулыгы аркасында ярлы, авыр тормышта яши дигән идея үткәрелә. Ә Ф.Әмирхан “Мал юк дип зарланма, үзеңнән күр аны” дигән шигырьләрнең мәгънәләре берлә Русия җир тарихын вә сәясәтен белгән кешеләр канәгать итмәячәктер”, - дип яза. Ул моның белән Г.Тукай шигыренең заман таләпләренә җавап бирмәвен күрсәтә (Габдулла Тукаев шигырьләре (2) (4 нче дәфтәр) (1908)).

Ф.Әмирханның “Ачлык кушты” рецензиясе 1908 елда “Әльислах”та “Дамелла” имзасы белән басыла. “Ачлык кушты” – Ярулла Вәли драмасы. Драматург әсәре белән “кызның фаҗигасендә явыз әнисе гаепле” дигән фикер уздыра. Тәнкыйтьче исә кызның үлемен, фаҗигасен Россиянең социаль-икътисади җирлеге белән бәйли: “Мондый олуг темалар (ачлык темасы – Г.Т.), хосусән, бөтен бер халыкның, хәтта бер мәмләкәтнең халәте икътисадиясеннән (икътисади хәленнән – Г.Т.) килгән күренешләр хакында язылган драмалар социальный характерда язылырга вә асыл сәбәп булган яманлык, төрле тарафларыннан вә сәбәпләре белән тәфтиш ителеп (аңлатылып – Г.Т.), укучы күз алдына тәрсим ителергә (сурәтләнергә – Г.Т.) тиештер. Әмма “Ачлык кушты” драмасы нәкъ шушы нәрсәләрдән мәхрүм” (“Ачлык кушты”, 1908). “Ачлык кушты”, “Үги балалар” рецензияләрендә ул үгет-нәсихәтчелекне, риториканы, кеше образларындагы схематизмны һәм иллюстративлыкны кискен рәвештә тәнкыйть итә.

Г.Коләхмәтовның “Яшь гомер”ендәге Зөләйха образына шушы ноктадан якын килеп “Мөхәррир монда капиталның тугрыдан-тугры көчләве буенча кияүгә чыгуны тасвир иткән булса, драманың гомуми фикеренә кәмаль (камиллек) вә яңа рәүнәкъ (төс) биргән булыр иде”, - дип яза “Яшь гомер” (1908) рецензиясендә.

Реализм турында фикер йөрткәндә Әмирхан персонажны индивидуальләштерү мәсьәләсенә дә зур игътибар бирә. Аныңча, әдәби герой

чын мәгънәсендә характер булырга, ягъни социаль хәле кушканча гына түгел, бәлки табигате, тумыштан килә торган характер үзенчәлеге кушканча да гамәл кылырга тиеш. Шакир Мостафаның "Фәүзи" повестендагы төп персонажларның берсе Ламига уңае белән ул, мәсәлән, болай дип яза: "Занымча (минем карашымча – Г.Т.), әгәр дә идеальный элемент урынына Шакир әфәнде күбрәк "индивидуальный" элемент катыштырган булса, очлап чыккан булыр иде. Чөнки шул ук Ламига үзенең хосусый хиссиятен сөйләгәндә никадәр гүзәл һәм никадәр куәтле".

Ф.Әмирханның Г.Исхакый әсәрләренә язылган рецензияләрендә матур әдәбиятның реаль чынбарлыкны тулы һәм дөрес чагылдыру хасияте бары тик җанлы һәм тормышчан образлар, табигый типлар тудыру аша тормышка ашырыла дигән фикер, кагыйдә үзәккә куела. Мәсәлән, "Алдым-бирдем" рецензиясендә тәнкыйтьче пьесаның сюжеты нигезендә яткан төп каршылыкны – яңа тормыш белән иске тормыш арасындагы көрәшне билгели, милли чынбарлыктагы тартышны типлар аркылы анализлый. Конфликт тудыручы көчләр, төркемнәргә нигезле характеристика бирә. Рецензент тормыш дөреслеге гәүдәләнү ягыннан пьесаны югары бәяли. Тип терминын түбәндәгечә аңлата: "Тип" дип, мәгыйшәттән алып ясалган вә тасвир ителә торган сурәте әдәбиягә әйтеләдер: "Алдым-бирдем"дәге һәрбер персонажның татар тормышыннан алынып, тип дәрәҗәсенә җиткерелеп эшләнүе билгеләнә. Ә Ибраһим образының яңа тормыш каһарманы буларак ачылмавы, мәхәббәт темасының аз тасвир ителүе, пьесаның җитешсезлеге итеп күрсәтелә.

"Солдат" (1908), "Мөгаллим" (1914), "Зөләйха" (1917) рецензияләрендә дә Ф.Әмирхан реалистик тәнкыйть кануннары, әдәби әсәрне бәяләү принциплары белән эш итә. Иң беренче "Гаяз" (1907) мәкаләсендә Г.Исхакый каләмендә реалистик табигатен тотып алып: "... язган нәрсәләре белән йөрәкләрне кузгата, күңелгә әллә нинди фикер вә хисләр бирә вә мәгыйшәтьнең начар вә яхшы якларын ачык күрсәтә торган мөхәррир", – дип яза. Ул аларда гәүдәләнгән тормыш материалының иҗтимагый-социаль,

милли азатлык мәсьәләләре белән бәйләнешенә һәрдаим үз игътибарын юнәлтеп тора.

“Солдат” исемле рецензиясендә, автор җәмгыятьтә хөкем сөргән сәяси хәлгә бәйле рәвештә повестька тиешле, теләгән бәя бирә алмавын сиздертә. Ул аны роман дип атый. Г.Исхакыйның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген, шуның бер өлеше “Зиндан”да тасвир ителүен хуплый.Әсәрне әдәбият һәм фикер үсешен күрсәтүче повесть дип атый. Бу рецензиядә Ф.Әмирханның инкыйлаби-демократик карашлары чагыла.

“Мөгаллим” рецензиясе пьесаның “Шәрык” клубында уйналу мөнәсәбәте белән языла. Шуңа күрә театр тәнкыйте белән үрелеп китә. “Мөгаллим” татар халкының азатлык хәрәкәтләре көчәйгән вакытында язылган. Кимчелек буларак V пәрдәдәге бертарафлылык күрсәтелә. Безнең карашыбызча, тәнкыйтьче бертарафлылык дигәндә сыйнфый көрәш, азатлык хәрәкәтләрен яктыртуга тиешле игътибар бирелмәүне күздә тота. Алдагы рецензияләрендәгечә пьесаны бәяләүдә төп бизмән булып татар тормышын реаль вакыйгаларда дөрес итеп үз кыяфәтендә чагылдыру принцибы тора.: “Татар мөгаллиме тормышының Гаязның маһир куллары тарафыннан ясалган картинасы безнең алда авыр, фаҗигале вә өмидсез булып басып торадыр. Моны күреп җан ачына, сызлана, пьеса бер трагедиягә, рухани трагедиягә әйләнә”.

Билгеле булганча, “Зөләйха” фаҗигасе 1912 елда язылып бетә, әмма ул 1917 елга кадәр рәсми төстә тыелып килә. 1917 елгы февраль инкыйлабы биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, “Зөләйха” пьесасы “Сәйяр” труппасы тарафыннан аның җитәкчесе һәм режиссеры Г.Кариев бенефисына 1917 елның 17 мартында Казанның Зур драма театры сәхнәсендә күрсәтелә. Бу зур тарихи фаҗига милли театр хәрәкәтендә әле күрелмәгән яңа сәхифә ача. Җәмәгатьчелек бик җылы кабул иткән бу спектакль вакытлы мабугатның да игътибарын бик тиз арада үзенә җәлеп итә. Пьесаны сәхнәләштерү матбугат битләрендә аның идея-эчтәлеге, татар театрының торышы, актер осталыгы, режиссура, сәхнә бизәлеше, тамашачы турында зур сөйләшүгә этәрә.

Г.Кәрам, Ш.Әхмәдиев, Р.Тюменов һ.б.ларның рецензияләре, тәнкыйди чыгышлары мәгълүм. Беренче булып фикерне Ф.Әмирхан әйтеп чыга (“Кояш”, 1917 ел, 19 март). Тәнкыйтьче әсәрнең темасына игътибар итеп, аның киң иҗтимагый-милли әһәмияткә ия булуына басым ясый: “Зөләйха – талантлы каләм, хәссас (сизгер – Г.Т.) рух белән язылган, урыны-урыны белән гаять тирән рухани фаҗигане караучының алдына китерә торган пьесадыр. Бу иске хөкүмәткә каршы гаять куәтле бер обвинительный акт булуы белән бергә, милләтемезнең үз кодсияте (изге – Г.Т.) юлында һичбер төрле фидаилектән кире тормас дәрәҗәдә рухка малик фәрдләре (ия шәхесләре – Г.Т.) барлыгын күрсәтә вә бөтенлегебезне саклауда исламның нинди шәрәфле бер роль уйнаганлыгын исбат итә торган бер васикадыр (нигезле дәлилдер – Г.Т.)” (“Зөләйха”, 1917). Күренә ки, тәнкыйтьче татар халкын милләт буларак саклап калуда ислам диненең әһәмияте турында әйтә. Моннан соң Ф.Әмирхан пьесаның һәм аның буенча эшләнгән спектакльнең сәхнәдә куелышына да дикъкать итә. Пьесаның сәнгатьчә эшләнешенә килгәндә, “әдәби җәһәтеннән дә, пьеса тормышта булган, реаль пьесаларыбызның күбесеннән өстен тора вә урыны-урыны белән гүзәллекнең югары дәрәҗәләренә ирешәдер”, - дип билгели Ф.Әмирхан.

Тәнкыйтьченең “Гаяз әфәнде шәрәфенә” (1917) мәкаләсе “Новый клуб”та Г.Исхакый хөрмәтенә зур банкет үткәрелү уңаеннан языла. Бик күп оешмалардан вәкилләр катнаша. Соңыннан Г.Исхакый да чыгыш ясый. Аның тарафыннан бу чорда төп мәсьәлә булып татар халкының сәяси көрәш тактикасын ачыклау һәм билгеләү проблемасы торуы билгеләнә һәм әдип банкетта сөйләгән нотыгында аңа үз мөнәсәбәтен белдерә: “Бу көндә бөтен милләт бербөтен буларак, кулга-кул тотышып хәрәкәт итәргә тиеш, демократы, буржуасы, зыялылары, руханилары – һәммәсе милләтнең һәрбер сыйныфы милли бөтенлек байрагы астында сәхнәгә басарга тиеш. Әмма хәзер исә, җимерелергә тиеш нәрсә җимерелде, аның урынына хәзер бер хәрабәнең чүпләре генә калды. Безнең милләтебезнең хәзерге вазифасы, инде шул хәрабәнең урынын чүпләрдән арчып, аның урынына милли мәдәният

иҗат итү, милли иркен рәфаһиятебезне (тормышыбызны – Г.Т.) торгызу өчен берләшү кирәк”.

Әдип тарафыннан әдәби тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләре эшләнүгә Ф.Әмирханның рус тәнкыйтьчеләренең хезмәтләре белән танышуы, тәнкыйди реализм белән язылган рус әдәбияты әсәрләрен укуы тәэсир итә. Мәсәлән, “Гоголь бәйрәме” (1909) дигән мәкаләсендә, яңа татар әдәбиятының рус реализмына ориентация тотарга тиешлеген күрсәтеп, ул болай ди: “... рус әдәбияты безнең яңа әдәбиятыбызга күп тәэсир итә генә түгел, бәлки күп ярдәм итәдер”. Аңа типик характерлар тудыруда И.С.Тургенев тәҗрибәсе ярдәмгә килсә, психологик анализга ирешү осталыгы Л.Н.Толстой ярдәменнән башка була алмаган. Н.В.Гогольнең тууына 100 ел тулу уңаеннан язылган юбилей мәкаләсендә әдипнең рус әдәбияты мәйданында тоткан урыны хакындагы уйланулары белән Ф.Әмирхан татар әдәбиятының ориентациясе, үсеш юнәлеше мәсьәләсенә барып чыга. Ул татар халкының көнитешен, яшәешен уңай якка үзгәртү, милли әдәбиятны яңарту өчен рус әдәбиятына йөз тотарга тиешлекне дәлилли: “Ватандашларыбыз русларның мәгыйшәти руханилары (дөньяви караш иҗат итүчеләре – Г.Т.) белән белешләнү безгә файдалы гына түгел, бәлки важибтыр (тиештер – Г.Т.): без алар аркылы Гарби Европа белән белешләнәчәк һәм тормышыбызда һәр көнне рус мәгыйшәте белән очрашып торабыз һәм торачак; билахирдә (ахырда – Г.Т.), рус әдәбияты безнең яңа әдәбиятыбызга күп тәэсир итә генә түгел, бәлки күп ярдәм итәдер” (“Гоголь бәйрәме”, 1909).

Ф.Әмирханның әдәби тәнкыйди эшчәнлегендә Г.Тукайның шигъри осталыгын яклау, аның иҗатын пропагандалау, иҗтимагый үзенчәлекләрен, халыкчанлыгын һәм миллилеген, тел-үзенчәлекләрен ачып бирү һәм гайбәттән саклау зур урын алып тора. “Габдулла Тукаев шигырьләре” (1) (1907), “Габдулла Тукаев шигырьләре” (2) (1908), “Татар шагыйрьләре” (1908), “Печән базары, яки Яңа Кисекбаш” (1908), “Тукай үлем алдыннан” (1914), “Тукай вә хатын-кыз” (1918), “Тукай” (“Азмы какканны вә сукканны”

(1914), “Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим” (1923) мәкаләләре һ.б.

Ф.Әмирхан иң беренче мәкаләләрендә үк Г.Тукайның шигырьләренең теле хакында этрафлы итеп сөйли. Башлангыч чор иҗатында татарча язылган әсәрләре белән беррәттән “иске төрек теле белән язылып, гарәпчә, фарсыча, әзербайҗанча, тагы әллә нәрсәчә телләреннән корылган шигырьләре дә күптер”, - дигән фикер уздыра. “Татар шагыйре урынына мөтәкәллиф (кирәксез – Г.Т.) төрекләшкән шагыйрьләр ясап чыгаруларын татар теле һәм татар әдәбияты ноктаи нәзарыннан (карашыннан – Г.Т.) гөнаһ” булуын билгели. Тел җәһәтеннән “Шүрәле” поэмасына уңай бәя бирә. Шагыйрьнең тәрҗемә, ияреп язуларына уңай бәя мөнәсәбәтен белдерә (Габдулла Тукаев шигырьләре) (1), (Габдулла Тукаев шигырьләре) (2).

Ф.Әмирхан әдәбиятның халыкчанлыгын, миллилеген аңлауда аерым бер урын тота: “Үз милләтеңне кирәгенчә сөяр өчен, аның рухын аңларга, аның халәте руханиясендәге бик нечкә мусика (музыка) тамырларын чиертеп, шуларның чыгарган тавышларын тыңлый белергә кирәктер. Шул вакытта гына кабык астына яшерелгән куәи руханияне (эчке көчен – Г.Т,), ләтафәт (гүзәллек – Г.Т.), матурлыкны күреп яратырга мөмкин буладыр” (“Мәктәпләребездә татар әдәбияты”, 1910). Монда ул, һичшиксез, милләтнең язмышы, аны борчыган проблемалар, уй-фикерләрен аларның кайгы-шатлыкларын күздә тота. Милләтнең ерак тарихын, үсешен белергә чакыра. Аерым бер мәкаләләрендә Г.Тукай иҗатының халыкчанлыгын аңлауда шушы юлдан килә. “Тукаев кайгы-хәсрәт баласы, моңнар шагыйре, авыр тойгылар, авыр мәшәкатьләр җырчысы иде... Милләтебезнең бөтен халык җырларындагы төп аһәң, кайгы, хәсрәт, авыр моң аһәңе аның шигырьләрендә дә төп көй, әсас (нигез – Г.Т.) иде. Менә шуңар күрә аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды” (“Азмы какканны вә сукканны” (1913)). 1923 елда язылган “Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим”дә дә шушы караш ассызыклана. Монда ул тезислар рәвешендә әдипнең тормыш

баскычларын билгели һәм түбәндәге иҗат сыйфатларын ассызыклый: гаять истигъдадлы (талантлы – Г.Т.), табигате гаять хәссас (сизгер – Г.Т.), авыру дәрәҗәсенә ирешә торган гыйззәте нәфесле (үз-үзен сөючелек – Г.Т.), ләкин каләме һәм кирәгенчә җәелергә һичбер төрле зәмингә (нигез – Г.Т.) очрый алмый һәлак булган таланттан башка һәрбер коралдан мәхрүм Тукайның тәкъдире алдан инде билгеләнеп куелган иде”, - ди.

Иске мәдрәсә биргәннән артмаган гыйлем, иске төрек-татар әдәбияты җыйганнан бер генә карыш та уза алмаган “әдәбият танышлыгы”, төньякның ярлы, мескен табигате белән чикләнеп калган табигать тәэсираты, Казан белән Җаек арасында чикләнгән дөнья белән танышлык, фикере, гыйлеме, зәвыгы яхшы тәэсир итәрлек даирәгә кермәү, Ф.Әмирхан карашынча, Тукайның тумыштан килгән талантына киңәергә, үсәргә мөмкинлек бирми, ул тумыштан бирелгән сәләт, “талант бөресен ачмыйча, ача алмыйча һәлак булды”.

Кимчелек буларак лириканың зәгыйфьлеге, хисләр, тойгылар җырларында көчле мәгънәләр юклыгы, зур күләмле әсәрләрендә фикер ягыннан оешып җитмәгәнлек күрсәтелә. Төп сәбәп – Тукай тормышы, авыр шартлар, “татар халкы гаммәсенең тормыш шараиты (шартлары – Г.Т.). Бу мәкаләдә Ф.Әмирханның шагыйрь иҗатына үтә тәнкыйтьчел карашы урын ала. Бәя-хөкемнәрдә 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң буржуаз җәмгыятькә, капитализмга булган тискәре карашның йогынтысы да, совет идеологиясенең тәэсире дә сизелә. Мәсәлән, Ф.Әмирхан алга таба болай дип яза: “Аның күңеле инкисар (хәсрәтләнү – Г.Т.) итте, мәңге инкисар (хәсрәтләнде – Г.Т.), шул инкисар (хәсрәтләнүе – Г.Т.) белән инде ул каберенә кергәнче аерылышмады. Менә Тукайның капитализм дөньясыннан хиссасы (өлеше – Г.Т.)... бөтен тормыш рәвеше белән буржуазный җәмгыятьтән камилән (тулысынча – Г.Т.) читтә яшәгән, табигате белән капитализм дөньясына җайланырга теләү, җайлана белүдән камил азат булган бу халык баласы мәңге халык гаммәсе белән бергә калачак” (“Күпме какканны...”, 1923).

Алда әйтелгәнчә, Ф. Әмирханның бу төр иҗатында Г. Тукай шигъриятен, шәхес субъектив бәядән, нахак сүзләрдән саклау темасы кызыл җеп булып сузыла. Шундый хезмәтләрнең берсе – “Татар шагыйрьләре”. Ф. Әмирханның бу мәкаләсе 1908 елда языла һәм беренче мәртәбә “Дамелла” имзасы белән шушы ук елда “Әльислах” газетасында басылып чыга. Ул Г. Тукай иҗатына объективлыктан ерак бәяләр биргән язмаларга җавап рәвешендә дөнья күрә.

1908 елда Казанда нәшер ителгән “Волжско – Камская речь” газетасында цензор, педагог, мәктәпләр инспекторы һәм Татар укытучылар мәктәбе укытучысы Алберт Петрович Пинкевич (1884 – 1939) “Очерки новейшей татарской литературы” дигән мәкаләсен бастыра. Ул анда XX гасыр башы татар әдәбиятына күзәтү ясый, Г.Тукай һәм М.Гафури иҗатларына нигезләнеп, татар шигъриятендә күзәтелгән тенденцияләрне барлый. А.Пинкевич үзенең мәкаләсендә “Тукаев шигырьләрендә нәфасәт һәм шагыйрьлек очкыннары күренә, ләкин ул күп вакытта, өстенә урынсыз мөгаллимлек ролен ала. Мәҗит Гафури шигырьләре тар милләтчелек белән язылганнар” дип, Г. Тукай шигырьләрен сәнгатьчә эшләнеше ягыннан югары бәяли, анда язучылык таланты барлыгын таный; ә М. Гафури әдәби әсәрләренең тар милли характерына үзенең тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Бу мәкаләгә җавап төсендә “Волжский листок” газетасында Касыйм Уралец тәхәллүсе белән “Татар шагыйрьләре” язмасы дөнья күрә. “Волжский листок” – 1904 – 1909 елларда Казанда рус телендә нәшер ителгән газета. Язма авторы А. Пинкевичның фикерләрен кире кагып, киресенчә, Тукайны шигырьләр саны азлыкта, тәрҗемәләре уңышсыз булуда, тел – стиле ямьсезлектә, урам теле белән язуда гаепли. “Тукаевның шигырь мәҗмугалары кечкенәләр, бары 15,20 генә нәү иҗат (оригиналь – Г.Т.) шигырьләре бар, калганнары муаффәкыятьсез (килешсез – Г.Т.) тәрҗемәләр. “Әмма Гафури? Бу – бөтен Русия һәм Себердә мәшһүр” – дип М. Гафурины югары бәяли, аны Америка шагыйре Уитмен Уолт (1819 – 1892) белән янәшә куя.

Соңгы мәкалә Ф.Әмирханны кулына каләм алырга мәҗбүр итә. Аның язылу максатын ул болай дип билгели: “Мин бу тәнкыйтьче татар шикелле тагы татарлар булмавыннан имин булмаганга күрә, мәзкүр (күрсәтелгән – Г.Т.) ике шагыйрьләрнең әсәрләре арасындагы мөнәсәбәтен карамакчы булам.”

Ф.Әмирханның мәкаләсе М.Гафури һәм Г.Тукай иҗатларын янәшә куеп тикшерү, бәяләү, чагыштырма анализ ясау шәкелендә язылган һәм ул жанр сыйфатлары белән әдәби параллель жанрына якын тора. Ф.Әмирханда әдип әсәрләренең теле, тәрҗемәләре, идея-эчтәлеге, милли характеры мәсьәләләре калкытып куела.

Ф.Әмирхан, М.Гафури шигырьләренең идея-эчтәлегенә, аеруча милли характерына А.Пинкевич тарафыннан бирелгән бәя белән килешә. Шагыйрьнең кайбер әсәрләрендә татар халкының милли хосусиятләрен, традицияләрен саклаган хәлдә бер иҗтимагый-икътисади шартларда башка милләтләр белән дус, тату яшәү мөмкинлеге кире кагыла. Дошманлык, дини-рухи аерымлык калкытып куела. Бу фикерне Ф.Әмирхан шагыйрьнең “Яшь гомер”, “Милләт мәхәббәте” әсәрләреннән шигырь юллары китереп ныгытып куя.

Тәнкыйтьче шагыйрьләр иҗатында тел чуарлыгын, гарәп, фарсы сүзләренең еш кулланылуын шул чор шигърияте өчен гомуми күренеш, татар теле формалашуда күзәтелгән бер тенденция рәвешендә карый. Тукайда гына түгел, М.Гафурида да башка телләрдән алынган гыйбарәләр белән язылган шигырьләр булуын әйтеп чыга. Шул ук вакытта бер үк мотивны, Тукайның гади, саф, ачык телдә, ә М.Гафуриның, киресенчә авыр, аңлаешлы телдә гәүдәләндерүе алар поэзиясеннән поэтик үрнәкләр китереп күрсәтелә.

Алга таба Тукайның, тәрҗемә эшен үзенчәлекле әдәби иҗат алымы дәрәҗәсенә күтәреп, рус һәм аның аша Аурупа шагыйрьләренең әсәрләрен уңышлы тәрҗемә итүе шагыйрь рухи мирасыннан мисаллар белән раслана.

Ф.Әмирхан Касыйм Уралецның шагыйрьләр шигъриятенә берьяклы, субъектив мөнәсәбәтен “аның татар әдәбиятыннан камил хәбәрсезлеге һәм

шагыйрь дигән нәрсәне вәгазь китабы дип аңлаучылыгы” белән бәйләп аңлатыла.

Дөрес, мәкаләдә Ф.Әмирханга да урыны белән объективлык җитми. Г.Тукай шигърияттен хата, ялгыш бәяләүчеләрне кире кагу белән мавыгып китеп М.Гафури шигъриятенә тенденциоз якын килә. Шагыйрь поэзиясенең иҗтимагый-милли әһәмиятен, аның байлыгын күреп бәяләп җиткерми.

Күзәтүләргә нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Татар әдәби тәнкыйте үткән юлны гыйльми күзаллаучы әдәбият галимнәре бу иҗат төренә нигез салучылардан Ф.Әмирханны бертавыштан күрсәтәләр. Бу, чыннан да, шулай. Ф.Әмирхан үзенең күпсанлы мәкаләләре, рецензияләре белән татар әдәбиятының яңару процессын тизләтә. Ул тәнкыйди эшчәнлегендә рус әдәбият белемендә калыплашкан һәм, әйтергә кирәк, XX гасыр башында милли әдәби-гыйльми фикер тарафыннан үзләштерелгән культура-тарих мәктәбенең кагыйдәләре, әдәби кануннарына таянып татар реалистик тәнкыйтенә нигез сала. Татар әдәби тәнкыйтенең нигез принциплары, әдәби әсәрне бәяләү кагыйдәләре, фән буларак асыл хасиятләре Ф.Әмирханның тәнкыйди гыйльми эшчәнлегендә фәнни югарылыкта эшләнә һәм хәл ителә.

Г.Ибраһимовның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге (1910 еллар тәнкыйте мисалында)

Киңкырлы талант иясе Г.Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйте тарихында да кабатланмас үз урыны бар. Ул бу иҗат төре белән әдәби тәнкыйтьнең, эзләнүләр чоры үтеп, камилләшү-җитди сыйфади үзгәрешләр кичерә башлаган 1910-елларында шөгыльләнә башлый һәм тиз арада киң карашлы, теоретик әзерлекле, киң колачлы, талантлы һәм үзенчәлекле тәнкыйтьче буларак танылa. Күренекле галим тәнкыйди эшчәнлеген ике юнәлештә алып бара:1) әдәби тәнкыйтьнең поэтикасы һәм тарихы мәсьәләләре;2) әдәбият мәйданында урын алган әдәби әсәрләргә чорның гыйльми-нәзари, әдби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи фикерләре ирешкән

казанышлары ноктасыннан бәя бирү, үз заманының әдәби процесс үзенчәлекләрен ачу.

Г.Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйте тарихында тоткан урыны, тәнкыйди эшчәнлеге һәм аның хасиятләре әдәбиятчы галимнәр тарафыннан мәгълүм дәрәҗәдә яктыртылган. XX гасыр башында татар дөньясында, ниһаять, әдәби тәнкыйтьнең фән буларак мәйданга килүе Г.Ибраһимовның исеме белән дә бәйләп карала. Аның "Татар шагыйрьләре" китабына язылган рецензиясендә Г.Баттал болай ди: "Галимҗан әфәнденең бу әсәре – чын тәнкыйть. Әдәбиятыбыз мондый тәнкыйтьләргә күптән мохтаҗ иде. Без, мондый әсәрләрне күргәч, әдәбиятыбыз җитди юлга кереп бара дип шатланабыз һәм Галимҗан әфәнденең тәнкыйть гыйлемендә алга таба бик зур адым атлаганын күрәбез"("Татар шагыйрьләре"). Татар әдәби тәнкыйте фәненең "остазы" булган профессиональ тәнкыйтьче Җ.Вәлиди тәнкыйть һәм әдәбиятта "мөтәхассыйс (белгеч) исемен алган яки алырга таба юл тоткан кешеләр"("Матбугат галәмендә") - "икенче буын мөхәррирләр" арасында Г.Ибраһимовны атый. Әлбәттә, бу замандашы тарафыннан тәнкыйтьчегә бирелгән югары бәя була.

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң Г.Ибраһимовның әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтенә Г.Сәгъди, М.Гайнуллин, М.Хәсәнов, М.Мәһдиев, Р.Мөхәммәдиев, Э.Галиева, Д.Заһидуллина һ.б. галимнәр игътибар итәләр. Дөрес, аерым бер эзләнүләрдә Ибраһимовның тәнкыйди фикерләре белән гыйльми-теоретик күзаллаулары, фәлсәфи-эстетик карашлары, кайбер очракларда публицистик эшчәнлеге тыгыз бәйләнештә карала. Бу хосусият әлеге тармакларның үзара тыгыз мөнәсәбәттә яшәүләреннән килә.

Әдәби тәнкыйть поэтикасына караган төшенчәләр, әсәрне бәяләү кагыйдәләре һәм алымнары, критерийлары, мәгълүм булганча, җанлы әдәби тәнкыйди хәрәкәт белән тыгыз бәйләнештә барлыкка килә һәм үсеш-үзгәреш кичерә. XX гасыр башында әдәби тәнкыйть яңа әдәбиятны, аның аерым берәмлекләрен аңлау-бәяләүнең кануннарын, фәнни нигезләрен

ачыклый торган эстетик концепцияләр эзләү юлына чыга, ягъни ул әдәби-мәдәни мәйданга килгән һәрбер яңа фән кебек , иң беренче нәүбәттә, үз предметын, өйрәнү һәм бәяләү объектын ачыклау, үз билгеләнү хокукы, иҗтимагый вазифасы һәм функцияләре, әдәби барыштагы урыны, тәнкыйть этикасы, жанрлар системасы кебек мәсьәләләрне хәл итәргә алына.

Милли, әдәби-мәдәни күтәрелештә әһәмиятле роль уйнаган Шәрекъ һәм Гареб мәдәниятләренең уңай йогынтысы, хәтта бу ике культурологик ориентирның үзара бәхәсе әдәби тәнкыйтьнең мөһим теоретик мәсьәләләрен хәл иткәндә дә сиземләнә. Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Баттал, М.Укмасилар тәнкыйди эшчәнлегендә үзе латин, борынгы грек цивилизациясе тәэсирендә калыплашкан Аурупа-рус әдәбият белеменең тәэсире зур булса, ә Р.Фәхретдин, Г.Сәгъди һ.б.лар төрки-татар дөньясы озак гасырлар тыгыз бәйләнештә яшәгән, әдәп-әхлак, белем алмашкан Шәрекъ мәдәниятенә таяналар. Татар галимнәре тарафыннан, мөмкин булганда, милли әдәбият белеменең, шул исәптән әдәби тәнкыйтьнең аерым терминнарын татарча эшләү теләге белдерелсә дә, ике мәдәниятнең ирешкән фәнни казанышларыннан башка бу мәсьәләне чишү мөмкин түгеллеге танылa. Бу хәрәкәтнең үзәгендә Г.Ибраһимов та кайный.

Г.Ибраһимов әдәби тәнкыйть фәне турындагы нәзари эзләнүләрен **“Әдәбият кануннары”** (1919) дигән хезмәтендә бер бүлекчәгә туплап урнаштыра. Билгеле булганча, аның беренче басмасы “Әдәбият дәресләре” исеме астында 1916 елда Казанда “Сабах” матбагасында дөнья күрә. Иң беренче нәүбәттә, әлеге методик әсбапта галимнең әдәби тәнкыйтьне фәнни нигезгә утырту омтылышын билгеләргә кирәк. Бу еллар тәнкыйди рухи мирасын актарганда, әдәби иҗатның бу төренә атама булып ике термин: **тәнкыйть** һәм **интикад**ның фәнни кулланылышта йөрүе күзәтелә. Г.Ибраһимовның аерым мәкалә-язмаларында интикад кулланылса да, тәнкыйть терминына өстенлек бирелә. Галим тәнкыйть сүзенең килеп чыгышы, мәгънәсе, фәнни һәм гамәли әйләнешкә керүе, аның тамырдаш, мәгънәдәш сүзләре турында уйлана : “Тәнкыйть сүзе “нәкыд” матдәсеннән

алынган. Лөгать мәгънәсе акчаның чынын сахтәсеннән (ялганыннан) аеру димәктер” (“Әдәбият кануннары”).

Әдәби тәнкыйтьнең предметы, аның шартлары һ.б. гыйльми-нәзари төшенчәләрне шәрехләүдә Г.Ибраһимов, алда әйтелгәнчә, Аурупа-рус әдәбият белеме ирешкән казанышларга таяна. Мәсәлән, ул тәнкыйтьне мантыйкый дәлилләр белән эш итүне һәм исбатлауны таләп иткән **мөхакәмә**нең бер төре итеп карый һәм алга таба тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләре аның тарафыннан шушы позициядән чыгып аңлатыла. Әдип моңа кадәр практик кулланылышта булган әдәби тәнкыйтьнең шартлары, таләпләре терминнары урынына кагыйдәләр, кануннар дигән төшенчәләргә мөрәҗәгать итә. Әдәби әсәргә бәя бирүнең үлчәмнәре турында сүз алып барып, **“мизан**” төшенчәсен фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә: “Бер әсәрне яки бер язучының барлык әсәрләрен тикшереп, аларга кыйммәт куйганда, мөнәкъкыйднең шулардагы җитешкән яки җитешмәгән якларны билгеләүдә үзенең рәһбәр(юл күрсәтүче, таяныч) ителгән шул канун вә нәзарияләре “тәнкыйтьнең мизаны” – яки критериум дип атыйлар” (“Әдәбият кануннары”).

Г. Ибраһимов китапның кайсы өлкәгә, нинди жанрда язылуына карап, аны бәяләү мизаннарының да төрле булуын әйтеп чыга, аларны бер – берсеннән аерып куя. Мәсәлән, дәрес китабы белән әдәби әсәрләрне бәяләүдә бер төрле кануннар һәм нәзарияләргә таянуны кире кага. Автор тарафыннан “тикшерелгән әсәрнең эч йөзен, маһиятен(асылын) ачып бирү, әсәр теле, өслүбе, план вә мөндәриҗәсе(эчтәлеге) төп уйны ачып җитә алып – алмавы, хәяткә мөнәсәбәте” мәгълүм мизаннар ярдәмендә бәяләнергә тиешле яклар буларак аерып чыгарыла. Бәя-шәрехләүнең объективлыгын, беръяклы гына булмавын күздә тотып, тәнкыйтьне “ике йөзле хәнҗәргә тиңли”. “Тәнкыйть ике йөзле үткен хәнҗәр булырга тиеш. Бу хәнҗәрнең бер ягы әсәрнең эчендәге җәүһәрләрне казып чыгарса, икенче ягы аның чүбекләрен табып күрсәтү” (“Әдәбият кануннары”).

“Әдәбият кануннары”нда әдәби тәнкыйтьнең төрләрен аерып чыгару, аларның үзенчәлекләрен билгеләү юнәлешендә дә тәнкыйтьченең карашлары урын алган. Әдәби тәнкыйтьнең әдәби әсәргә рекомендация бирү һәм әдәби әсәрнең “уңай” һәм “кире,” “җитешкән вә җитешмәгән” якларына бәя бирү вазифасы Г.Ибраһимовка аның ике: **“иҗаби”(уңай)** һәм **“сәлби”(кире)** төрләрен күрсәтүгә юл ача. “Әсәрнең яхшы ягын күрсәткән тәнкыйтьләр **иҗаби тәнкыйть** дип, җитешмәгәнен күрсәткәннәре **сәлби тәнкыйть** дип атала”(“Әдәбият кануннары”). Дөрес, биредә кире тәнкыйтьнең әдипкә ярдәм итү, әсәрнең кимчелекле якларын бетерүдә юл күрсәтү сыйфаты калкытып куела: “Сәлби тәнкыйтьләр әсәрнең җитешмәгән якларын күрсәтү белән язучының үзен дә, башкаларны да шул хатадан, шул кимчелектән сакланырга юл эзләргә, шулай итеп төзәлүгә сәбәп булалар”(“Әдәбият кануннары”).

Г. Ибраһимов иҗаби тәнкыйтьнең ике функциясен калкытып куя: 1) халык тарафыннан илтифат ителми яткан яшь талантларның әсәрләрен тикшереп, шулардагы яхшы якларны күрсәтү, шул юл белән аларны дөньяга таныту, 2) дөньяга чыгып та, халык тарафыннан кирәгенчә тәкъдир ителмичә яткан әдәби әсәрнең “төбенә салынган тирән вә кыйммәтле җәүһәрне” укучыга ачып бирү.

. Әдәби тәнкыйтьнең жанр ягыннан үсү, баю чоры XX гасыр башларына туры килә. Г.Ибраһимов - әдәби тәнкыйтьнең жанрларын булдыру, аның сыйфатларын ачыклау юнәлешендә дә кызыклы фикерләр белән чыгыш ясаган галим. Г. Ибраһимов **рецензия**, **рәддия** һәм **мәкаләне** әдәби тәнкыйтьнең жанрлары буларак карый. Ул рецензиягә түбәндәге билгеләмәне бирә: “Мәйданга чыккан бер әсәр, тыңланган концерт, күрелгән спектакль хакында вакытлы матбугатта, дәлилләр белән исбатка керешелмичә, кыска рәвештә тәэсир вә мөляхәзәне(фикер йөртүне) бәяннән гыйбарәт булган мәкаләләр **“рецензия”** дип атала” (“Әдәбият кануннары”). Ә рәддияне, аның карашынча, “сәлби тәнкыйтьләргә мөхәррирнең үзе яки башка берәү тарафыннан бирелгән җаваплар” барлыкка китерә. Алга таба бу жанрның рус әдәбият белемендә **антикритика** дип аталуы искәртелә.

Авторның рәддия язылу сәбәпләре турындагы хөкемнәре кызыклы. Г. Ибраһимов әдипне кимсетү, шәхесенә тию, абруен төшерү максатыннан язылган рецензияләргә рәддияләр языла дип карый. “Сәхнә хакында, әдәби әсәрләр хакында, әгәр дә шәхси намуска тиелмәгән булса, гадәттә рәддия язылмый. Фәнни әсәрләргә җавап бирелә”(“Әдәбият кануннары”). Хезмәт авторы К.Насыйриның Мәрҗанигә җавабын рәддиягә мисал итеп китерә. 1910 еллар татар әдәби тәнкыйтендә рецензия жанрының активлыгы кими. Ләкин шул ук вакытта рецензия, мәкаләнең жанр сыйфатларын үзенә алып, аңа тартымлык күрсәтә. Бу тенденция Г.Ибраһимовның тәнкыйть практикасында аеруча калку чагыла.

Г.Ибраһимов тәнкыйди эшчәнлегенең икенче тармагында үз иҗатлары белән милли әдәбиятның яңарышын тәэмин иткән классик әдипләр Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Ш.Камал, М.Фәйзи,Ш.Бабич, Г.Камал, Г.Коләхмәтов һ.б.ларның әсәрләре бәяләнә. Ул “Вакыт”, “Йолдыз”, “Тормыш”,”Идел”,”Кояш”, “Аң”, “Мәктәп”, 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң “Эшче”, “Кызыл Армия”,”Татарстан хәбәрләре”, “Кызыл Татарстан”, “Безнең юл” һ.б. газета-журналларда “Г.Ибраһимов”, “Габди”, “Галимҗан”, “Джан”, “Гыйрфанзадә” дигән имзалар һәм “Г.И.”, “Г.” инициаллары белән актив языша.

Тәнкыйтьченең бу төр рухи мирасындагы жанрлар системасын аның фикерләү стиле, язмада күтәрелгән актуаль әдәби, фәлсәфи, әхлакый, иҗтимагый-социаль мәсьәләләр, анализ обьектлары һәм принциплары, бәя-хөкемнәренең концептуальлеге билгели. “Әдип үзенең тәнкыйть мәкаләләрендә, - дип яза М.Хәсәнов, - татар әдәбиятының ул вакыттагы гомуми хәле, аерым жанрларның үсеше, әдәби процесста теге яки бу язучының тоткан урыны, татарда сынлы сәнгать, профессиональ музыка туу перспективалары, журналистика һ.б.мәсьәләләргә дә даими рәвештә игътибар итеп килә” (Хәсәнов М. Г.Ибраһимов – тәнкыйтьче һәм әдәбит галиме,1978). Аның тәнкыйди мирасында яңа әсәрне әдәбият сөючеләргә тәкъдим итү, аның хакында информация бирүне генә максат иткән кыска, кечкенә күләмле

информатив жанрларны табу кыен. Ә теоретик мәсьәләләр, сүз сәнгатенең торышы хакында уйлануларны, әдәби хәрәкәтнең аерым чорын, аның үсеш-үзгәреш закончалыкларын, тенденцияләрен чагылдырган әдәби күзәтү, проблемалы мәкалә, монографик мәкалә, рецензия- мәкалә, монографик рецензия кебек жанрлар Г.Ибраһимов тарафыннан максатчан һәм отышлы файдаланыла. Галим әдәби әсәрләргә бәяне әдәбият-сәнгатькә һәм тәнкыйтькә үзе куйган таләпләр-шартлар, үз сүзләре белән әйткәндә, әсәрнең “төбенә салынган тирән вә кыйммәтле җәүһәрне” укучыга ачып бирү яссылыгында оештыра. Г.Ибраһимов тәнкыйди эшчәнлегенең асыл хасиятен билгеләп, галим Г.Сәгъди болай дип яза:”... әдип ул вакытта сәнгать әсәрләренең бигрәк эмоция якларына, сәнгатьчә ничек эшләнеп чыгу мәсьәләләренә ныграк кереп, аларга бигрәк шул яктан бәһа бирүдә киң алымлы, зур куәтле тәнкыйтьче иде”(“Бездә әдәби тәнкыйть”,1927). Д.Заһидуллина тәнкыйтьченең матур әдәбиятны бәяләү принциплары һәм кануннары хакындагы гыйльми-нәзари күзаллауларын түбәндәгечә формалаштыра:”Әдәбият рухи дөньяны чагылдыру максаты куя дигән кагыйдәдән чыгып, Ибраһимов сәнгать әсәре булу өчен тормышны күрсәтү генә җитми, шул тормышның рухын, җанын ачарга кирәк, дип җавап бирә”(“Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе”,1912).

Г.Ибраһимовның үткән XX гасыр буенча өйрәнелеп, бүген дә бәхәсле булып калган “Татар шагыйрьләре”(1913) хезмәте **әдәби параллель** жанрында язылган. Дөрес, автор анда С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Г.Тукай шигърияләренә анализны чагыштырма планда үреп алып бармый, ә китапның беренче бүлегендә әдәбият-сәнгать әсәрләрен бәяләүнең яңа принциплары һәм кагыйдәләре нигезендә С.Рәмиев рухи дөньясының идея-эстетик үзенчәлекләрен, шагыйрьлек сыйфатларын ассызыклый да шулар яссылыгында калган ике шагыйрьнең әдәбият мәйданында торткан урынын, шигърияләренең хасиятләрен билгели. Әдип татар әдәби тәнкыйтендә поэзияне шәрехләүдә яңа фәнни-теоретик юнәлеш булдыра:”Требуя от художников слова мастерства, гармонии между чувством и его словесным

выражением, критик выдвигал на первый план чисто эстетический аспект творчества; приоритет он отдавал таланту, считая его главным критерием для критической оценки. Это в целом выделяло его среди современников. ...В ней Г.Ибрагимов в целом верно и во многом первым вскрыл эстетические заблуждения национальной литературной критики в подходе к поэзии, тем самым объективно послужив становлению новой парагдигмы в татарском литературоведении"(Гилазов Т. "Литературная репутация Тукая в эстетической концепции Г.Ибрагимова", 2009).

Г. Ибраһимов "Хәят"(1911) монорецензиясендә Ф.Әмирхан повестенда романтик иҗат тибы сыйфатларының чагылышын күрсәтеп, "Мөгаллимә"нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән"(1915) бәхәсле мәкаләсендә әдәби әсәрдә тормыш дөреслеген гәүдәләндерү принцибын яклап, "Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр"(1915) күзәтү рецензиясендә Ш.Камал хикәяләре мисалында импрессионизм модернистик агымының тасвирый алымнары һәм чараларының сыналышын ассызыклап, 1910 еллар татар әдәбиятында иҗат юнәлешләренең төрлелеген һәм милли сүз сәнгатенең үсеш перспективасын билгели. "Яңа китап мөнәсәбәте илә"(1912) язмасында иҗтимагый-социаль, әхлакый һәм тормыш-яшәеш мәсьәләләрен характерларның холкы һәм психологиясе аша гәүдәләндерү, "Зур романнар"(1912) рецензиясендә роман , аның жанр хасиятләре, шулай ук башка язмаларда урын алган әдәби типлар, әсәрләрнең милли характеры, тема-мәүзугъ яңалыгы, образлар системасы, вакыйгалар үстерелеше, авторның хикәяләү стиле хакындагы бәя-карашлары галим фәнни-теоретик эзләнүләренең киңкырлы булуы турында сөйли.

Г.Ибраһимовның бай эстетик зәвыгы, сизгер табигате матур әдәбияттагы һәр яңа күренешне тиз тотып ала. "Галиябану хакында бер-ике сүз"(1922) рецензия-мәкаләсендә пьесаны бәяләү уңаеннан халык поэтик иҗаты белән язма әдәбият арасында багланышлар, аларның бер-берсенә йогынтысы, сүз сәнгатенең художестволылыгын камилләштерүдә фольлор казанышларының роле кебек мәсьәләләргә дә игътибар ителә. Мәгълүм

булганча, М.Фәйзинең “Галиябану» музыкаль драмасында музыканың идея-эстетик вазифасы үзгәрә, ул очраклы бизәк төсендә генә түгел, ә пьеса эчтәлегенең тукымасын хасил итә. Әсәрнең мәгънәви кисәкләрен бер үзәккә туплаган әдәби деталь буларак кулланыла.. Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Г.Ибраһимов әдәби әсәрнең яңа сыйфаты хакында болай дип яза: «Галиябану»ның бөтенләй яңа хасиятләреннән берсе – аның бездә беренче мәртәбә сәхнәгә музыканы, җырны, бер иттифакый зиннәт ясап кына түгел, бәлки төп матди итеп, асыл мөндәриҗә (эчтәлек – Г.Т.) кыйлып кертүедер. Буны «Галиябану» башлап җибәрде. ... Менә шундый хасиятләре белән «Галиябану» бездә ялгыз урында тора, яңа бер баб яки, зуррак тәгъбир булса да, әйтик, драмалар галәмендә яңа мәктәп ача һәм, шулар аркасында бик хаклы буларак, гаммә алдында иң кадерле урыннарның берсен ала»(“Галиябану” хакында бер-ике сүз”,1978).

Г.Ибраһимовның әдәби-эстетик карашлары 1910 еллар татар әдәби тәнкыйтендә мәстәкыйль, үзенчәлекле, әйтергә кирәк вакыты белән каршылыклы үсеш юлы кичерә. Әдипнең кайбер язмаларында галим үзе формалаштырган фәнни мәктәпнең төп кануннары белән генә аңлатып булмый торган берьяклы бәя-хөкемнәре булса да, ул әдәби тәнкыйтьнең фән буларак үсешен тәэмин итүгә, тәнкыйть поэтикасының һәм тарихының мөһим проблемаларын хәл итүгә, әдәби әсәрләрне анализлау-шәрехләүнең яңа парадигмаларын эшләүгә, иҗатның һәр өлкәсендә яшь талантлар тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә.

***

Г. Ибраһимов — XX йөз башы татар романтик әдәби тәнкыйтенә нигез салучыларның берсе. Әдәби иҗатының бу төрендә киң карашлы, теоретик әзерлекле, киң колачлы, талантлы һәм үзенчәлекле каләм иясе булып танылуг-:. Аның эшчәнлегендә тәнкыйди мәкалә, еллык хисап, әдәби күзәтү, әдәби портрет, рецензия кебек жанрларның кулланылышы. Тәнкыйди язмаларында әдәбият тарихы, әдәбият теориясе мәсьәләләренә

дә зур урын бирелү, аерым очракларда аларның кушылып, үрелеп китүе («Әдәбият мәсьәләләре», 1910, «Зур романнар», 1912).

Язучының башлангыч чор тәнкыйди эшчәнлегендә үк татарларда нәфис әдәбият, татар вакытлы матбугаты, китап басу эшләре, мәктәпләрдә әдәбият дәресләре, татар әдәбиятын укыту кебек җитди проблемаларның куелышы.

Аның тәнкыйди хезмәтләрендә Г. Тукайга мөнәсәбәт; Матбугатта дөнья күргән беренче мәкаләсендә аңа бирелгән зур бәя («Татар матбугаты», 1910). Шагыйрь лирикасында тематик төрлелек, хисси тирәнлек, юмор һәм сатира, саф татар теле билгеләнү («Яңа әсәрләр», 1911).

Авторның матур әдәбиятка мөнәсәбәте, аңа куйган таләпләр, шигырь һәм аның асылы, үзенчәлеге, төп сыйфатларын аңлавыннан чыгып «Татар шагыйрьләре» (1913), «Талант трагедиясе» (1914), хезмәтләрендә шагыйрь иҗаты һәм шәхесенә каршылыклы мөнәсәбәте. Г. Тукай иҗатын милли идея яссылыгында бәяләве. Шигъриятенең асыл сыйфатларыннан халыкчанлык, миллилекне ассызыклавы, бу турыда теоретик карашлары.

Әдәби тәнкыйтьтә зур дулкынлану, борчылу уяткан һәм тәнкыйтьчеләрнең каләмен активлаштырып җибәргән «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә «шигырь һәм шагыйрь», «нәзым һәм назыйм», талант,әдәби ижат эше, матур әдәбиятның, шигъриятнең иҗтимагый роле мәсьәләләрнең куелышы һәм аларның романтик яссылыкта хәл ителеше.

Татар шагыйрьләреннән С. Рәмиев һәм Дәрдемәнд шигъриятләрен бәяләүгә багышланган бүлекләрнең бүген дә тәнкыйди фикернең тутыкмас җәүһәрләре буларак кабул ителүе «Татар шагыйрьләре», «Талант трагедиясе» кебек хезмәтләрдә романтик әдәбият тәнкыйте формалашу.

Г. Ибраһимовның Г. Тукай белән ике арадагы салкынлыкны, үтә киеренке мөнәсәбәтне аңларга омтылуы, моның сәбәпләре турыңда уй-фикерләре («Актык сәлам», 1915).

Г. Ибраһимовның татар прозаикларыннан ф. Әмирхан, Ш. Камал, К. Бәкер әсәрләренә багышланган мәкаләләре, рецензияләре. Талантлы каләм, киң тасвирлык, «хыялый яки хыял вә хакыйкать катыш стиль», фантастик әдәбиятка сәләтлелек Ф. Әмирхан иҗатының төп сыйфатлары буларак билгеләнү («Татар матбугаты», 1910, «Хәят», 1911, «Зур романнар», 1912). Аларда әдәбиятның миллилеге турында карашлар.

Ш. Камал иҗатына гомуми күзәтү ясау характерында язылган өлештә импрессионистик стиль билгеләре (табигать «серләре белән адәм йөрәгенең эчке зарларын бергә кушу»), «җиңел каләм», «җитез тасвир», матур тел, нәфислек кебек үзенчәлекләр ассызыклану. («Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр», 1915 һ. б.)

Г. Ибраһимовның тәнкыйди эшчәнлегендә. Г. Исха-кый иҗаты. «Мөгаллимә» драмасының сәхнәдә уйлану мөнәсәбәте белән язылган күләмле мәкаләсендә әдипнең иҗатына каршылыклы, берьяклы мөнәсәбәте һәм аның сәбәпләре. Татар совет әдәби тәнкыйтенең әдәби мираска мөнәсәбәте уңаеннан язылган мәкаләләрдә Г. Исхакый әсәрләренең гомумкешелек кыйммәтен инкарь итү юлына басуы.

Г. Ибраһимов — татар сәнгате тәнкыйтенә нигез салучыларның берсе. Аның рәсем, нәфис әдәбият, музыка, һәйкәлтараш кебек сәнгать төрләренең төп сыйфатлары, уртак яклары һәм аермалары турындагы фикерләре. Бу темага багышланган мәкаләләрдә «сәнгать — сәнгать өченме, яки мәсләккә хезмәт өченме?» бәхәсенә тәнкыйтьченең карашы («Рәссамлык», 1910, «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз», 1915 һ. б.)

Ф. Әмирхан — теоретик әзерлекле, киң карашлы, эрудицияле тәнкыйтьче. Аның әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә реалистик тәнкыйтьнең кануннары һәм кагыйдәләре эшләнү. «Әл-ихлас» белән бәйле журналистлык эшчәнлеге. «Йолдыз», «Кояш», «Аң» кебек газета-журналларда язышуы. Тәнкыйди эшчәнлегендә мәкалә, фельетон, аеруча публицистик язма, рецензияләрне актив куллануы.

М. Гафури («Үги балалар»), Ярулла әл-Вәли («Оят яки күз яше», «Җанлы җеназа»), Ф. Кәрими («Хыялмы, хакыйкатьме») һ. б. ларның әсәрләренә язган рецензияләрендә әдәби зәвыксызлыкка, тар милләтчелеккә, сурәтләнгән материалларның тормыштан ераклыгына, әдип тарафыннан үткәрелгән фикерләргә тәнкыйтьченең тискәре карашы, аларда тормыш дөреслеге өчен көрәш.

Матур әдәбиятның реаль чынбарлык белән мөнәсәбәте, иҗтимагый стройның сәяси һәм икътисади асылын сәнгатьчә гәүдәләндерү мәсьәләсе алгы планга чыгарылу («Яшь гомер», 1908, «Зиндан», 1908, «Габдулла Тукаев шигырьләре», 1908 һ. б.).

Кадимчелек һәм җәдитчелек низаглары, яңалык һәм искелек көрәше, иске тормыш белән яңа тормыш тартышы, азатлык хәрәкәтләре кебек мәсьәләләрне яктырткан әсәрләрнең Ф. Әмирхан тарафыннан хуплап каршы алынуы. Яңа тормыш каһарманнары көчсез, йомшак дип, ә искелек каһарманнарының сәнгатьчә эшләнеше югары дип бәяләнүе. Аларда Ф. Әмирханның инкыйлаби — демократик карашлары чагылу, гомум-кешедек мәсьәләләренә, кыйммәтләргә игътибар җитмәү, татар тормышына үтә тәнкыйтьчел караштa булу, аның традицияләрен, гореф-гадәтләрен, рухи, милли, мәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып бетермәү. Моның чор таләбе, үзгәрешләрнең кискенлеге белән аңлатылуы. Бу типтагы язмаларда классик реализмның сыйфатлары ачыклана төшү: тормышны реаль детальләрдә чагылдыру, типиклаштыру, шәхес һәм тирәлек мәсьәләсе һ. б.

(«Яшь гомер», 1908, «Алдым-бирдем», 1908, «Низамлы мәдрәсә», 1908, «Җиһаншахәзрәт», 1908, «Фәүзи», 1908 һ. б.).

Тәнкыйтьченең рецензияләрдә әдәбиятның сатирик юнәлешен яклавы. Аның тәнкыйть итү, фашлау, ачы көлү сыйфатын хуплау. Искелек каһарманнары аркылы әдипләрнең татар тормышындагы тискәре, ямьсез күренешләрне, артталык, наданлык, торгынлыкны, кеше иреген буучы тәртипләрне, иске гореф-гадәтләрне кире кагулары, уңышлы тормыш

материалына тап булулары ассызыклану. («Низамлымәдрәсә», 1908, «Беренче театр», 1908, Яңа китаплар сериясеннән «Җиһанша хәзрәт», 1908, «Печән базары яки яңа Кисекбаш», 1908).

Ф. Әмирханның тәнкыйди мәкаләләрендә тормыш дөреслеге, образлар системасы, тип, образ тудыру принципларыннан гомумиләштерү һәм индиви-диальләштерү, әсәрнең жанр таләпләренә җавап бирүе, сюжет-композицион яктан җыйнаклык, камиллек кебек критерийлар истә тотылу. Шулай да эстетик фикерләүдә социологик анализның өстенлек итүе.

Ф. Әмирханның тәнкыйди эшчәнлегендә Г. Тукай шәхесенә һәм иҗатына мөнәсәбәте. Тукай шигърияте теле-өслүб, халыкчанлык принцибы («халыкның кайгы-шатлыкларын дөрес сурәттә аңлату», рухи халәтләрен күрсәтү), идея-эчтәлек, нәфислек нокталарыннан югары бәяләнү. Шагыйрьнең тәрҗемә әсәрләренә мөнәсәбәте. Чуар тел белән язылган шигырьләренең, уңышсыз тәрҗемәләренең кире кагылуы.

Тукай поэзиясендә чагылган шагыйрьлек талантына зур өметләр баглау. («Габдулла Тукаев шигырьләре (1)», 1907, «Габдулла Тукаев шигырьләре (2)», 1908, «ххх Азмы какканны вә сукканны...», 1913).

Бәхәс рухы белән язылган аерым мәкаләләрдә шагыйрь иҗатына мөнәсәбәттә объективлык җитмәү («Татар шагыйрьләре», 1908). Иң соңгы язмаларының берсендә Тукай шигъриятенә, теоретик әзерлегенә, шигъри талантына каршылыклы мөнәсәбәт белдерүе («Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим», 1923).

«Язган нәрсәләре белән йөрәкләрне кузгатучы», «күңелгә әллә нинди фикер вә хисләр бирүче», «мәгыйшәтнең начар вә яхшы якларын гына ачык күрсәтә торган» Г. Исхакый турында Ф. Әмирхан. Язучының әдәби әсәрләре уңае белән язылган иң соңгы рецензияләреннән берсе — «Зөләйха», 1917. Рухани фаҗиганең югары сәнгати бәя алуы, аның «иске хөкүмәткә каршы гаять куәтле бер обвинительный акт» буларак ассызыклануы, пьесаның әһәмияте иҗтимагый-милли яссылыкта

билгеләнү («Гаяз», 1907, «Солдат» 1908, «Мөгаллим», 1914, «Алдым-бирдем», 1907 һ. б. мәкаләләр).

Ф. Әмирханның сәнгать тәнкыйте. Татарча спектакльләргә, әдәбият кичәләренә, концертларга язылган тәнкыйди мәкаләләре. Аларда сәхнә осталыгы, талант, режиссура, актерлык сәләте, кием-салым, сәхнә бизәлеше, зыялылык кебек мәсьәләләргә игътибар ителү. Аерым бер рецензияләрендә әдәби тәнкыйть белән театр тәнкыйтенең кушылып китүе.

«Әдәбиятка гаид», 1908, «Мәктәпләребездә татар әдәбияты», 1910 һ.б. мәкаләләрдә ф. Әмирханның әдәбият тарихына һәм әдәбият теориясенә караган фикерләре.

Вопросы и задания для самопроверки и контроля (Үзконтроль өчен сораулар һәм биремнәр):

1. Ф.Әмирханның әдәби әсәрне бәяләү принципларын санагыз.
2. Ф.Әмирхан әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә Г.Исхакый әсәрләрнең бәяләнеше.
3. Г.Ибраһимовның “Татар шагыйрьләре” хезмәтендәге эстетик карашларының романтик тәнкыйтьне формалаштырудагы әһәмияте
4. Г.Ибраһимовның Г.Тукай шигъриятенә нисбәтле әдәби-эстетик карашларының үзгәрешен күзәтегез.
5. Г.Ибраһимов тәнкыйди эшчәнлегендә нинди жанрлар өстенлек итә.

ТЕМА 5 Тоталитаризм дәвере татар әдәби тәнкыйте (1920 еллар - 1950 елларның уртасы).

Аннотация

1920-1950 елларның беренче яртысында татар әдәби тәнкыйтенең катлаулы, каршылыклы һәм фаҗигале үсеш юлы гыйльми күзаллана. 1920 еллар әдәби тәнкыйтендә күзәтелгән гыйльми юнәлешләрнең кире кагылып, норматив, партияле әдәби тәнкыйть формалашу юлы күрсәтелә. Идеодогик

басым йогынтысында әдәби-тәнкыйди ориетирларның үзгәреше чор тәнкыйтьчеләре эшчәнлеге мисалында раслана. “Конфликтсызлык теориясе”, “әдәбиятта кимчелексез уңай герой” күренешләренең асылы ачыла.

Ключевые слова (төп төшенчәләр): марксистик-ленинчыл эстетика, социологизм, эстетика, партиялелек, сыйнфыйлык, халыкчанлык, партияле тәнкыйть, вульгар социологизм, шәхес культы.

Методические рекомендации по изучению темы (Теманы үзләштерү өчен методик рекомендацияләр):

- 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң яңа социокультурологик шартларда норматив, “партияле” тәнкыйть барлыкка килү, аның әдәби барышка берьяклы йогынтысы хакында лекция материалы урнаштырылган;

- Студентларга мөстәкыйль эш сыйфатында бирелгән темалар буенча презентацияләр үткәрү өчен материаллар тупларга, иҗади һәм контроль эшләр эшләргә, түгәрәк өстәлгә материал сайларга һәм төрле актуаль темаларга чыгышлар ясарга әзерләнергә тәкъдим ителә,

- Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максаты белән һәр темага сораулар һәм биремнәр бирелә.

Источники информации (Информация чыганаклары):

1. Гыйлаҗев Т. Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900-1925). Методик кулланма – Казан, 1999. – 42 б.
2. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.
3. Гыйлаҗева Ч.М. Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. - Казан: РИЦ . 2012. -208 б.
4. Галиева Э.Р. Татар әдәбияты белемендә культура-тарих мәктәбе / Э.Р. Галиева. – Казан: Фән, 2002. – 360 б.
5. Галимуллин Ф.Г. Әле без туганчы (1920-1930 еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш) / Ф.Г. Галимуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – 320 б.

6. Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). – Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.

7. История русской литературной критики: Учеб. для вузов / В.В.Прозоров, Е.Г.Елина и др.; Под ред. В.В.Прозорова. – М.: Высш. Шк., 2002. – 463 с.

8. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 4 том / Татар совет әдәбияты (1917-1941). – Казан: Татар. кит.нәшр., 1989.- 566 б.

9. Татар әдәбияты тарихы Алты томда. 5 том / Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбиты (1941-1960). - Казан: Татар. кит.нәшр., 1989.- 542 б.

Интернет-ресурсы (Интернет-ресурслар):

1. dic.academic.ru/dic.nsf/bse/104011/**Литературная**
2. bse.sci-lib.com/article070749.html
3. http:// kitap.net.ru
4. kitapxane.at.tt
5. tatar.org.ru и др.

Список сокращений (кыскартылмалар исемлеге):

В.С. - вульгар социологизм

Г.Толымбай – Гомәр Толымбай

Х.Наум – Хәнәф Наум

С.Каратай – Сәгыйть Каратай

Ф.Мөсәгыйть- Фатих Мөсәгыйть

Г.Нигъмәти – Галимҗан Нигъмәти

Г.Гали -Гомәр Гали

МӘ – матур әдәбият

ӘД – әдәби тәнкыйть

ӘӘ – әдәби әсәр

Әд- әдәбият

М-н –мәсәлән

Соцреализм – социалистик реализм

ТӘТ – татар әдәби тәнкыйте

Глоссарий (Сүзлекчә):

Вульгар социологизм – марксизм идеологиясенең сыйнфыйлыгы мәсьәләсен үтә берьяклы аңлатудан килеп чыккан һәм тарихи-әдәби процессны гадиләштерүгә, схематизмга китергән карашлар системасы.

Социалистик реализм – реалистик юнәлешнең бер агымы, Советлар Россиясендә татар совет әдәбиятының әйдәп баручы иҗат методы буларак тәкъдим ителә. Аның танып-белү өлкәсе коммунистик идеал һәм марксиситик-ленинчыл идеология яктылыгында тормышны үзгәртеп кору белән чикләнә. Максаты совет социалистик җәмгыятен төзү этапларын һәм коммунизмга бару юлын яктырту кебек билгеләнә.

Әдәбиятта партиялелек – әдәбиятта билгеле бер иҗтимагый-тарихи, социаль-сыйнфый тенденция, әдәби иҗатның аңлы яисә аңсыз рәвештә туган идеологик юнәлгәнлеге, язучының аның иҗатыннан объектив рәвештә килеп чыга торган иҗтимагый тормыш позициясе.

Әдәбиятта сыйнфыйлык – әдәбиятның иҗтимагый характеры белән бәйле сыйфат. Әдәбият җәмгыятьнең тормышын чагылдыра:һәр катлам, һәр сыйныф үз мәнфәгатьләре белән, үз шартларында яши икәнлеге күренә. Язучы аңлы рәвештәме, әллә реалистик дөреслек белән чын хакыйкатьне язуы аркасында үз ихтыярыннан тыш, объектив рәвештәме, кайсыдыр иҗтимагый катламның, сыйныфның интересларын чагылдыра., аны яклый – шул рәвешчә билгеле бер сыйныфка хезмәт итә. Әдәбитяның әнә шундый юнәлгәнлеге, тенденциозлыгы, социаль яктан әһәмиятле, кирәкле мәсьәләләрне күтәреп,, аларны билгеле бер сыйныф позициясеннән карап хәл итүе сыйнфыйлык дип атала.

Вопросы для изучения (Өйрәнү өчен сораулар):

1. 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң Россиядә кискен иҗтимагый-рухи, икътисадый-сәяси үзгәрешләр һәм яңа иҗтимагый-сәяси вәзгыятьнең мәдәниятькә, әдәбият-сәнгатькә йогынтысы.

2. 1920 еллар әдәбият белемендә һәм әдәби тәнкыйтьтә әдәби юнәлешләр, әдәби, эстетик фикер тартышы.

3. Әдәбият фәненең яңа марксистик-ленинчыл методологиясе эшләнү һәм аның әдәбият белеме, шул исәптән әдәби тәнкыйтькә тәэсире.

4. 1920-1930 елларда партияле тәнкыйть формалашу.

5. И.В.Сталинның шәхес культы һәм аның татар зыялылары, милли әдәбият тарихында чагылышы.

Лекция №5. **Тоталитаризм чоры татар әдәби тәнкыйте (1917-1950 елларның беренче яртысы)**

1917 нче елдан соң татар әдәби тәнкыйте үзенең тарихында икенче – каршылыклы, авыр һәм фаҗигале дәвергә килеп керә Совет чоры әдәби тәнкыйте үз эчендә берничә баскычка бүлеп өйрәнелә (1917-1950 (соңгы елларда басылып чыккан хезмәтләрдә бу чорны "тоталитаризм чоры татар әдәби тәнкыйте" дип атыйлар); "тоталитаризмнан соңгы дәвер татар әдәби тәнкыйте" дип аталган чор эчендә ике баскыч - 1960 нчы еллар, 1970-1980 еллар аерылып тора). Совет чорында эстетик тәнкыйтьнең традицияләре җимерелә, аның аерым функцияләрен әдәбият белеме үз өстенә ала. Автор белән укучы аралашуының инкыйлаби-демократик тәнкыйть нормаларына нигезләнгән яңа формалары, алымнары барлыкка килә. Әдәби тәнкыйть әдәби әсәрне бәяләүнең эстетик үлчәмнәреннән баш тартып, аларны социологик концепциягә буйсындыра.

1920 нче елларда әдәбият галимнәренең һәм тәнкыйтьчеләренең (Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Г.Сәгъди, Г.Гали һ.б.) гыйльми-тәнкыйди эшчәнлегендә яңа совет әдәбиятының чынбарлык, җәмгыять белән бәйләнеше, әдәбиятта сыйнфыйлык һәм партиялелек принциплары, иҗат методы һәм әдәби герой, әдәби мираска мөнәсәбәт мәсьәләләре куела. Бу проблемаларны аңлауда шул чор язучылары, шагыйрьләре дә (Ф.Бурнаш, К.Тинчурин, Һ.Такташ, К.Нәҗми, М.Җәлил, А.Шамов, Ә.Фәйзи һ.б.) катнаша. Әдәби тәнкыйть, бу үзәк мәсьәләләрне үзләштерүдә пролетар

идеологиягә нигезләнеп, нәфис әдәбиятның эстетик кыйммәтен, сәнгать кануннарын күләгәдә калдыра, әдәбиятның социологиясен, сыйнфыйлыгын беренче планга куя. Дөрес, матур әдәбиятның табигатенә, асылына каршы килә торган чит, ят кануннарга каршы тәнкыйди фикер көрәшеп карый. Эстетик тәнкыйть традицияләрен саклау омтылышы Җ.Вәлиди, Ф.Әмирхан, Г.Рәхим, Г.Гобәйдуллин хезмәтләрендә күзәтелә: Җамал Вәлиди һәм Галимҗан Ибраһимовның үзара мөнәсәбәтләренең киеренкеләшүенең башы илдә барган сәясәтнең торышына барып тоташа. Җамал Вәлиди инкыйлабка кадәрге булган татар әдәбияты белеме һәм әдәбият тарихын өйрәнү өлкәсендә алып барган иҗади эзләнүләре нәтиҗәсендә формалашкан һәм ныгыган әдәби-эстетик карашларыннан, хакимият басымы астында кайберәүләр төсле, большевиклар хакимияте урнашкач та ваз кичми, үз фикерләрен кыю төстә яклавын дәвам иттерә. Һәм шул рәвешле Г. Ибраһимов карашлары белән каршлылыкка керә. Җ. Вәлиди үткәндәге әдәби мираска тискәре караш, әдәбият, сәнгать әсәрләренә бары тик сыйнфый күзлектән генә чыгып бәя бирүләр белән килешми, тәнкыйди мәкаләләрендә (“Әдәби мөсахабә” (“Әдәби әңгәмә”) (1922)) әдәбият, сәнгать әсәрләрен анализлаганда иң беренче чиратта аларның үзләренә генә хас образлы фикерләү, эстетик тәэсир итү сыйфатларын ачыклауны әдәби тәнкыйтьнең иң төп бурычларыннан берсе икәнлеген исбатларга тырыша [6, 337-346].

Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашлары Җ.Вәлидинеке белән тәңгәл килми. Г. Ибраһимов, әдәбият, сәнгать – К. Маркс, Ф. Энгельс тәгълимәте буенча, беренче чиратта хакимият идеологиясе белән тыгыз мөнәсәбәттә каралырга тиеш дигән фәнни ысулны яклый. Ягъни, үткән әдәби мирас, Г. Тукай, Ф. Әмирханнар иҗаты аның буенча, үз заманы өчен генә әдәби эстетик әһәмияткә ия, аларда күтәрелгән фикерләр, мәсьәләләр хәзерге тормышка ярамыйлар, мәгънәләре ягыннан да инде үткән, артта калган булып саналалар, бәяләнәләр.

Ж.Вәлиди “Матбугат дөньясы. Әдәби мөсәхабә”, 1922; “Аңларга тырыштык, аңлый алмадык”, 1922; Г.Рәхим “Нәләтләр шагыйре”, 1923; “Казакъ кызы”, 1925 һ.б.).

Әдәбиятның җәмгыять белән бәйләнеше мәсьәләсенә Г.Ибраһимов “Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы” (1922), “Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен билгеләү мәсьәләләре” (1923) “Пролетариат әдәбияты турында” (1924) хезмәтләрендә туктала. Әдәбиятның соөиологиясен тикшергәндә “марксистлар өчен тарихның бөтен материалы – идеологиянең “әдәбдиятның бөтен тармаклары һәммәсе дә ти к үткән тормыштагы техниканың, иҗтимагый-икътисадый эшләрнең өскә чыгарган бимешләре генәдер” кебек берьяклы фикерләпе өстенлек итә. Әдәбиятның җәмгыять белән бәйләнешен турыдан-туры аңлап, иҗтимагый аңның үзенчәлекле төре булган сәнгать, шул исәптән әдәбиятка да тар, чикләнгән караш урнаша. ӘТ еш кына әд-ның иҗтимагый һәм сыйнфый моментына өстенлек биреп, аның эстетик ягын игътибар үзәгеннән читтә калдыра.

Әдәби үсешне социаль-икътисадый һәм идеологик ситуацияләрнең туры чыгарылмасы итеп карау нәтиҗәсендә, 1917 елга кадәрге әдәби мираска “буржуаз әдәбият” дип тамга сугыла.

Г.Сәгъдинең дә ӘТ эшчәнлеге мондый мавыгулардан азат түгел. “Татар әдәбияты тарихы” (1926), “Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты” (1930) хезмәтләрендә әдәби әсәр теге яки бу чорның тарихи закончалыкларына иллюстрация сыйфатында гына мәйданга килми, иҗтимагый үсеш спецификасын ачып салу белән бергә, ул үз үзенчәлекләрен дә эшкә җигә дигән карашын эзлекле үткәрә алмый. “Пролетариат дәверендә...” дигән китабында эпоха стиле белән әдәбият стиле арасында турысызыклы тиңдәшлек үткәрә.

Дөрес, аерым тәнкыйтьчеләр мәкаләсендә, эстетик карашларында сәнгатьнең иҗтимагый-икътисадый нигезләр белән катлаулы бәйләнешен күрергә омтылу, аның әдәбиятка тәэсирен билгеләргә тырышу була. М-н, Г.Гали “Без әдәбият тарихын ничек аңлыйбыз” (1927) мәкаләсендә

әдәбиятның сәнгатьчәлеген тикшерүгә игътибар итә башлый: “Әдәбият тарихының төп материалы, тикшерелә торган нәрсәсе матур әдәбият булырга тиеш. Әдәбият өчен генә мөмкин булган моментларны тикшерүдә, мәгълүм иҗтимагый-икътисадый барышның МӘ – ка ничек тәэсир итүен тикшерү дә булырга тиеш”

Г.Нигъмәти дә мәсьәләнең бу ягына игътибар итә, аның фикеренчә, әдәбият социаль-икътисадый хәл һәи идеологик ситуацияләрнең автоматик чагылышы түгел, ә чагыштырмача мөстәкыйль иҗтимагый организм, һәм аның “үзенә караган аерымлыклары” да бар.”Галимнең “Әдәбият фәненең үсеше нинди булырга тиеш” (1930), “Әдәби тәнкыйтьтә механистлык һәм эклектиклыкчыгыгшларга каршы”(1931), “Әдәбият һәм тормыш” (1931) хезмәтләре һәм мәкаләләре ВС карашлардан азат булмасалар да, әдәбиятның җәмгыятькә бәйләнеш үзенчәлеген аңлауга зур өлеш кертәләр.

Чор тәнкыйтендә әлеге проблема белән тыгыз бәйләнештә әдәбияттта папртиялелек, әдәбиятның сыйнфыйлыгы һәм халыкчанлыгы мәсьәләләрен аңлау юнәлешендә дә көрәш бара. Сүз сәнгатенең сыйнфыйлыгы проблемасы һәр тәнкыйтьчедә кызыл җеп булып бара.

Г.Сәгъди үзенең “ Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты” хезмәтендә болай дип яза: “Әдәбиятның төп юнәлеше ноктасы, аның характеры һәм төп сыйфаты, гомумән, мәгълүм бер сыйныф мәдәниятенең төп юнәлеш ноктасы,. шуның характеры, төп сыйфаты белән билгеләнә”. Ә инде җәмгыятьнең икътисадында хакимлек итүче сыйныфлар аның идеологиясендә дә хакимлек итәләр дигән марксистик формула әдәбиятта сыйнфыйлык, әдәбиятның социологиясен үтә тар мәгънәдә - пролетариат сыйныфы файдасына хәл итүгә китерә. Нәтиҗәдә XX йөз башы татар әдәбияты буржуаз җәмгыятьнең идеологик продукты дип игълан ителде.Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, Г.Гали, Ф. Сәйфи-Казанлы шушындый караштa торалар. Бу – бер. Икенчедән, Г.В.Плеханов, В.П.Переверзевларның сәнгать методологиясендәге ялгышларын тәнкыйть күзлегеннән үткәреп файдаланмау сыйнфыйлык проблемасын аңлауны тагын да чуалта.

Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, Н.Исәнбәт. Ф.Бурнаш кебек язучыларга бик каты тәнкыйтькә эләкте.Бурнаш – “татар милли буржуаз язучысы”, Кутуй – фабрикант малае”, Ш.Маннур – “кулак җырчысы”, Айдар – “сарай җырчысы, ишан малае” дип игълан ителде. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, С.Сәмиев кебек классик язучыларның мирасы да социаль чыгыш ноктасыннан өйрәнелә.

!920-1930 еллар тәнкыйте татар халкының күп өлешен тәшкио иткән крестьян сыйныфына нинди мөнәсәбәттә тора соң. Әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә крестьян сыйныфына икеләнеп, шикләнеп карау, аңа ышанычсызлык күрсәтү, санга сукмау, “тарау, аңсыз, караңгы” кебек мыскыллы караш урнаша. Аның психологиясендәге вак милекчелек, ялгызлык, сәүдәгә омтылыш кекбек сыйфатлар күпертелеп, калкуландырылып сурәтләнә. ӘТ тә язучы, шагыйрьләрдән дә крестьян образын шул рәвешчә тасвирлау таләп тиә: “Марксизм, берәүдән яшермичә, крестьянствоның вак буржуа һәм хосусый милекче икәнен ачык әйтә. Тарихта да, гыйлемдә дә, театрда да, сәнаигъта да, җырда да, әдәбиятта да типичный крәстиән, марксиситлар өчен, тик әнә шулай тасвир кылганда гына дөрест була, шул тәкъдирдә генә тормышны аңлауга материал була”, - дип яза Г.Ибраһимов “Аңларга тырышыгыз,туганнар!”(1923) мәкаләсендә.

ӘТ шулай ук һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һ.б. социаль төркемнәр, катлаулар мәнфәгатьләрен чагылдыру проблемасы да идеологиядә хакимлек итүче сыйныф интересларында хәл ителә.

Партиялелек принцибы, әдәбият-сәнгать, иҗат эше белән җитәкчелек итү өчен большевиклар (коммунистлар) тарафыннан эшләнеп, өстән төшерелә, ягъни шулай ук идеологик, сәяси күренеш була. Татар әдәби тәнкыйте дә аны хәл итүгә сыйнфыйлык принцибы аша килә. Партиялелек дигәндә тәнкыйтьчеләр. Әдәбият галимнәре ачык, аңлы һәм эзлекле рәвештә чагылган социалистик идеялелек, пролетариат сыйныфының мәнфәгатьләрен сәнгатьчә яклауны күздз тоталар. Бу тормыш материалы. Чынбарлык “әдәбиятта урын алганда, пролетариат күзлегеннән карап бирелсен” дигән

берьяклы таләп куелуга китерә. Партиялелек бер эшче сыйныфына гына хезмәт итә башлый. Крестьян, һөнәрчеләр һ.б. социаль төркем мәнфәгатьләре пролетариат идеологиясе – марксистик идеология ноктасыннан чагылдырыла башлый. Партиялелек милли әдәбиятның идеология, сәясәт белән бәйләнешен тагын да көчәйтә. Әдәбияттта революцион, социалистик идея-эчтлек белән артык мавыгу әдәбият һәм сәнгатьнең үз кануннары һәм үлчәмнәре (критерийлары) булуын еш кына арткы планга калдыра. Нәтиҗәдә әдәбият һәм сәнгать кануннары һәм үлчәмнәре сәяси критерийлар белән алмаштырылуга, "әдәбиятның сәясәт белән үрелеп үсүенә китерә" 1930 елларда әдәбият "дәүләт милкенә", идеологиягә әверелә. Сәясәттә И.В.Сталиннын "социализм җиңә барган саен, сыйнфый көрәш кискенләшә" дигән демагогик теориясе матур әдәбитка да үтеп керә. Муса Җәлил "Матур әдәбиятыбыз алдындаүзәк проблемалар" мәкаләсендә язганча, "МӘ үсешен, барышын сыйныфлар көрәшенең нәтиҗәсе" итеп тикшерә башлыйлар.

1920 елларда әдәбиятның сәнгатҗчәлеге, эстетик атегорияләре турында сүз алып барыла. Ләкин ул әдәбият һәмсәнгатьнең икенчел дәрәҗәдәге сыйфаты, иярчен үзенчәлегебуларак карала. М-н, Г.Ибраһимов "Өч җавап" (1922) мәкаләсендә 2шигырь, әдәбият, һәрнәрсәдән элекәдәби булсын, худоңество бирсен, җанлы тасвир бирсен" дип чыгы. Сәнгатьчәлек мәчсьәләсенә Ф.Бурнаш, Г.Гали игътибар итә. Г. Нигъмәти "Үсү һәм тирәнәю елы"(1928) мәкаләсендә әсәрләрне коры идеяләр схемасына, политик иллюстрацияләрсенә әйләндерхдән сакланырга чакыра.

Г.Сәгъди дә замандашларының карашларын куәтләп, " Пролетариа диктатурасы дигән хезмәтендәбу проблемага игътибар итеп, "Әлбәттә, әдәбият үзенең бөтен табигате белән сыйнфый һәм тенденцияле булган ибтимагый хәдисә, - дип язды. – Әдәби әсәрләрнең әдәби кыйммәте әнә шул тенденцияне сәнгатҗчә бирә белүдә, ягъни тенденция һәм агитация күзгә ачык бәрелеп торган бер рәвештә ялангач булмасын, бәлки сәнгать киеменә төрелеп, бизәндерелеп бирелгән булсын". Югарыда күренгәнчә, ӘӘ нең художестволылыгы- сәнгатьчә эшләнеше хакында таләплә нигездә дөрес

куела, әмма алар язучы-шагыйрьләр иҗатында, тәнкыйтьче бәя-анализларында алар эзлекле тормышка ашырылмыйлар.

1920 елларның уртасына таба ТӘТ ендә үзәк проблемаларның берсен иҗат методы мәсьәләсе алып тора. Совет әдәби тәнкыйте үсешенең бу чорында проблема хәл ителешенә ВС нык комачаулый. Ике дәвер – Октябрьгә кадәрге һәм Октябрьдән соңгы чор әдәбиятлары араындагы күчемлелек инкарь ителә. Бер төркем тәнкыйтьчеләрһәм әдәбиятчылар традицияләрне кире кагалар, XX йөз башы татар әдәбиятының казанышларыннан берсе сәнгатьчә реализм кабул ителми. Г.Ибраһимов. Г.Нигъмәти, Г.Сән\гъди Гали Ходаяров, һ б. татар әдәбиятының революөиягә кадәрге үсеш этабында булган реалистик юнәлеш яңа чорда да дәвам иттерергә кирәклекне яклап чыгалар.

Г.Нигъмәти “Әдәбият мәйданында” (1925), “РЕволюция елларында әдәбиятыбыз” (1929), “Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре” (1933), “Социалистик реконструкция чорында татар сове матур әдәбияты” (1934) дигән хезмәтләре иҗат методы эстетикасын аңлау һәм үзләштерүгә юнәлгән. “реализм – тормышны чын көенчә, хыл буяуларына буямыйча, булганынча аңларга һәм аңлатырга тырышу. Бу юл белән язучы. әдип тәтормышны әнә шур югарыда әйтелгәнчә итеп тәхсиф итәргә. Күрсәтергә тырыша”, - дип реализмның тормышны объектив сурәтләвенә, аны бар көенчә чагылдыруына басым ясый (“Әдәбият мәйданында”).

Г.Сәгъди исә “Татар әдәбияты тарихы” (1926), “Пролетариат диктатурасы ...” (1930) дигәнихезмәтләрендә яңа әдәбиятның реализм юлыннан үсүен яклый. Ул, мәсәлән, “пролетариат диктатурасы ...” дигән хезмәтендә: Реализм совет әдәбиятының төп. Үзәк ноктас, төп хасияте. Аның өслүбе дә төбендә реализм өслүбе” дип билгели.

1920 еллар ахырына инде чынбарлыкны чагылдыру мәсьәләсендә аерым бер таләпләр куела башлый, ягъни яңа реализмның принциплары һәм кагыйдәләре эшләнә. Әдәби тәнкыйть совет язучылары алдына катгый таләбен – тормышны бөтен тулылыгы, катлаулылыгы белән иңләп язу, әмма

социалистмик төзелеш мәнфәгатьләре ноктасыннан чагылдыру бурычын куя. Чынбарлыкны И.В.Сталин партиясенә, аның хөкүмәте мәнфәгатҗләренә җавап бирерлек, “дөреслекне сайлап алу методы” – социалистик реализм методы формалаша. 1932 елда А.М.Горький иҗат методына исем тәкъдим итә.1934 елда совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездында кабул ителеп ныгытыла.

Әдәби-эстетик фикер үсешенең бу чорында романтизм методының урыны һәм роле мәсьәләсе, аңа мөнәсәбәт катлаулы һәм каршылыклы була. Романтизм еш кына совет әдәбиятына чит, “консерватив” агым буларак карала. Тәнкыйтьчеләр һәм галимнәр (Г.Нигъмәти, Г.Сәгъди. Г.Гали һ.б.) романтизмны реализмга каршы куеп, дөньяга караш ноктасыннан өйрәнәләр. Шунысын әйтергә кирәк: бу иҗат методы 1920 еллар әдәби тәнкыйтендә һәм әдәбиятында мөстәкыйль иҗат методы буларак яши. Ләкин романтизмны “идеологик яктан яхшырту”, “кызылландыру” сызыгы барлыкка килә. Бу методның бер канаты булып “кызыл романтизм”,”революцион романтизм”, “актив романтизм” атамалары кулланылышка керә. Г.Нигъмәти “Социалистик реконструкция чорында татар совет матур әдәбияты” (1934), “татар совет әдәбияты күтәрелештә” (1934) дигән хезмәтләрендә совет әдәбиятында романтизм урыны мәсҗәләсе карала. Соц. Реализм реализм һәм романтизмның синтезы, “кызыл романтизм социалистик реализмның аерылмас бер тармагы”дип игълан ителә..Романтизмның сурәтләү чаралары, традицияләре соцреализмның эстетикасын баетучы, тулыландыручы чаралар. формаларбуларк тәкъдим ителә. 1920-1930 еллар ТӘТе социалистик реализмны совет сәнгате һәмәдәбиятының бердәнбер иҗат методы дип тәкдим итә, романтизм моның нәтиҗәсендә мөстәкыйль метод буларак яшәүдән туктый. Димәк, социалистик реализм марксист галимнәр тарафыннан формалаштырылган бер уйдырма, рәшә, миф кына түгел, ул әдәби күренеш буларак бар, таихи үткәнебез, XX гасыр 1930-1980 еллар әдәбиятның бер үзенчәлеге.

1920-1930еллар тәнкыйтендә югарыда тикшерелгән проблемалар белән тыгыз бәйләнештә әдәби герой мәсьәләсе тирәсендә дә гыйльми-нәзари эзләнүләр алып бара. Тәнкыйтьчеләр аңа чор таләбеннән, яңа чынбарлыктан чыгып якын киләләр. Совет әдәбиятының төп герое итеп совет чынбарлыгының яңа кешесе, эчке дөньясы бай хезмәт кешесе торырга тиеш дигән формула урнашканчы, әдәби тәнкыйтькә күп ялгышулар, эзләнүләр баскычын үтәргә туры килә. 1920 елларда "стандарт кеше", "коллектив герой", "схематик герой". "тере кеше", "җанлы кеше" кебек атамалар киң кулланылышта йөри. Әдәби герой мәсьәләсе Г.Нигъмәти, Г.Сәгъди, Г. Ибраһимов, Закир Гали, К.Нәҗми язмаларында, монографик хезмәтләрендә күтәрелә. Ләкин алар әдәби герой проблемасына революцион көрәш, социалистик төзелеш ноктасыннан якын киләләр. Аның характерындагы сыйнфый сыйфатларга өстенлек бирелә.Геройның эчке дөньясына, шәхси мәнфәгатьләренә аз игътибар ителә. Инкыйлаблар һәм гражданнар сугышы чорында мәйданга чыккан яңа герой – көрәшче тибы әдәби процесста әйдәп баручы буларак яңгыраш таба. Әлеге герой төп максатында халык бәхетен, аның киләчәген кайгыртса да, моңа ирешү юлында күпгасырлык татар әдәбияты традицияләреннән читләшә. Ул еш кына кан коюны яклый, ашкынып сыйнфый көрәшкә ташлана.Бу позиция заман героен аңлауда да берьяклылыкка китерә: әдәби герой революция эше өчен кирәкле социаль-психологик тип буларак формалаша.

Әдәби геройны бары эш кешесе итеп күрергә теләү, аны шәхси тормыштан тулысынча мәхрүм итәргә тырышу кебек, революцион аскетизм идеяләреннән һәм вульгар социологизм концепциясеннән килә торган эстетеи карашлар 1930 елларда Әхмәт Фәйзинең "Сәхнәдә йөрүче аяклы плакатлар белән тамаша залында утыручы геройлар" (1933), Муса Җәлилнең "Совет драматургиясе яңа чорда" (1933), "Чакырылучы ударникларның иҗатлары турында берничә сүз" (1933) һ.б. мәкаләләрендә һәм тәнкыйтькә шушы хәвефле елларда килгән Гали Халит, Хәсән Хәйри, Гази Кашшаф, Фатих Хөсни, Латыйф Җәләй эшчәнлекләрендә кире кагыла башлый. Әдәби

геройны психологик яктан баетуга басым ясала.1930 еллар әдәби тәнкыйте төп геройны сурәтләүгә бүгенге көн күзлегеннән караганда, шактый югары, дөрес таләпләр куйса да, “дәүләт заказы буенча язылган әдәби әсәрләр партиянең, хөкүмәтнең алып барган сәясәтен иллюстрацияләүче геройны, “үз мин”ен югалткан кешелексез геройны үзәккә куя.

Матур әдәбиятта идеологиянең, сыйнфыйлыкның ролен арттыру 1920-1930 еллар чикләрендә вульгар социологизм шаукымының активлашуына китерә (Г.Толымбай, Х.Наум, С.Каратай, Ф.Мөсәгыйть).

Вульгар социологизм – марксизм идеологиясенең сыйнфыйлыгы мәсьәләсен үтә берьяклы аңлатудан килеп чыккан һәм тарихи-әдәби процессны гадиләштерүгә, схематизмга китергән карашлар системасы.

ВС-ның төп сыйфатлары:

а) әдәби иҗатны икътисадый мөнәсәбәтләргә турыдын-туры бәйләү;

б) сурәтләү чараларын: фраза төзелеше, метафора, ритм һ.б.икътисадый факторлар белән аңлату;

в) тарихи чынбарлыкны кайсы да булса сыйныф тормышының материаль шартлары белән чикләү;

г) чор тормышының гомумкешелек, сәяси, идеологик, психологик һ. б. күптөрле якларын исәпкә алмау;

д) әдәби иҗат процессын чынбарлыкны пассив фиксацияләүгә кайтарып калдыру;

е) әдәби әсрнең эчтәлек һәм максатын тәңгәлләштерү һ.б.

1930 нчы елларда көчәйгән И.В.Сталинның шәхес культы һәм ул тудырган “сыйнфый көрәш” теориясе татар әдәби тәнкыйтендә үзенең тирән, фаҗигале эзен калдыра. Тәҗрибәле, теоретик әзерлекле, марксистик-ленинчыл тәгълиматка ышанып, социалистик төзелешкә үзләрен багышлаган тәнкыйтьчеләргә, әдәбият галимнәренә, язучыларга хаксызга яла ягыла, ярлыклар тагыла һәм күпләренең тормышлары И.В.Сталин төрмәләрендә фаҗигале рәвештә өзелә (Г.Ибраһимов, Г.Рәхим, Г.Нигъмәти, Җ.Вәлиди, Г.Гали, Ф.Бурнаш, К.Тинчурин һ.б.).

Тоталитаризм чоры тәнкыйтендә 1932 -1950 елларның уртасы күпмедер күләмдә аерылып тора. 1932 елда ВКП (б) ҮК ның “Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында” (О перестройке литературно-художественных организаций”) дигән карары чыга. Аның нәтиҗәсендә аерым әдәби төркемнәр, ассоциацияләр юкка чыгарылып, язучыларны бер союзга берләштерү эше башлана. Ә инде 1934 елда булыа үзган СССР язучыларның I корылтае әлеге үзгәрешләргә нәтиҗә ясый. Әдәби иҗат белән шөгылҗләнүчеләрне гомум әдәби-эстетик методология тирәсендә туплау, аларның эшчәнлеген билгеле бер нормативларга нисбәтле чикләү белән әдәбият үсешендә генә түгел, татар әдәби тәнкыйте тарихында да яңа чор башлана. 1930 елларда әдәби тәнкыйтькә Г.Халит, Г.Кашшаф, Х.Хәйри, Х.Госман, М.Гайнуллин кебек яшь көчләр килә. Тәнкыйтьне үстерү, аның принципиальлеген арттыру кирәклеге турында мәкаләләр дөнья күрсә дә, алар гомум хәлне үзгәртә алмый (Ә.Фәйзи “Иҗат кыюлыгына – юл!”,1933; Г.Нигъмәти “Шәриф Камал – драматург”, 1934; Г.Гали “Тәнкыйть турында”,1935; Г.Кашшаф “Кави Нәҗминең ике повесте турында”, 1936; Г.Халит “Халык шагыйре Тукай”,1939 һ.б.).

Идеологик басым йогынтысында әдәби-тәнкыйди ориетирларның үзгәреше күзәтелә. Ул, бер яктан, иҗтимагый үзаңның чагылыш булган тәнкыйтҗтән әдәби әсәрләргә конъюктур бәя бирүне таләп итсә, икенче яктан. Әдәбият алдына куелган “киләчәкне революцион үсештә күрсәтә” бурычы тәнкыйтьтә тиз арада уңай, җиңүле, шатлыклы күренешләрне бәяләү-раслау төсен ала (Г.Нигъмәти “Татар совет драматургиясе югары сыйфат өчен көрәштә үсәргә тиеш”,1934; “Татар совет драматургиясе үсеше”, 1935 һ.б.)

Партиянең әдәбият һәм сәнгать белән җитәкчелекне тулысынча үз өстенә алуы, тәнкыйтьнең күрсәтмәләр буенча (бер карадан икенче карарага кадәр) яши башлавына китерә. Шуңа да бу чор тәнкыйтен “партияле тәнкыйть” дип атыйлар. Тәнкыйди язмалар кызыл һәм кара төсләр белән эш итә, бу исә әдәби-тәнкыйди бәяләрнең бертөрле һәм бермәгънәле булуына

китерә. Тәнкыйтьнең эчтәлеген билгеләүче сыйфатлар буларак гаепли торган фикер-бәянең кискенлеге, башка төрле караш булу мөмкинлегенә урын калмау, жанр һәм стиль ягыннан бертөрлелек алаг чыга.

1941-1945 сугыш елларында әдәби әнкыйтҗ икенче планда калса да, партиянең идеологик басымы кимеми. Аның бер чагылыш буларак дөнья күргән "Татарстан партия оешмаларында масса-политик эшнең торышы" дигән ВКП (б) ҮК ның 1944 елгы карары һәм аның татар мәдәнияте һәм әдәбияты өчен авыр нәтиҗәләре яхшы билгеле. Шушы карарда күрсәтелгән "кимчелекләрне" бетерү юнәлешендә ӨлкәҮК фикер хөрлеген, башкача бәяләү мөмкинлеген чикләгән бер дистәгә якын кара кабул итә.Сугыштан соңгы елларда "Звезда" һәм "Ленинград" (1946) журналлары буенча чыгарылган каралар, шулай ук А.Ахматова, М.Зощенко кебек шәхесләрне эзәрлекләүләр үз максатына ирешә: үзәктә һәм милли республикаларда әдәби тәнкыйть сүнеп-сүрелеп кала.

1940 еллар ахыры – 1950 еллар башында әдәби тәнкыйть үлем хәленә килә Үзенең демагогик ачыклыгы белән билгеле конфликтсызлык теориясен ул "корал итеп" алырга мәҗбүр була (Гомәр Бәширов "Татар совет әдәбиятында уңай герой (Татарстан язучылар союзының III съездындагы доклад)", 1954; Мирсәй Әмир "Кимчелексез уңай герой өчен", 1954 һ.б.). Әлеге хәл татар әдәби тәнкыйтендә дә саклана. Шулай да чор тәнкыйтенең акрынлап вульгар социологизм йогынтысыннан арына баруын ассызыкларга кирәк. 1950 елларда классик язучылар иҗатын бәяләүдә дә, әдәби процессны бер бөтен итеп күзаллауда да тәнкыйтьчеләр иркенрәк эш итә башлыйлар. Әдәби мәсьәләләргә объективрак караш ташларга һәм аларны киңрәк тикшерергә беркадәр мөмкинлек туа. Әдәби мирасны, шул чор әдәбиятын бәяләүдә И.Нуруллин, Б.Гыйззәт, Э.Нигъмәтуллин, Р.Шакуров, Н.Гыйззәтуллин, Р.Бикмөхәммәтов һ.б.лар активлык күрсәтәләр.

Вопросы и задания для самопроверки и контроля (Үзконтроль өчен сораулар һәм биремнәр):

1. 1920 елларда нәшер ителгән газета-журналларны санагыз.

2. Октябрь инкыйлабыннан соң тәнкыйли эшчәнлекләре 1910 елларда башланган тәнкыйтьчеләр белән бергә эшләгән яңа исемнәрне атагыз.

3. Г.Ибраһимовның “тарихи кыңгыравык өзелде” мәкаләсендә әдәби әсәрне бәяләүнең нинди кануннары һәм кагыйдәләре кире кагыла.

4. Партияле әдәби тәнкйтьнең үзенчәлекләрен санагыз.

5. “1920-1940 еллар татар әдәбият белеменең һәм тәнкыйтенең фаҗигале битләре динән темага эссе язылгыз.

6. Вульгар социологизм концепциясенең үзенчәлекләрен һәм милли сәнгатькә тискәре йогынтысын күрсәтегез.

7. ВКП (б) ҮК ның 1944 елгы “Татарстан партия оешмаларында масса-политик һәм идеологик эшнең торышы” карарының татар әдәбият белеме, шул исәптән әдәби тәнкыйтькә тискәре йогынтысын күрсәтегез.

8. Матур әдәбиятта “конфликтсызлык теориясе” нең барлыкка килү сәбәпләрен ачыклагыз

ТЕМА 6 Тоталитаризмнан соңгы татар әдәби тәнкыйте (1950 елларның икенче яртысы – 1980 елларның беренче яртысы).

Аннотация.

1950 елларның икенче яртысы – 1960 елларның иҗтимагый һәм әдәби-мәдәни характеристикасы бирелә. Әдәби тәнкыйтьтә яңарыш сыйфатлары барлана. Матбугат битләрендәге әдәби бәхәсләргә, шул чорның күренекле тәнкыйтьчеләре иҗатларына бәя бирелә. 1960-1980 еллар әдәби тәнкыйте үсешендәге тенденцияләр гыйльми күзаллана.

Ключевые слова (төп төшенчәләр): “җепшеклек” чоры, ярымдемократик үзгәрешләр, әдәби дискуссияләр, реабилитация, традицияләр, новаторлык, шартлылык.

Методические рекомендации по изучению темы (Теманы үзләштерү өчен методик рекомендацияләр):

- Тоталитаризмнан соңгы дәвер татар әдәби тәнкыйтендә күзәтелгән уңай тенденцияләр, чор тәнкыйтендәге яңа сыйфатлар турында лекция материалы тәкъдим ителәә;

- Студентларга мөстәкыйль эш сыйфатында бирелгән темалар буенча презентацияләр үткәрү өчен материаллар тупларга, иҗади һәм контроль эшләр эшләргә, түгәрәк өстәлгә материал сайларга һәм төрле актуаль темаларга чыгышлар ясарга әзерләнергә тәкъдим ителәә,

- Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максаты белән һәр темага сораулар һәм биремнәр бирелә.

Источники информации (Информация чыганаклары):

1. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.

2. Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). – Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.

3. История русской литературной критики: Учеб. для вузов / В.В.Прозоров, Е.Г.Елина и др.; Под ред. В.В.Прозорова. – М.: Высш. Шк., 2002. – 463 с.

4. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 4 том / Татар совет әдәбияты (1917-1941). – Казан: Татар. кит.нәшр., 1989.- 566 б.

5. Татар әдәбияты тарихы Алты томда. 5 том / Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбиты (1941-1960). - Казан: Татар. кит.нәшр., 1989.- 542 б.

Интернет-ресурсы (Интернет-ресурслар):

1. dic.academic.ru/dic.nsf/bse/104011/**Литературная**
2. bse.sci-lib.com/article070749.html
3. http:// kitap.net.ru
4. kitapxane.at.tt
5. tatar.org.ru и др.

Глоссарий (Сүзлекчә):

Әдәби герой - әдәби әсәрдә холык-фигыль сыйфатлары эш-гамәлләрендә, уй-фикерләрендә, теләк-омтылышларында калку сурәтләнгән кеше образы. Әдәби герой”персонаж” яки “катнашучы” төшенчәләре белән тәңгәл килә.

Яңачалык (новаторлык) - (латинча “яңартучы” сүзеннән) – иҗтимагый тормышта һәм яшәештә барлыкка килә торган яңалыкларны, яңа мөнәсәбәтләрне һәм күренешләрне, кешеләрдәге һәм җәмгыятьтәге яңа сыйфатларны сәнгатьчә яңа чаралар ярдәмендә дөрес итеп сурәтләү.

Традиция – (латинча “тапшыру”, “күчерү” мәгънәсендә) – үткән чорларның актуаль һәм кыйммәтле дип кабул ителгән, үзләштерелгән, яисә иҗат ориентиры итеп алынган культура-сәнгать тәҗрибәсе.

Символ (“шартлы билге” дигән мәгънәдәге грек сүеннән) – әдәбиятта метафорик алыштыруларга нигезләнгән сурәтләү чараларының бер төре.Символ – нинди дә булса күренешне, предметны аңлата торган шартлы сүз яки билге.Әдәбиятта символлар куллану гомумиләштерүне көчәйтергә, сурәтнең мәгънәви тирәнлеген һәм тәэсир итү көчен арттырырга ярдәм итә.

Вопросы для изучения (Өйрәнү өчен сораулар):

1. 1950 елларның икенче яртысы – 1960 еллардагы иҗтимагый-әдәби атмосфера.
2. Әдәби тәнкыйтьтә сыйфади үзгәрешләр.
3. Вакытлы матбугат битләрендә әдәби бәхәсләр һәм дискуссияләр.
4. КПСС ҮК ның “Әдәби тәнкыйте турында” карары: уңай һәм тискәре йогынтысы

Лекция №6. **Тоталитаризмнан соңгы татар әдәби тәнкыйте (1950 елларның яртысы – 1980 елларның I яртысы).**

Тоталитаризмнан соңгы дәвер тәнкыйте үз эчендә ике баскычка бүленә: а) 1950 елларның уртасы – 1970 еллар башы; б) 1970 еллар башы – 1980 еллар уртасы.

Татар әдәби тәнкыйте тарихында 1950 елларның уртасы – 1960 еллар тәнкыйте үзенчәлекле урын алып тора. СССР Язучыларының 1954 елда булып үткән II съезды И.В.Сталин вафатыннан соң сизелә башлаган үзгәрешләрне үстерү рухында үтә. Акрынлык белән татар әдәбиятында да чор, заман рухына йөз белән борылу сизелә башлый. 1960 нчы еллар әдәби тәнкыйтендә барлыкка килгән яңалыклар, яңача фикерләүгә мөмкинлек тудырылу И.В.Сталинның шәхес культы игълан ителеп, Н.С.Хрущевның ярымдемократик үзгәрешләре, "җепшеклек" чоры белән аңлатыла. Әдәби тәнкыйди фикер, идеологик күрсәтмәләрдән бераз арынып, бертөрлелектән субъектив башлангычка күчә, укучы белән аралашуның югалган формалары - әдәби бәхәсләр, дискуссияләр, хакимият басымыннан беркадәр бәйсез журнал тәнкыйте һ.б.лар кайтарыла. 1950-1960 еллар тәнкыйте күптөрле һәм чуар булуы белән характерлана. Бер яктан, партия җитәкчелеге демократик үзгәрешләргә азмы-күпме мөмкинлек бирә, икенче яктан, фикер хөрлеген, шәхси карашын яклаучыларны эзәрлекли. Б.Пастернакның "Доктор Живаго" әсәре өчен Язучылар союзыннан чыгарылуы шуның бер чагылышы булып тора. Татар әдәбиятының танылган шагыйре Салих Баттал 1961 елда "Батый ханга ачык хат" әсәрен бастырып чыгаргач, гаятҗ кычле эзәрлекләү башлана.

Татар сүз сәнгате, алда әйтелгәнчә, каршылыклы үсеш кичерә. М.Җәлилнең көрәше һәм иҗаты дөньякүләм яңгыраш ала, бу исә татар әдәбияты белән башка халыкларның кызыксынуын арттыра. Репрессияләнгән әдипләрнең иҗаты халыкка кайтарылу, җҗыентыклары басылып чыгу әдәбиятның үткәне һәм бүгенгесе, традицияләр дәвамчанлыгы турында фикер алышуга юл ача (Г.Бәширов. "Изге бурычлар",1955). Әдәби тәнкыйтьтә метод һәм стиль мәсьәләләре, аерым алганда, романтизм методы һәманың алымнарына уңай мөнәсәбәт чагыла. Г.Ибраһимов романтик иҗаты белән бәйле бу өлкәдә тикшеренүләр башлана (Н.Исәнбәт, И.Нуруллин, М.Хәсәнов хезмәтләре).

1950 еллар уртасыннан башлап әдәби процессны җанлы процесс итеп күзаллау омтылышы, бер яктан, уңай герой хакында җитди бәхәсләргә

китерсә, икенче яктан, заманчалык мәсьәләсе дә күтәрелеп, болар барысы да “конфликтсызлык теориясе”ннән арыну, сыйфат үзгәреше башлануны аңлата (Г.Әпсәләмов “Заман таләп иткән бурыч”,1958; Г.Минский “Заман темасы мәсьәләсенә карата”,1958; Р.Мостафин “Төп сызык”,1958 һ.б.). Әмма алар тәнкыйди фикернең нигез ташларына әверелгән сыйнфыйлык, партиялелек принципларына, социалистик реализм методына кагылмыйлар.

1960 еллар башында татар әдәбияты бик тә үзенчәлекле этап кичерә.”Җепшеклек” чоры формалаштырган әдипләр яңа форма, яңа эчтәлек эзләү аша тормыш-чынбарлыкны сәнгати сурәтләүдә җитди табыш-яңалыклар юлына чыга (аеруча сыйфади яңарыш шигърияттә зур яңгыраш ала). Шул рәвешле әдәбият мәйданында традицияләрне дәвам иткән һәм үткән казанышларга таянып, яңа сыйфат яңарышына ирешкән караш-концепцияләр очраша. Бу исә әдәби тәнкыйтьтәдә үзен ачык сиздерә: берәүләр борынгыдан килгән традицияләрне яклап чыкса, икенчеләр яңалыкны хуп күрә, өченчеләре исә аларның үрелеп, үзара бәйләнеп үсүенә ышана (Р.Бикмөхәммәтов, Нур Гыйззәтуллин, Энгель Нигъмәтуллин һ.б.).

Әдәби тәнкыйть тарихының тагын бер чорын 1970 еллар башыннан алып 1980 еллар уртасына кадәрге чор алып тора. 1972 елгы КПСС ҮК ның “Әдәби тәнкыйть турында” карары чыга. Ул социалистик лагерь белән капиталистик дөнья арасында “салкын сугыш” көчәеп, гәрчә идеологик максатларда кабул ителсә дә, моңа кадәр икенчерәк планда, күләгәдәрәк кала килгән әдәби тәнкыйтькә игътибарны арттыра, аның үсешендә мәгълүм роль уйный. Беренчедән, әдәби тәнкыйть фән буларак югары мәктәпләрнең уку планнарына кертелеп, университет, институт студентларына укытыла башлый. Икенчедән, бу юнәлештә гыйльми-нәзари эзләнүләрне көчәйтеп җибәрә. Мәсәлән, Казан дәүләт университетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентларына әдәби тәнкыйть тарихын ике дәвергә бүлеп, доцент М.С.Мәһдиев һәм доцент З.М.Мәҗитовлар укытты. Аларның лекцияләре фактологик материалга бай, тәнкыйди фикер үткән юлны тирән күзаллаулары белән аерылып тора иде. М.Мәһдиевнең әдәби тәнкыйтьнең

борынгы чордан алып 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр дәверен иңләгән лекция материаллары безне бөтенләй моңа кадәр билгеле булмаган, иясә аз таныш булган кызыклы шәхесләр иҗаты дөньясына, әдәби-мәдәни мохиткә алып керде. Лекторның идеологик буяулардан, шәрехләүләрдән азат лекцияләре, гәрчә дистә еллар үтсә дә, үзләренең фәннилеген, актуальлеген югалтмыйлар.

Бу этапта әдәбият тарихын бөтен тулылыгында өйрәнүгә омтылыш тагын да көчәя. Бу чорда әдәби тәнкыйтьнең әдәбият белеме белән якынаю тенденциясе сизелә. И.Нуруллин, Г.Халит, яшь көчләрдән Й.Нигъмәтуллина, Н.Юзеев, Р.Мостафин, М.Хәсәнов, З.Мәҗитов, А.Әхмәдулин, М.Мәһдиев, Ф.Хатипов, Ф.Мусин, Р.Ганиева һ.б.ларның татар әдәбиятының классик әдипләре турындагы монографик пландагы тикшеренүләре яңа фактларга, теоретик фикерләргә бай. Һәм алар татар әдәбиятының тулы тарихын барлыкка китерүдә билгеле дәрәҗәдә өлеш кертәләр.

Соңрак аларга Ф.Галимуллин, Р.Мөхәммәдиев, М.Вәлиев, Мөд. Вәлиев, Р.Рахмани һ.б. килеп кушыла. Бу еллар язучылар тәнкыйтенең активлашуы белән характерлана. Аерым алганда, Г.Бәширов, Ф.Хөсни, С.Хәким, М.Әмир, Г.Ахунов, Х.Сәрьян, Ә.Еники, И.Гази һ.б. ның әдәби тәнкыйть җыентыклары дөнья күрә. Аларның үзенчәлеге шунда, авторлар “әдәбиятны киңләп колачларга, аңа гомум бәя бирергә омтылмый, ә күбрәк үзенең шәхси карашын, уйлануларын чагылдыра. Ул үзен аеруча кызыксындырган, уйландырган һәм борчыган мәсьәләләр турында сөйли” (Мусин Ф. 2001). Шул ук вакытта чор тәнкыйтендәге уңай сыйфатлар рәвешендә профессиональ тәнкыйтьнең дә барлыкка килүен ассызыкларга кирәк. Ф.Миңнуллин, Р.Мостафин, Т.Галиуллин һ.б. кебек профессиональ тәнкыйтьчеләр үзләренең рецензия – бәяләмәләре белән чыгыш ясый башлый.

Алдагы чор әдәби-эстетик, тәнкыйди фикеренең төп бурычы булып әдәбият тарихын, аерым вәкилләренең тормыш юлын һәм иҗатын, чор нәфис әдәбиятының үзенчәлекле якларын өйрәнү эше кала. Бу чорда

тәнкыйтьчеләр, әдәбият галимнәре билгеле бер әдәби төр тирәсенә туплана төшәләр. Проза мәсьәләләрен өйрәнүдә Ф.Хатипов, Ф.Мусин, Р.Мостафин һ.б.лар активлык күрсәтәләр. А.Әхмәдуллин, Һ.Мәхмүтов, Н.Ханзаффаров һ.б.лар драматургияне тикшерүгә алыналар. Поэзия белән турыдан-туры Х.Госман, Г.Халит, Н.Юзеев, Т.Галиуллин, Р.Мөхәммәдиев, М.Вәлиевлар шөгыльләнәләр. Алар һәр төрнең кимчелекле, уңышлы якларын күрсәтеп, матур әдәбиятның үсеш тенденцияләрен билгелиләр.

Тәнкыйтьтә әдәби мирас, традиция һәм яңачалык мәсьәләсе буенча җитди бәхәсләр бара. Әдәбият теориясе буенча яңа хезмәтләр, тикшеренүләр дөнья күрү тәнкыйть теориясе белән дә кызыксынуга китерә (Ф.Миңнуллин "Ярату",1983; Чылбырның өч буыны",1983) Бу уңайдан Ә.Еники тәнкыйтенә игътибар итик." Безнең әдәбият замандашыбызның күңел дөньясын бөтен тирәнлеге һәм катлаулылыгы белән ачуга ирешә алганы юк әле", - ди ул һәм XX гасырныд 70-80 елларында урта кулһәм зәгыйфь әсәрләрнең күбәеп китү сәбәбен болай аңлата: "Минемчә, тәнкыйтьчеләрнең һәм бигрәк тә язучыларның үзләренә таләпчәнлекләре кимеп баруында булса кирәк... Әсәрне язу бар, ясау бар. Менә без барыбыз да ясарга шактый остардык. Шуның аркасында шома эшләнгән әсәрдән талантлы язылган әсәрне аера алмый башладык" (Еники Ә.,1983). Икенче бер сәбәп итеп әдип табигый дөреслектән читләшүне, тартып-сузып китерелгән ясалма "дөреслек"кә йөз тотуны атый. Тел сафлыгы, чисталыгы сагында торган язучы әдәбиятта әлеге дә баягы шомартуның шактый урын алуына безнең игътибарыбызны юнәлтә һәм тәнкыйтьнең вазифаларын искә төшерә. Ә.Еники тәнкыйтьнең бурычын әдәбият белән бергә бер-берсенә уйланырга азык биреп, бер-берсен куәтләп яшәүдә күрә.Үз вакытында әйтелгән дөрес бәя язучы өчен бик мөһим. Тәнкыйтьнең көче – намуслы һәм гадел булуда, дип саный ул. Тәнкыйтьнең көче – намуслы һәм гадел булуда(еники Ә.,1980).

Әмма тәнкыйтьтә көтелгән җанлану күренми. Газета-журнал битләрендә барган фикер алышулар шактый вак, бертөрле, хәтта билгеле мәсьәләләргә кайтып кала. Тәнкыйтьжанрлары арасында мактау

рецензияләре өстенлек итә. Тәнкыйть объекты шактый ачык күренеп торган ике төркемгә бүленә: берсе – официаль төстә “яхшылар арасына кертелгән “әдәбият генераллары” булып, алар әдәби процессны алып баручы, аның төп идея-эчтәлеген, пафосын билгеләүчеләр буларак бәяләнә; икенчеләре – әдәбиятта “фон тудыручылар” рәвешен алып, еш кына иҗатлары күрмәмешкә салынган, читләтеп үтелгән, хәтта табышлары “беренчеләргә” күчереп куелган “эш атлары”. Мондый күренеш бөтен ил күләмендә күзәтелә. Аның бер чагылышы булып Л.И.Брежневның билгеле трилогиясенә бирелгән бәя тора. Тагын шуны билгеләп үтәргә кирәк: хәзерге тәнкыйтьтә дә йогынтысы ачык сизелгән, ә башлангычы 1960-1980 елларга кайтып калган “син мине макта, мин сине мактыйм” яисә дәрәҗәле урында эшләгән (рәислек, депутатлык, чиновниклык һ.б. шундый вазифа үтәү) язучыга яраклашырга тырышу күренеше киң колач җәя.

Совет чорында татар әдәби тәнкыйтенең каршылыклы, еш кына чикләнгән, билгеле бер кысаларда яшәргә мәҗбүрбулуын билгеләп, Н Фәттах болай ди: “Татар тәнкыйте, минемчә, беркайчан тулы мәгънәсендә ирекле һәм бәйсез була алмады. Ул, бер яктан,хаким идеологиягә һәм эш башында торган түрәләргә, икенче яктан әдәбиятны үз кулында тоткан аерым шәхесләргә һәм аерым төркемнәргә ялчы хезмәтен башкарды. Тәнкыйтьчеләр бары үз хуҗаларының гына исемнәрен мактау белән телгә алып, башкаларның исемнәрен дә, әсәрләрен дә телгә алмыйча, тәнкыйть мәкаләләре язарга өйрәнеп киттеләр. Шул рәвешчә, татар әдәбиятында исемнәрен, әсәрләрен курыкмыйча әйтеп була торган даһилар һәм читкә тибәрелгән, тәнкыйть тарафыннан танылмаган исемсезләр, хокуксызлар барлыкка килде” (Фәттах Н. 1989). Мәкалә авторының карашларында субъектив мөнәсәбәт билгеле бер дәрәҗәдә чагылса да, дөреслек бөтенләй юк түгел.

1960-1980 елларда татар әдәби тәнкыйте туплаган тәҗрибә татар сүз сәнгатенең җитди сәхифәләрен, үсеш тенденцияләрен ачуга ярдәм итү белән

бергә, буыннардан буыннарга күчүче традиция рәвешендә хәзерге тәнкыйть өчен дә бай чыганак һәм җирлек булып тора.

Вопросы и задания для самопроверки и контроля (Үзконтроль өчен сораулар һәм биремнәр):

1. “Җепшеклек” чорына бәя бирегез.
2. 1950 елларның икенче яртысы – 1960 еллар татар әдәби тәнкыйтендә нинди традицияләр яңадан торгызыла.
3. 1960 еллар әдәбият белеменә һәм тәнкыйтенә нинди яшь көчләр килә.
4. Герой-шагыйрь Муса Җәлил шәхесе һәм иҗаты” дигән темага әдәби тәнкыйть үсеше ноктасыннан эссе языгыз.
5. 1970 еллар журнал тәнкыйтендә куелган әдәби проблемалар дигән темага түгәрәк өстәл оештырыгыз.
6. И.Нуруллин әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә нинди тәнкыйть жанрлары күзәтелә.
7. Уңай герой һәм заман герое хакында фикер көрәшен бәяләгез.

ТЕМА 7 Профессиональ һәм язучылар тәнкыйте (Ф.Миңнуллин һәм М.Мәһдиевләр тәнкыйте мисалында)

Аннотация.

1960-1980 еллар татар әдби тәнкыйтендә профессиональ, язучылар, укучылар тәнкыйтенең роле, аларның сыйфади характеристикалары турында гыйльми мәгълүмат бирелә.Язучылар тәнкыйтенең татар әдәби тәнкыйтендә әйдәүче урында торуы, шул ук вакытта бу иҗат төрендә Ф.Миңнуллин, И.Нуруллин. Р.Мостафин, Ф.Мусин мисалларында профессиональ тәнкыйтьнең дә хәлиткеч роль уйнавы бәян ителә.

Ключевые слова (төп төшенчәләр): әдәби тәнкыйть, профессиональ, академизм, анализ, фәнни тирәнлек, язучылар, субъективлык, шәхси башлангыч, ассоциация, бәйләнеш.

Методические рекомендации по изучению темы (Теманы үзләштерү өчен методик рекомендацияләр):

- 1960-1980 еллар татар әдби тәнкыйтендә профессиональ, язучылар, укучылар тәнкыйтенең роле, аларның сыйфади характеристикалары турында гыйльми мәгълүмат бирелгән лекция тәкъдим ителә.

- Студентларга мөстәкыйль эш сыйфатында бирелгән темалар буенча презентацияләр үткәрү өчен материаллар тупларга, иҗади һәм контроль эшләр эшләргә, түгәрәк өстәлгә материал сайларга һәм төрле актуаль темаларга чыгышлар ясарга әзерләнергә тәкъдим ителә,

- Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максаты белән һәр темага сораулар һәм биремнәр бирелә.

Источники информации (Информация чыганаклары):

1. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.
2. Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). – Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.
3. История русской литературной критики: Учеб. для вузов / В.В.Прозоров, Е.Г.Елина и др.; Под ред. В.В.Прозорова. – М.: Высш. Шк., 2002. – 463 с.

Интернет-ресурсы (Интернет-ресурслар):

1. dic.academic.ru/dic.nsf/bse/104011/**Литературная**
2. bse.sci-lib.com/article070749.html
3. http:// kitap.net.ru
4. kitapxane.at.tt
5. tatar.org.ru и др.

Глоссарий (Сүзлекчә):

Әдәби репутация – (латинча reputatio – уйлану, фикер йөртү мәгънәсендә) әдәби иҗатта язучы тарафыннан ирешелгән иҗтимагый бәя,

аның шәхесе, иҗатының сыйфатлары, уңай һәм кимчелекле яклары турында туган гомуми күзаллау һәм мөнәсәбәт.

Профессиональ тәнкыйть – әдәби тәнкыйть өлкәсендә максатчан шөгыльләнүче эшчәнлеген белдереп, әдәби әсәрне төзелеш-структурасына, эчке закончалыкларына таянып анализлаган һәм шул нигездә тормышның сүз сәнгатенә бәйле рухи ихтыяҗларын, мәдәни сыйфат-билгеләрен ачкан академик характердагы тәнкыйть.

Язучылар тәнкыйте – төп иҗади эшчәнлекләре әдәби әсәрләр язу белән бәйле булып, субъективлык, шәхси башлангыч, көтелмәгән ассоциацияләр, бәйләнешләр, нәтиҗәләр киң урын алган, үзгә зәвыкка нигезләнгән, төр һәм жанр ягыннан чуар булган тәнкыйть.

Вопросы для изучения (Өйрәнү өчен сораулар):

1. Тоталитаризмнан соңгы дәвердә татар әдәби тәнкыйтенең торышы. Әдәби тәнкыйть төрләре.
2. Профессиональ тәнкыйть вәкиле Ф.Миңнуллин эшчәнлеге.
3. Тәнкыйтьче хезмәтләрендә кузгатылган проблемалар.
4. М.Мәһдиев әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә язучылар тәнкыйте үзенчәлекләре.
5. М.Мәһдиевнең гыйльми эшчәнлеге. Аның татар әдәбияты тарихын үстерүгә керткән өлеше.

Лекция №7. **Профессиональ һәм язучылар тәнкыйте (Ф.Миңнуллин һәм М.Мәһдиевләр әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге мисалында).**

Профессиональ тәнкыйть үрнәге буларак Ф.Миңнуллин әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге.

Тәнкыйтьче, язучы, журналист, публицист, тәрҗемәче Фәрваз Мөхәммәдулла улы Миңнуллин 1934 елда Арча районы Ишнарат авылында туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1950-1954 елларда Арча педучилищесында, 1954-1959 еллар аралыгында Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. “Совет

әдәбияты”(“Казан утлары”) журналы редакциясендә бүлек мөдире булып эшли башлый, 1961 елда аспирантурага укырга керә. 1965 елда “Казан утлары”нда кабат тәнкыйть бүлеге мөдире булып эшли башлый.

1977-1984 елларда Ф.Миңнуллин Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре, рәис урынбасары вазифаларын башкара. 1984-1994 елларда Татарстан китап нәшриятында – матур әдәбиятредакциясе мөдире, соңыннан нәшриятның баш мөхәррире вазифаларын башкара.

Ф.Миңнуллин әдәби тәнкыйтькә алтмышынчы елларда килеп, тәүге язмалары белән үзен талантлы, күзаллау офыгы киң, үзфикерле тәнкыйтьче итеп таныта. Аның тәнкыйди мирасында күзәтүчәнлек, тирән анализ соралган проблемалы очерк, әдәби портрет, аналитик күзәтү, эссе кебек жанрлар актив.

Ф.Миңнуллин гомуми белем мәктәпләре өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр төзү һәм тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнә. Аның тарафыннан Г.Уэллсның “Күренмәс кеше” (1979), Дж. Лондонның “Мартин Иден” (1982) әсәрләре һ.б.татарчалаштырыла.

Тәнкыйтьче буларак аны татар прозасы аеруча кызыксындыра. Г.Бәширов, И.Гази, Ф.Хөсни, Ә.Еники, Р.Төхфәтуллин, Н.Фәттах, А.Гыйлаҗев, М.Мәһдиев, М.Юныс кебек язучылар аның иҗат кредосын билгели. Ул – “Якты юллар” (1975), “Прозаның гражданлык йөзе” (1983), “Талантлар юлы” (1984), “Затлылык” (1990), “Балта явызлар кулында” (1994) кебек хезмәтләр авторы.

Ф.Миңнуллин әдәбти тәнкыйть өлкәсенә караган барлык төр, шул исәптән теоретик мәсьәләләрне дә күтәрә, әмма алар хакында күпчелекккә ерак академик стильдә язмый, теләсә кайсы социаль туркем вәкиле аңларлык, кызыксынырлык рәвештә иҗат итә.

“Балта явызлар кулында” китабының “Тардицияләр яктылыгында” дип аталган тәүге өлешендә торгынлык елларында матбугат битләрендә күтәрелгән төрле яссылыктагы әдәби-тәнкыйди бәхәсләрнең кайтавазы рәвешендә кабул ителә. Автор “Үр артында үрләр бар” исемле язмасында

матур әдәбиятның максат-бурычлары, әдипнең миссиясе, танылу сәбәпләре, миллилелеге, калку геройлар кебек проблемаларга кагылыа уза. Шушы хезмәттә әдәби тәнкыйтьнең предметы, тәнкыйтьченең әдәбият алдындагы вазифалары, тормыш һәм сәнгать арасындагы өзлексез бәйләнеш турында фикерләр бар.

“Әдәбиятның заманчалыгы” мәкаләсенең темасы атамага ук чыгарылган. Ф.Миңнуллин анда 1979 елда “Социалистик Татарстан” газетасы битләрендәге кузгатылган айлык бәхәскә нәтиҗә ясый. Әйтик, И.Нуруллин заманчалыкны “ бүгнеге тормыш материалында бүгенге көн рпоблемаларын бүгенге көн югарылыгында сәнгатьчә хәл тиү” дип санаса, икенче төркем галимнәр төшенчәне заман темасы белән генә бәйләмиләр, “әсәрнең бүгенге көн өчен дә актуаль яңгыравы” дип карыйлар. Автор мондый караштa тора: “Заманчалыкны әдәбиятның тышкы сыйфатлары түгел, эчке сыйфатлары – әдәби әсәрнең рухы, пафосы билгели”. Заман герое һәм уңай герой төшенчәләрен аңлаудагы төрлелеккә, аларны уңышлы яисә уңышсыз, урынсыз, бутап укллану очракларына, теориядә эчтәлеге төгәл, ачык терминнарның гамәлдә дөрес кулланылмавына игътибар итә. “Заман героен уңай герой белән тәңгәлләштереп карау, әдәби әсәрнең үзенчәлеген, аның эстетик хасиятен төшенмәү язучының хезмәтен гадиләштереп аңлауга, берьяклы бәяләүгә китерә”, - дип яза.

Заман героена бәйле рәвештә, ул әдәбиятка хас гасыр ахыры үзгәрешләре турында сүз йөртә, прозаның күпланлы образларга йөз тотуын, әдәби әсәрләрдә елдан-ел автор образының мөһимләшә баруын әйтә, характер логикасы ачык булмаган геройлар белән мавыгу күренешенә тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Әнә шул рәвешле, “әдәбият белеменең иң аз өйрәнелгән өлкәсенә” – “әдәби геройлар логикасына” килеп чыга.

Әнкыйтьченең тип һәм характерларга һәм аларны тудыру күренешенә бәйле кызыклы күзәтләре бар. Беренчедән, аның хаклы карашынча, социаль тип әдәби образның эчтәлеген ачып бетерә алмый, аны гариплләндерә, ярлыландыра. Типик образ белән социаль типны бер үк төрле аңласак, типик

образда кешенең индивидуаль сыйфатлары исәпкә алынмый булып чыга. Геройлар саның әдәби берәмлекнең тема һәм проблемасы билгели, ди тәнкыйтьче, әгәр әсәр берничә вариантта язылса, геройлар саны һаман кими – типиклаша бара, теге яки бу герой башкакларның сыйфатларын “үзләштерә” икән. Язучы Г.Бәшировның “Сиваш”, Ф.Хөснинең “Авыл өстендә йолдызлар”, Ә.Еникинең “Рәшә” әсәрләре һәм башка мисаллар ярдәмендә,типиклаштырылган геройларда индивидуальлек кими дигән фикерә килә.

Галим карашынча, герой һәм тирәлек мөнәсәбәте – әдәби геройлар диалектикасына карый торган катлаулы мәсьәләләрдән. Ф.Миңнуллин бу очракта И.Нуруллинннның әлеге мөнәсәбәтнең тәнкыйди реализмда ук хәл ителгән дигән фикеренә каршы чыга. Бигрәк тә 1920-1930 еллар прозасында ти пдәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән һәм бер үк вакытта ышандырырлык та образлар юклыгын әйтә, Гомәр Толымбай, Хатип Госман кебек язучылар иҗатыннан герой һәм ул сурәтләнгән җирлекнең бер-берсенә лаек булмаган очракларына мисаллар китерә. Андый мисалларны соңгырак чор прозасыннан да таба. Ф.Миңнуллин һәрвакыт бер нәрсәне ассызыклый: тирәлек һәм герой арасындагы мөнәсәбәтләрне дөрес чишү – автор осталыгына, һәм бигрәк тә тасвирлаган чорын аңлау дәрәҗәсенә бәйле.

Ф.Миңнуллин нәрсә хакында гына язмасын – актуальлеге бүгенгәчә кимемәгән, кайчандыр аның тарафыннан кабыргасы белән куелган проблемалар фәнни планда ахыргача хәл ителмәгән булып чыга.Ул киңкарашлы тәнкыйтьче сыйфатында фикер йөртә: типик шартларның әдәби әсәрнең идея-проблема аныклыгын, үзәк геройларның чынлык дәрәҗәсен, тормышчанлыгын билгеләвен күрсәтә. Бик күп галимнәрдән аермалы буларак, Ф.Миңнуллин “геройның дөньяга карашын авторга көчләп тагу”га каршы чыга. Бигрәк тә үзәк герой тискәре образ булганда, бу хәл кеше ышанмастай күренешкә китерә, аның фикере авторныкы дип табылып, әсәр иясенә ялгыш карашлары өчен тәнкыйть уты яудырыла башлый.

Ф.Миңнуллин, үзәк герой уңай образ булганда, эш әллә ни кыен түгел дисә дә, бу очракта да шушы ук хәл күзәтелә. Мәсәлән, торгынлык елларының күпме әсәрендә идеология кысаларына утыртылган уңай әдәби образ белән автор күрергә теләгәне арасында аерма зур иде..Хәтта бүген дә, норматив әдәбият үрнәге буларак иҗат ителмәгән прозада да, автор уңай героен публика ихтыяҗын, тормыш чынлыгын күздә тотып һәм шул ук вакытта шәхси идеалларына туры китермичә иҗат итә ала.

Ф.Миңнуллин Г.Минскийның “Язның беренче көне”, Х.Миндубаевның “Фәридә” исемле әсәрләрендә дәүләт хисабына укыгын яшь белгечнең билгеләнгән эш урынына китеп баруында батырлык күрмәвен, М.ШӘрифуллинның хосусый милекчелек тәнкыйть ителгән “Еллар үткәч” повестенда табигыйлек һәм эзлеклелек юклыгын, характер логикасы бозылуын әйтә.

Кыскасы, Ф.Миңнуллин тәнкыйте укучыны да, әдипне дә һәм хәтта галимне дә үзләре укыгын әдәбиятка караганда да ныграк уйлатырга һәм ахыр чиктә – тәрбияләргә, рухи үстерергә, күзаллау офыкларын киңәйтергә, тормышны аңлавын тирәнәйтергә сәләтле.

Ф.Миңнуллин тәнкыйте һәрвакыт – тәнкыйди рухта гына. “Чылбырның өч буыны” язмасында фәннең һәм бигрәк тә тәнкыйтьнең хәрәкәттәге эстетика булудан ераклыгын күрсәтә: аңа бүгенге әдәби барышны бәяләү җитми, аның ерактан килгән тарихы да җитәрлек тикшерелмәгән, теге яки бу жанр формаларының туу һәм үсеш тарихы да төпле чагылдырылмаган. Торгынлык еллары тәнкыйтендә санап чыгу өстенлек итүен билгели, аның язучы репутациясен эшләү белән шөгыльләнүен күрсәтә. Бүгенге тәнкыйть исә официоз һәм комплиментар, баналь тәнкыйть.

Ф.Миңнуллин әдәби тәнкыйть үсешен теория үсеше белән турыдан-туры бәйләп карый, терминнарның мәгънәсен аңламыйча механик куллану, әдәби образны тар аңлау һәм аны иҗат итүне схематик күзаллау кебек күренешләрне тәнкыйтьли, әдәбият белемендә якын киләчәктә хәл ителергә

кирәкле проблемаларны барлап чыга..Болар арсында әлегечә аталмаган киңтармаклы әдәби багланышлар проблемасы да бар.

Ф.Миңнуллинны, һич шикләнмичә, 1970-1980 еллар аналитик тәнкыйтенең иң көчле вәкиле дип бәяләргә мөмкин.

Язучылар тәнкыйте үрнәге буларак М.Мәһдиевнең әдәби тәнкыйди эшчәнлеге.

Татарстанның халык язучысы, республиканың Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты М.Мәһдиев үз чорының әдәби процессы үзәгендә кайнап яши. Университетның татар әдәбияты кафедрасы доценты, танылган әдип даими рәвештә китап укучылар, киң җәмәгатьчелек белән очраша, республиканың татар телле матбугатында әдәбият-сәнгатькә, иҗтимагый фикер үсешенә, гомумән, татар дөньясына караган төрле мәкаләләр белән чыгыш ясый. Күптөрле эшчәнлек алып барган язучы әдәби тәнкыйть мәсьәләләре белән дә кызыксынып яши. М.Мәһдиевне тәнкыйтьче буларак өйрәнгәндә, аның фәнни хезмәтләре, әдәбият тарихына караган язмалары, күпсанлы интервью-әңгәмәләре, замандашлары иҗатына бәяләмәләре күздә тотыла.

М.Мәһдиевнең әдәби тәнкыйть белән кызыксынып яшәвенә остазы Х.Госман тәкъдиме белән XX гасыр башы әдәби тәнкыйтен фәнни планда тикшерүгә алынуы һәм 1964 елда уңышлы рәвештә кандидатлык диссертациясе яклавы да сәбәп булып тора. Галимнең “Әдәбият һәм чынбарлык (XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар)” (1987), “Реализмга таба” (1989), “Социальные корни таланта” (1990) хезмәтләрендә XX йөз башы татар вакытлы матбугатында әдәбият мәсьәләләре, әлеге чор әдипләренең иҗтимагый эшчәнлеге, әдәбиятта һәм публицистикада алга чыккан тема һәм мотивлар, аларның тарихи һәм социаль-иҗтимагый җирлеге һ.б. җитди проблемалар тикшерелә. Реалистик тәнкыйть тарафдары буларак чыгыш ясап, шәхси мөнәсәбәт-бәясен, нигездә, авторның дөреслеккә тугры калуына, тормышчанлыгына, ышандыру көченә нисбәтле билгели.

М.Мәһдиевның Таип Яхин, Габделмәннан Рахманколый, бертуган Гобәйдулла һәм Габдулла Бубилар кебек XIX ахыры һәм XX йөз башы татар мәгърифәтче педагоглары, Г.Сәгъди, Г.Рәхим, Г.Нигъмәти, Ф.Сәйфи-Казанлы кебек әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләре турында бай архив материалларына нигезләп язылган мәкаләләре, иҗат портретлары, фольклор һәм әдәбият фәненең аерым проблемаларын тикшергән фәнни-тәнкыйди хезмәтләре зур әһәмияткә ия. Галимнең шулай ук Н.Думави, С.Рахманколый, Г.Рәхим, Ф.Әмирхан, М.Гафури һ.б. иҗат эшчәнлегенә караган фәнни хезмәтләре бар. Автор тарафыннан әдипләрнең татар әдәбиятына, мәдәниятенә керткән өлешләре киң һәм нигезле яктыртыла.

М.Мәһдиевнең тәнкыйтьче буларак караш-фикерләре, сүз сәнгатенә мөнәсәбәте үз чоры әдәби процессына нисбәтле дөнья күргән мәкалә-язмаларында аеруча тулы чагылыш таба. Әмма шунысы игътибарга лаек: аларда публицистик эчтәлек өстенлек итә, өйрәнү объектына, исемгә чыгарылган темага автор киң планда якын килә һәм әдәби-мәдәни, милли, социаль-иҗтимагый мәсьәләләр белән бәйләнештә тикшерә.

Танылган язучы әдәби тәнкыйтьнең урыны, әһәмияте турында шактый киң уйлана. Ул аңа зур таләпләр куя: “Тәнкыйтьче икәнсең, ничек язылганын гына түгел, ничек язылырга тиеш икәнлеген дә күрсәт”. Фикерен болай дәвам итә: “Үзенә генә хас уңышлары, үз манерасы, үз кимчелекләре белән әдәбиятка килеп кергән яңа автор кайвакытта ни өчендер берәүләрне сагайта. Һәм талантлы күренгән бу яңа иптәшкә ярдәм итәсе урында аның иҗатыннан тырышып-тырышып кимчелек эзлиләр. Ничек язасы? Моны әйтмиләр...” [Мәһдиев. Язучының иҗат активлыгы. 1974. 23 май]. Үз чоры тәнкыйтенең исә күбрәк мактау белән шөгыльләнүен искәртә. Дөрес, әсәр яисә автор иҗатының уңышлы якларын ачуны һич тә кире какмый, әмма анализның авторга хас сәнгати эзләнүләрне, әсәренең әдәби процесстагы урынын билгеләү белән үрелеп барырга тиешлеген ассызыклый. Чордашлары арасында әнә шундый тәнкыйтьче дип Ф.Миңнуллинны атый һәм “Замандашыма мәдхия” мәкаләсендә болай дип яза: “Совет чорындагы татар

әдәбиятын, бигрәк тә 1930-70 еллардагы татар әдәбиятын Фәрваз Миңнуллин кадәр тирән аңлаган, анализлый алган тагын ничә генә тәнкыйтьче бар икән" [Мәһдиевю. Замандашыма мәдхия (Ф.Миңнуллинга 60 яшь). 1994. 135].

Әдәбият-сәнгатькә караган мәкалә-язмаларында матур әдәбиятның эчтәлеге, бурыч-вазифалары, язучы шәхесе һ.б. турында уйлана. М.Мәһдиев язучы булу, әдәби иҗат белән шөгыльләнүне гаять мөһим бурыч-вазифа дип саный. Замандашы Г.Кашапов иҗатына бәясендә әдипкә хас аеруча мөһим сыйфат буларак тормышны, сурәтләү объектын өйрәнеп, белеп язуны һәм хакыйкатькә тугры калуны искәртә [Мәһдиев. Г.Кашапов әсәрләре турында. 1989. 271-272].

Тәнкыйтьче хезмәтләрендә әдипнең иҗатка килүе, әсәрнең язылу тарихы, тормышчанлыгы, язучының иҗат иреге, гомумән иҗат психологиясе мәсьәләләре турында уйланып, ул шактый үзенчәлекле, билгеле бер дәрәҗәдә субъектив фикерне яклый: "Язучының "чишмә башы" – фаҗигадә. Драма, тормыш драмасында. Шәхси тормышында фаҗига, хәсрәт, борчу кичермәгән кешедән язучы чыга алмый" [Мәһдиев. Әйдә, халыкка хезмәткә! (Язучы М.Мәһдиев белән Р.Низамиев әңгәмәсе). 1991. 157].

1990 елда газета битләрендә барган "Нәрсә ул партияле әдәбият һәм иҗат иреге?" дигән дискуссиягә катнаша һәм "Кыршауланган әдәбият" дигән мәкаләсендә сүз сәнгатенең ниндидер партия мәнфәгатьләренә хезмәт итүен, димәк, социалистик реализмның нигез принципларының берсен кискен кире кага. "Партия мәнфәгатьләренә бәйле әдәбият вакытлар үтү белән юкка чыга, алай гына да түгел, кайвакытта җәмгыять өчен зарарлы күренешкә дә әйләнә башлый" [Мәһдиев. Кыршауланган әдәбият. 1990. 1 апрель], - дип яза ул әлеге фикерен мисалларда дәлилләп. Иҗат иреге булмауның үлемгә тиң күренеш икәнен искәртеп, С.Есенин, В.Маяковский, Һ.Такташ язмышларын, аларның вакытсыз үлү сәбәпләрен искә төшерә

Язучыга куелган бурычлар арасында М.Мәһдиев тормышны өйрәнүне, белемле булуны саный. Ул әдәбиятның торышы мәсьәләсенә тукталып, 1974 елда "Прозабызның әле киң колач алып заманча үсеп китә алганы юк"

[Мәһдиев. Язучының иҗат активлыгы. 1974. 23 май] дисә, 1991 елны “Мин проза жанрында эшлим, ләкин күрмим түгел: прозабыз авырый. Укыр нәрсә бик санаулы” [Мәһдиев, 1991; 165], - ди. Моның сәбәпләре турында уйланулары татар әдәбиятының дөнья мәйданына чыга алмавы турындагы фикерләргә барып тоташа. “Бездә “школа” юк, - дип саный ул.- Безнең шәһәрдә милли рух юк. Казан татары ул – синтетик татар. (...). Бу атмосферада милләтнең зур язучысы туа алмый. Татар баласы вак тормыш эчендә гомерен уздыра” [Мәдиев, 1991; 166-167].

М.Мәһдиев әсәрләргә куелган таләпләр арасында телгә, әдәби сүзгә игътибарлы булуны аерып күрсәтә. “Әдәби сүз игътибар сорый” дигән язмасында Г.Тукай, М.Гафури шигырьләрен һаман хата белән бастырып чыгаруны, укуыбызны билгели.

Язучының иҗат лабораториясе, автор-әсәр-укучы мөнәсәбәте мәсьәләләре турында уйланулары бигрәк тә “Ни хәлең бар, Фатыйма?” исемле мәкаләсендә тулы чагылыш таба. Укучылардан килгән хатларга җавап рәвешендә дөнья күргән әлеге язма үз вакытында зур кызыксыну уята, киң яңгыраш таба. Ул эзлекле рәвештә әдәби әсәрнең бервакытта да теге яки бу тема белән генә чикләнмәвен, бәлки авторның киң планда Кеше турында тирән уйлануларын укучыга тәкъдим итүен билгели: “Минем бары тик үземне борчыган, дулкынландырган мәсьәләләр, үзем сокланган – инде башымда туган тема – кешеләр турында язасым килгән иде”. [Ни хәлең бар, Фатыйма? (“Фронтовиклар” романы турында укытучылардан килгән хатларга җавап) Мәдиев. 1973. 45]. Башка хезмәтләрендә урын алган, үзе өчен мөһим санаган принципны – вакыйга-күренешләрне, әдәби образларның тормышчанлыгын – тагын бер кат аерып чыгара.

Шулай итеп, чорыбызның танылган әдибе М.Мәһдиевнең әдәби-тәнкыйть турындагы хезмәтләре кыйммәтле мирас булып тора.

Вопросы и задания для самопроверки и контроля (Үзконтроль өчен сораулар һәм биремнәр):

1. Ф.Миңнуллинның тәнкыйди эшчәнлеге кайсы төргә карый?

2. Ф.Миңуллин тәнкыйтендә кайсы жанрлар актив кулланыла?

3. Автор заман герое һәм уңай герой мәсьәләсенә нинди караштa тора?

4. Ф.Миңнуллин әсәрнең уңае герой һәм автор позициясе мөнәсәбәтен ничек билгели?

5. М.Мәһдиев тәнкыйди эшчәнлегенә нигезләнеп язучылар тәнкыйтенең төп үзенчәлекләрен билгеләгез.

6. Мәһдиев әдәби әйләнешкә керткән шәхесләрне санагыз.

ТЕМА 8 Хәзерге чор татар әдәби тәнкыйте (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы).

Аннотация.

XX-XXI чикләрендә әдәби тәнкыйтьнең торышы, анда күзәтелгән тенденцияләр, күчеш чоры тәнкыйте, тәнкыйтьтә кризис, кризистан чыгу юллары тикшерелә. Чор тәнкыйтендә күзәтелгән яңа тенденцияләр, актив тәнкыйтьчеләр эшчәнлегенең төп хасиятләре турында гыйльми күзаллау булдырыла.

Ключевые слова (төп төшенчәләр): үзгәртеп кору, рухи яңарыш, күчеш чоры, тәнкыйть кризисы, традиционлык.

Методические рекомендации по изучению темы (Теманы үзләштерү өчен методик рекомендацияләр):

- XX-XXI чикләрендә әдәби тәнкыйтьнең торышы, анда күзәтелгән тенденцияләр, бер төркем тәнкыйтьчеләрнең эшчәнлеге хакында гыйльми күзаллау бирелгән лекция материалы урнаштырылган;

- Студентларга мөстәкыйль эш сыйфатында бирелгән темалар буенча презентацияләр үткәрү өчен материаллар тупларга, иҗади һәм контроль эшләр эшләргә, түгәрәк өстәлгә материал сайларга һәм төрле актуаль темаларга чыгышлар ясарга әзерләнергә тәкъдим ителә,

- Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максаты белән һәр темага сораулар һәм биремнәр бирелә.

Источники информации (Информация чыганаклары):

1. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.

2. Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). – Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.

3. История русской литературной критики: Учеб. для вузов / В.В.Прозоров, Е.Г.Елина и др.; Под ред. В.В.Прозорова. – М.: Высш. Шк., 2002. – 463 с.

4.

Интернет-ресурсы (Интернет-ресурслар):

6. dic.academic.ru/dic.nsf/bse/104011/**Литературная**

7. bse.sci-lib.com/article070749.html

8. http:// kitap.net.ru

9. kitapxane.at.tt

10. tatar.org.ru и др.

Глоссарий (Сүзлекчә):

Импрессионистик тәнкыйть – гыйльми юнәлеш-агымга яисә фәнни концепциягә таянмыйча, әдәби әсәр турында укучы күңелендә ихлас туган беренчел эмоциональ хис-кичерешләр, тойгылар алгы планга чыгарылган тәнкыйть.

Символик тәнкыйть – язучының әсәрдә метафорик, символик фикерләү үзенчәлеген, ассоциатив логикага корылган образлылыкны, символга салынган мәгънәви тәрәнлекне ачуга юнәлтелгән тәнкыйть.

Мифологик тәнкыйть – кешелек җәмгыятенең беренче иҗат җимеше булган миф турындагы өйрәтүләргә нигезләнеп, анализ барышында әсәрдә урын алган мифның асылы, төзелеше . эчтәлеге ачылган һәм мифның автор концепциясен аңлаудагы урыны билгеләнгән тәнкыйть.

Филологик тәнкыйть – әдәби әсәрне тел-стиль үзенчәлекләре ягыннан тикшереп бәяләүне күздә тотып, өйрәнү объектының идея-проблематика ягын, киң планда бөтенлекле анализны читтә калдырып, алгы планга грамматика һәм сурәт чаралары, тел билгеләре кебек мәсьәләләне чыгарган тәнкыйть.

Публицистик тәнкыйть – әдәби әсәрне җәмгыятькә, андагы процессларга бәйле тикшереп, яшәешкә социологик характеристика мөһим урын алып торган һәм ул язма структурасының башка элементлары белән тыгыз үрелеп, укучыга юнәлтелгән тәнкыйть.

Фәлсәфи тәнкыйть – матур әдәбиятны үткән һәм киләчәк, язмыш һәм хакыйкать, фаҗига һәм өмет һ.б. фәлсәфи категорияләргә бәйле тикшереп, анда яшәешнең, чынбарлыкның олы мәгънәсен эзләп табуга юнәлтелгән тәнкыйть

Вопросы для изучения (Өйрәнү өчен сораулар):

1. 1980 елларның икенче яртысында демократик үзгәрешләр: Советлар берлеге таркалу, Коммунистлар париясенең хакимияте җимерелү, ил тормышында кискен икътисадый-рухи үзгәрешләр. Әдәбият-сәнгать дөньясындагы яңалыклар.
2. Әдәбият белеме, шул исәптән татар әдәби тәнкыйтенең торышы: “күчеш чоры” тәнкыйте, әдәби тәнкыйть кризисы.
3. Матбугат битләрендә әдәби тәнкыйтьнең бүгенге хәле һәм аның киләчәк перспективасы хакында сөйләшү.
4. Әдәби тәнкыйтьне җанландыру һәм аны үстерү юллары турында тәнкыйтьчеләр.
5. XX-XXI гасыр чикләре татар әдәби тәнкыйтендә күзәтелгән яңа сыйфатлар.
6. XX-XXI гасыр чикләрендә Тукай турындагы гыйльмиятнең торышы: үсеш перспективалары.

Лекция №8. **Хәзерге чор татар әдәби тәнкыйте (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы).**

Хәзерге әдәби тәнкыйть тәнкыйть тарихының эзлекле дәвамы буларак, үсеш-үзгәрешенең мөһим бер чоры дип карала. Аның хронологик чикләре 1980 елларның икенче яртысы XXI гасыр башына туры килә. Хәзерге тәнкыйтьнең ике баскычы: 1) 1980 еллар уртасы – 1990 еллар башы һәм 2) XXI гасыр башы аерып чыгарыла.

XX гасырның соңгы унъеллыгы, кискен иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни-рухи үзгәрешләргә нисбәтле, гыйльми-тәнкыйди һәм әдәби фикердә яңарыш хәрәкәте белән характерлана. Әдәби тәнкыйть, догматик, норматив принциплардан, идеологиядән арынып, үз үсешендәге тенденцияләрне, аерым баскычларын яңача бәяләргә тиеш була. Билгеле булганча, әдәби тәнкыйть үсеше чор әдәби барышына бәйле. Беренче баскычта әдәби процесс каршылыклы үсеш юлына керә һәм тиз генә җанланып китә алмый. Татарстан язучыларының 1989 елда үткән корылтаенда Ә.Еники үзенең чыгышында матур әдәбиятта үзгәрешләрнең канәгатьләнерлек булмавын ассызыклый Шушы караш Р.Харис. Ф.Миңнуллиннар тарафыннан да раслана. Т.Галиуллин исә X съездда ясаган чыгышында тәнкыйтьнең үсеш юлында булып, күпсанлы хезмәт-мәкаләләрдә әдәби процесстагы төп тенденцияләрне ачыклау, әдәби күренешләрне чынбарлыкка бәйләп аңлату, жанрлар хәрәкәтен, сурәтлелек чараларының байый, яңара баруы хас дип күрсәтә.

Үзгәртеп корулар башланган чордагы тәнкыйтьнең торышы, андагы кимчелекле һәм уңай яклар Ф.Миңнуллинның 1987 елгы әдәби тәнкыйть торышына күзәтү төсендә язылган мәкаләсендә аеруча тулы чагылыш таба: а) “тәнкыйтьнең адресаты үтә тар, радиусы бик бәләкәй” булу; б) “әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләре арасында әдәбиятның тар бер өлкәсендә “специальләшү”; в) әдәбияттагы кимчелекләрне исемнәре китап сөючеләргә аз таныш булган, яңарак кына каләм тибрәтүгә алынучыларга кайтарып калдыру һ.б.

А.Хәлим, М.Юныс, Р.Свирегин, Г.Ахунов, Ф.Бәйрәмова, А.Гыйлаҗев, С.Хафизов язмаларында тәнкыйтьнең артта калуы, чор, заман таләпләренә җавап бирмәве билгеләнә. Болар барысы да гасыр әдәби процессында бу тармакның бер урында таптана башлавын, аерым мәсьәләләрдә хәтта артка чигенүен күрсәтә. Икенче төрле әйткәндә татар әдәби тәнкыйте “кризис” чорына керә. Моңа китергән шартлар турында сүз алып барганда, күчеш чоры үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк. Тышкы факторлардан тыш эчке шартлар – шәхес аңындагы үзгәрешләр, әдәбият-сәнгать торышы, аның заман таләпләренә, рухи ихтыяҗларга җавап бирүе, традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңалыкларга омтылышы һ.б. Р.Мостафин “Чорлар чатындагы үзгәрешләр” (2004) мәкаләсендә XX гасыр ахыры әдәбиятындагы үзгәрешләрне ачыклый: 1) идеология үзгәрү аркасында күп әдипләрнең аптырап калуы; 2) цензураның юкка чыгуы,гомумән алганда, сүз, матбугат иреге бирелү; 3) җәмгыятьтә дингә карашның уңай якка үзгәрүе; 4) публицистиканың киң урын алуы; 5) классик мирасыбызның әйләнеп кайтуы; 6) үткән тарихыбызга игътибар арту һ.б. Аннан соң әдәби зәвыкка ия булып, югары профессиональ әзерлеле, үз карашларын курыкмыйча әйтә алган И.Нуруллин, Ф.Зөлкәрнай, Ф.Миңнуллиннарның үлеме дә эзсез калмый.

“Күчеш чоры” әдәби тәнкыйтьтә җитди каршылыклар китереп чыгарса да, бер үк вакытта “яңа тәнкыйть” өчен җирлек әзерләнә. Чор-җәмгыять үзгәрешләрен, әдәби процесс үзенчәлекләрен тоемлаган, мөһим нәтиҗәләргә килгән аналитик ямалар күренә,әдәби тәнкыйтьтә эстетик тенденцияләр көчәя башлый. 1988-1989 елда “Казан утлары” журналы тарафыннан үткәрелгән “Заман һәм шагыйрь” дигән фикер алышуда, М.Вәлиев, М.Шабаев, Г.Рәхим, Г.Гыйльманов, Ә.Баянов, М.Гайнетдинов һ.б катнаша. Чор татар шигъриятен, заман үзгәрешләренең чагылышы, гомумән әдәби барыш мәсьәләләре күтәрелә. Т. Галиуллин татар шигъриятенең язмышы турындагы “Шигырь кемгә кирәк” мәкаләсендә әлеге иҗат төренең асылы, аның халык язмышы, мәнфәгате белән аерылгысыз булырга тиешлеге

турында яза.Эчке тартыш, көрәш фонында әдәби тәнкыйтьтә үсеш-үзгәреш күзәтелә.

1980 еллар уртасында башланып киткән үзгәртеп корулар тәэсирендә татар әдәбияты үз үсешендә “яңа дулкын”га керә. Әдәбиятта “ак таплар” бетерелеп, Г.Ибраһимов, Г.Рәхим, Ф.Әмирхан һ.б. аерым әсәрләре, бигрәк тә Гаяз Исхакый мирасы кайтарыла. Нигездә реалистик һәм романтик юнәлешкә йөз тоткан татар сүз сәнгате модернистик агымнарга, алым-чараларга иркен мөрәҗәгать итә башлый. “Яңа” әдәбиятны аңлата, бәяли алырлык, табышларны билгеләрлек, эзләнүләр юнәлешен ачарлык яңа тәнкыйть кирәклеге көн тәртибенә куела. Чөнки киң планда матур әдәбиятта чагылган казанышлар белән тәнкыйди фикер арасында аерма барлыкка килә. Бу чорда әдәби тәнкыйтьнең таянычы булган публицистика көчәя. Хәбәрдарлык, сүз һәм матбугат иреге күпсанлы газета-журналларның нәшер ителүенә китерә: “Ватаным Татарстан”, “Идел”, “Мирас”. “Аргамак”, “Казан” һ.б. Әлеге басмаларда, әдәби тәнкыйтьне җанландыру макстыннан, “Түгәрәк өстәл” сөйләшүләре үткәрелә.

Татар әдәби тәнкыйте XXI гасыр башында, күптөрле тышкы һәм эчке факторларга нисбәтле, яңа чор әдәби процессын, шул исәптән аерым әсәрләрне аңлау-бәяләүнең үлчәмнәрен, фәнни нигезләрен ачкан эстетик концепцияләрне эзләү юлына чыга. XXI гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә әдәби тәнкыйтьнең реалистик (М.Вәли-Барҗылы: “Күңел кемне көтә?”; Р.Фәизов: “Алар безнең арада”) һәм романтик (Н.Гафиятуллина: “Романтик әдәбиятта заман фаҗигасе: Әсгать Сәлах”) төрләре күзәтелә. Шул ук вакытта аерым язмалар да мифологик (Л Дәүләтшина: Киләчәккә күз төбәп”, Д.Заһидуллина. А.Шәмсутова), импрессионистик (Р.Зәйдулла: “ Куркытмагыз кошлар авазын”, Ә Сәлах: “Күкрәүләре һаман яңгырый (шагыйрә С.Сөләймановани искә алганда)”, Р.Шәрәфиев: “Ак казлар чакыруы”), символик (Г.Гыйльманов: “Образ. Символ. Рухи кодлар” тәнкыйтьнең дә кайбер сыйфатлары чагыла. Татар иҗтимагый, фәлсәфи, дини, мифологик, эстетик фикеренә таянган әдәби тәнкыйть формалашу

процессы бара. М.Вәлиев, Р.Кукушкин, Р.Сверигин, Г.Гыйльман, Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов һ.б.ларның хезмәтләрендә модернистик, постмодернистик агымнарның әдәби-тәнкыйди концепциясе калыплаша бара. 1990 нчы елларның башында Тукай феноменын, шагыйрьнең шәхесен, әдәби мирасын аңлауда яңа этап, яңа чор башлана. М.Хәсәнов, Ф.Мусин, Т.Галиуллин, М.Зәкиев, Ә.Сәхаповларның проблемалы, теоретик мәкаләләрендә шагыйрь иҗатын гыйльми күзаллауның методологик принциплары, фәнни концепциясенең билгеләре тәкъдим ителә. Тукай шигъриятенең Ислам мәдәнияте белән бәйләнеше, Коръән китабыннан шагыйрьнең әсәрләренә үтеп кергән гомумкешелек, инсани кыйммәтләр, дини мотивлар Н.Нәккаш-Исмәгыйль, Р.Ганиева, Х.Миңнегулов, Ч.Зарипова һ.б.ларның хезмәтләрендә киң яктыртылды. Г.Тукай үз иҗатында Урта гасыр татар поэзиясе һәм XIX гасыр мәгърифәтчелек әдәбияты, Шәрык классикасының күпгасырлык бай традицияләрен иҗади үстерде. Х.Миңнегулов үз игътибарын Тукай шигъриятенең Урта гасыр татар әдәбияты белән бәйләнеше мәсьәләсенә юнәлдерсә, Р.Ганиева исә шушы ук чор әдәбиятының икенче юнәлеше – суфыйчылык поэзиясе традицияләренең шагыйрь әсәрләрендә гәүдәләнешен, яңача яңгырашын яктыртты. Тукайның шигъри фикерләвендәге шәркый сурәтләр, “аның идея-фәлсәфи конструкциясе, һәм сурәтле-бизәкле гәүдәләнеше” турындагы гыйльми уйланулары белән Н.Хисамов уртаклашты. Ә инде Т.Галиуллин тикшеренүләренең үзәгендә яткан XX йөз шигъриятендә дәвамлылык мәсьәләсе Тукай традицияләренә таянып шәрехләнә.

XX гасыр Тукай фәненең зур казанышы төсендә 1995-1997 нче елларда “Габдулла Тукай” энциклопедик сүзлек-белешмәсен төзү мәсьәләсенең көн тәртибенә куелып, бу эштә беренче адымнар ясалуны күрсәтергә кирәк. Аның башында, кызганычка каршы, вакытсыз гүр иясе булган Н.Юзиев торды. Сүзлек-белешмәне төзүгә әдәбият белән бәйләнешле галимнәр, тәнкыйтьчеләр генә түгел, ә барлык зыялылар катламы тартылды. Тукай иҗаты һәм шәхесенең 1920-1940 нчы елларда татар диаспорасы яшәгән

төбәкләрдә төрле газета-журналларда гәүдәләнеше Тукай фәненең кызыклы катламы булып тора. Мөһаҗәрәттә чыккан вакытлы матбугат битләрендә Тукайга багышланганнарын халкыбызга җиткерүдә Р.Ганиева, З.Рәмиев, А.Кәримова һ.б.лар мәгълүм өлеш кертте. Бу мәсьәлә Х.Миңнегуловның соңгы еллар гыйльми-тәнкыйди эшчәнлегендә зур урынны алып тора.

Вопросы и задания для самопроверки и контроля (Үзконтроль өчен сораулар һәм биремнәр):

1. Күчеш чоры тәнкыйтенең сыйфатларын барлагыз.
2. XX гасыр ахырында күзәтелгән “тәнкыйть кризисы”ның үзенчәлекләрен санагыз.
3. XXI гасыр башы татар әдәби тәнкыйтендә нинда жанрлар өстенлек итә?
4. Хәзерге әдәби барышта тәнкыйтьнең роле дигән темага эссе языгыз.
5. Хәзерге татар әдәби тәнкыйтендә күзәтелгән яңа тенденцияләрне барлагыз.
6. “Интернет-ресурслар шартларында әдәби тәнкыйтьнең киләчәге” дигән темага түгәрәк өстәл оештырыгыз.

Список источников информации

а) основная литература (төп әдәбият):

17. Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика начала XX века / М. Гайнуллин.– Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 433 с.
18. Гыйлаҗев Т. Татар әдәби тәнкыйте тарихы (1900-1925). Методик кулланма. – Казан, 1999. – 42 б.
19. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 254 б.
20. Мухамадиев Р.С. Проблемы формирования татарской литературной критики (1900-1917) / Р.С. Мухаммадиев – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – 143 с.

21. Харрасова Р.Ф. Әдәби тәнкыйть теориясе. Махсус фән программасы / Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт университеты, 2007.- 32 б.

б) дополнительная литература (өстәмә әдәбият):

10. Абдуллин Я. Мәгърифәт нуры ачар (Татар иҗтимагый фикере тарихыннан сәхифәләр) / Я. Абдуллин – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – 196 б.
11. Амирханов Р. Татарская дореволюционная пресса (в контексте “Восток-Запад”) / Р. Амирханов – Казань: Татар. книжное издательство, 2002. – 238 с.
12. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том / Төз.: Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 751 б.
13. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том / Төз.: Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 735 б.
14. Әхмәдуллин А.Г. Офыклар киңәйгәндә. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / А. Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. - 239 б.
15. Әмирханов Р. Иманга тугрылык / Р. Әмирханов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. – 384 б.
16. Гайнетдин М. Гасырлар мирасы / М. Гәйнетдин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – 319 б.
17. Галиева Э.Р. Татар әдәбияты белемендә культура-тарих мәктәбе / Э.Р. Галиева. – Казан: Фән, 2002. – 360 б.
18. Галимуллин Ф.Г. Әле без туганчы (1920-1930 еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш) / Ф.Г. Галимуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – 320 б.
19. Галиуллин Т.Н. Шәхесне гасырлар тудыра. Әдәби тәнкыйть, хикәяләр. / Т.Н. Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр, 2003. – 192 б.
20. Галиуллин Т.Н. Яктылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. -= Казан: татар. кит.нәшр.,2011. – 319 б.
21. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т.Ш. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.
22. Закирҗанов Ә.М. Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ә.М. Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – 175 б.

23. Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – нач. XXI в.). – Казань: Ихлас, 2011. – 320 с.
24. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман / Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары / Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 271 б.
25. Ибрагим.Т.К., Султанов Ф.М., Юзеев А.Н. Татарская религиозно-философская мысль в общемусульманском контексте. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 239 с.
26. История русской литературной критики: Учеб. для вузов / В.В.Прозоров, Е.Г.Елина и др.; Под ред. В.В.Прозорова. – М.: Высш. Шк., 2002. – 463 с.
27. Крупчанов Л.М. История русской литературной критики XIX века, - М.: Высшая школа, 2005. – 383 с.
28. Мәрданов Р. “Шура” журналы (1908-1917): әдәбият мәсьәләләре / Р. Мәрданов. –Казан: Рухият, 2001. – 152 б.
29. Мәһдиев М.С. Реализмга таба. XXйөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре / М.С. Мәһдиев. – Казан: Университет нәшрияты, 1989. – 154 б.
30. Миңнегулов Х.Й. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлекләге иҗаты / Х.Й. Миңнегулов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – 367 б.
31. Миңнуллин Ф.М. Балта явызлар кулында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ф.М. Миңнуллин. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1994. –334 б.
32. Мусин Ф.М. Көмеш көзге: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ф.М. Мусин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – 256 б.
33. Недзвецкий В.А. Русская литературная критика XYIII – XIX веков: курс лекций. – М.: Аспек Пресс, 2008.- 302 с.
34. Очерки истории татарской общественной мысли. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. – 191 с.
35. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 1 том / Урта гасырлар дәвере. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1984.- 566 б.

36. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 2 том / XIX йөз татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1985.- 573 б.
37. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3 том / XX гасыр башы. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1986.- 598 б.
38. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 4 том / Татар совет әдәбияты (1917-1941). – Казан: Татар. кит.нәшр., 1989.- 566 б.
39. Татар әдәбияты тарихы Алты томда. 5 том / Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбиты (1941-1960). - Казан: Татар. кит.нәшр., 1989.- 542 б.
40. Хәсәнов М.Х., Мөхәммәдиев Р.С. Әдәби тәнкыйть һәм эстетик фикер мәсьәләләре / Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3-т. / XX гасыр башы / М.Х. Хәсәнов, Р.С. Мөхәммәдиев. – Казан, 1986. – 490-505 б.
41. Харрасова Р.Ф. Әдәби тәнкыйть теориясе / Махсус курс программасы / Р.Ф. Харрасова. Казан: Казан дәүләт университеты, 2004.- 19 б.
42. Юзеев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII-XIX вв. / А.Н. Юзеев.-Казань: Татар. кн. изд-во, 2001.- 192 с.

Вопросы к зачету

1. Әдәби тәнкыйть фәне. Аның предметы һәм бурычлары (функцияләре), башка фәннәр белән бәйләнеше.
2. Татар әдәби тәнкыйтенең формалашуына нигез булган беренче карашлар һәм хезмәтләр: тәнкыйди фикернең яшәү һәм үсү формалары (Г.Курсави, Х.Фәезханов, Ш.Мәрҗани һ.б.).
3. Әдәби тәнкыйтьнең үзбилгеләнү хокукы өчен көрәше (Г.Тукай, Г.Сәгъди, С.Рәмиев, Н.Гасрый, Җ.Насыйп, М. Укмаси).
4. Әдәби тәнкыйтьнең фән буларак формалашу чоры (1905-1917).
5. Татар әдәби тәнкыйте тарихын өйрәнүнең торышы.
6. XIX гасыр мәгърифәтчесе К.Насыйриның гыйльми эшчәнлегендә әдәби тәнкыйть мәсьәләләре.

7. 1910 - еллар тәнкыйтендә әдәби-эстетик фикер көрәше: матур әдәбиятта тормыш дөреслеген чагылдыру, аның халыкчанлыгы һәм миллилеге, сүз сәнгатенең үсеш юнәлеше проблемалары.

8. Театр тәнкыйте туу һәм аны формалаштыруда көч куйган тәнкыйтьчеләр.

9. Әдәби тәнкыйтьнең жанрлар системасы һәм аларны төркемләү мәсьәләсе.

10. Җамал Вәлиди – тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме: әдәби тәнкыйди эшчәнлегендә жанрлар төрлелеге һәм аның әдәби әсәрне бәяләү принциплары һәм алымнары.

11. Әдәби тәнкыйтьнең юнәлеш-агымнары, төрләре һәм типлары

12. Г.Тукайның әдәби тәнкыйди эшчәнлеге. “Шигырьләребез”, 1907; “Мөбарәк тәсбих өзелде”, 1910; “Милләткә файда урынына зарар”, 1910; “Мөкаддимә”, 1910; “Яңа әсәрләр”, 1911 һ.б.

13. Г.Ибраһимов тәнкыйтендә Г.Тукай иҗаты һәм шәхесенә бәя.

14. Г.Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйтен формалаштыру һәм үстерүдәге роле. “Татар матбугаты” (1910), “Зур романнар” (1912), “Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр” (1915),”Галиябану” хакында бер-ике сүз” һ.б.

15. Г.Сәгъдинең гыйльми-тәнкыйди эшчәнлеге, әдәби тәнкыйть турындагы карашлары.

16. Хәзерге әдәби тәнкыйть (1980 еллар уртасы- 2010 еллар) һәм анда күзәтелгән сыйфади үзгәрешләр.

17. Җ.Вәлиди – беренче тукайчы галим.

18. Габделбари Батталның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге.

19. Ф.Миңнуллин – профессиональ әдәби тәнкыйтьче.

20. Г.Исхакыйның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге: әдәби әсәрләрне бәяләү принциплары һәм метод-ысуллары. “Җанлы җеназа” , “Яшь гомер”, “Низамлы мәдрәсә” , “Гаяз Исхакыйның татар әдәбияты турындагы доклады” һ.б.

21. 1920-1930 елларның беренче яртысында татар әдәби тәнкыйтенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре.

22. Ризаэтдин Фәхретдин – тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме.

23. Ф.Әмирханның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге, төп темалар.

24. Ибраһим Нуруллин –әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче.

25. Т.Галиуллин – әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче.

26. Мөхәммәт Мәһдиевнең әдәби-гыйльми, тәнкыйди эшчәнлеге.

27.1950 елларның икенче яртысы - 1980 елларның беренче яртысында (тоталитаризмнан соңгы чор) татар әдәби тәнкыйте һәм аның үсеш закончалыклары.

28.Әдәби тәнкыйтьнең шартлары турында галимнәр, тәнкыйтьчеләр.

29.Гомәр Гали – тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме.

30.1930 елларның икенче яртысы – 1950 елларның беренче яртысында әдәби тәнкыйть (тоталитар чор).